Безнең Мирас
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
06
июнь 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Мордовиядә татар утравы: ләмберә һәм түбән татарлары, эрзәләр

4 бит

Колынчаковлар утарында

80 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

06
(342)
июнь 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Шәриф Камал

ТАРИХИ МИРАС

4 Мордовиядә татар утравы: ләмберә һәм төмән татарлары, эрзәләр. *И.Биккинин*
10 «Иренә ярдәм күрсәтте». *Н.Исхаков, Р.Исхакова*
16 Малмыж татарлары телендә мари атамалары. *И.Газизуллин*
20 100 ел элек татар дөньясы: Сабан туйлары. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
22 Истанбул мәктүбләре. *Ф.Кәрими*

ТАТАР ГАМЕ

28 Без кем яки Бер китап тирәсендә уйланулар. *И.Таһиров*
35 Рәфыйк Фәтхуллов: «Сабан туен татарны танытырлык итеп оештырабыз»

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкаләә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

40 Ике тарихны бергә кушкан мәдрәсә. *И.Җиһаншин*
46 Сәйдәш Шәмсетдинов: «Эшебезне Аллаһка тапшырдык»
51 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

52 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
58 Ислам. Дини сүзлек
59 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
60 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

62 «Тәрҗемәи хәлем». *Х.Хәмидулла*
68 Татар Пешләсе
70 Композиторның зур бәхете. *Э.Шәрифуллина*
73 Эльмира Шәрифуллина шигырьләре
74 Әгъләмисина. *Ф.Зыятдинов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

78 Тораташ хакыйкать. *Р.Батулла*
80 Колынчаковлар утарында. *Р.Абянов, М.Сафәров*
86 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
88 Өзелгән җыр. *Ф.Сәлимова*
94 Истә, һаман да истә!
95 Әмир Мәхмүдов (1947-2018) шигырьләре
96 Шамун Фидаи (1902-1920) шигырьләре

СӘНГАТИ МИРАС

98 Мәгърифәтче хормейстер. *И.Кыямов*
105 Төсләрдә милли хисләр. *Д.Гайнетдинова*
108 «Сагынуга дәва юк икән» җыры

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

110 Нарат

СИХӘТЛЕ МИРАС

111 Нарат дәвалый

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Июнь*

Заказ №О-1544. Тираж – 3145 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 27.05.2022. Чыгу көне: 02.06.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
«Казан татарларының ат чабышы».
Е.Корнеев әсәреннән фрагмент. 1812 ел



Хатыннар — инсаннарның гүзәл вә ләтыйф яртысы. Алар булмаса, дөнья ямьсез бер солдат казармасы төсле булыр иде.

Шәриф Камал

Шәриф Камал шәһәр музеенда (хәзерге ТР Милли музее)

безнен мирас №6 июнь 2022

ШӘРИФ КАМАЛ
(27.02.1884-22.12.1942)

Борынгы кыргыйлар күрше халыкларга һөҗүм баскынлыкларын утлавык өчен көрәш максатларына нигезләсәләр, хәзерге немец-фашистик кыргыйлары, шул ук максатларга «тормыш мәйданы» өчен көрәш исеме биргән хәлдә, бандитлыкның төп хасияте – үтерүчелек, талаучылык җинаятьләрен иң тупас, иң әшәке һәм җирәнгеч ноктага җиткереп үтиләр.

***

Халыклар борын-борыннан үзләренең йорт-җирләрен басып алучы һәм шуңа омтылучы явыз дошманнарын, үзләренең хикмәтле иҗат җимешләре – әкиятләрендә чирканыч, зәһәр аждаһа итеп чагылдырганнар. Ул хәшәрәт, әлбәттә, коточкыч усал була: һәркөн берәүне ашый да тора. Ә халыкның инде моңардан бөтенләй коты алынган. Бары, кем кайчан ашалырга тиешлек турында тәртипне югалтмас өчен, кизү билгеләүдән башка чарасы калмаган! Ләкин чара табыла: халыкның бәхетенә каршы, бер батыр егет килеп чыга. «Дөньяны ашыйм!» – дип җикереп торган аждаһага каршы көрәш ача ул. Аждаһаның җиде (тугыз яисә унике) башын ул берәм-берәм кырып бетерә. Шулай итеп халыкны һәлак булудан коткара. Әкияттәге батыр егет халыкның аңлы күмәк көченә киная итеп алына, аны шулай дип аңларга кирәк. Ә аңлы күмәк көч үзенең хаклылыгына ышанып көрәшә икән, ул җиңелми, һәрвакыт җиңә.

***

Матур әдәбиятка бәя куйганда, иң башта без аның «чын»лык, табигыйлек һәм тормыштагы хәлләрнең, вакыйгаларның ни дәрәҗәдә күңел төбәрлек сызыкларын ала белү ягын күздә тотабыз. Әсәрне шушы яктан үлчәү – тәнкыйтьче, әдәбиятчы үлчәве генә түгел, һәрбер укучы, һичшиксез, шушы әйтелгән якларның җитешлек яисә җитешсезлегенә карап, күбесенчә үзе дә, эшнең нәрсәдә икәнлеген сизмичә, әсәргә бәя куя, ярата яисә яратмый.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Мордовиядә татар утравы: ләмберә һәм түбән татарлары, эрзәләр

Ирек Биккинин

Биредә хәзер ике шәһәр – Саранск һәм Рузаевка, шулай ук Ләмберә, өлешчә Ромоданово, Рузаевка һәм Кочкурово районнарындагы татар, урыс һәм мордва (мукшы һәм эрзә) авыллары урнашкан. Бу авыллар Ынзара (урысча Инсар) елгасына коя торган Таула һәм Пензятка елгаларының үзәнлеген били. Шулай ук Ынзара елгасының Рузаевкадан алып Ромодановога кадәрге үзәнлеге дә – борынгы татар җирләре. Биредә яшәүчеләрне этнографик әдәбиятта ләмберә татарлары дип атыйлар.

Эш шунда ки: хәзерге көнгә кадәр әлеге торак пунктларның тарихын Атемар (1638), Саранск (1641) һәм Инзер (1642) ныгытмалары, шулай ук Саранск-Инзер-Атемар-Сура елгасы чик буе ныгытмалары төзелеше белән генә бәйләп аңлаттылар. Фәндә урыс дәүләте җирләренең киңәюе, яңа җирләрне яулап яки сатып алуга мөнәсәбәтле берьяклы гына караш хөкем сөрде. Мордва тарихчылары да шушы фикергә ияреп китте: әйтерсең, элек, шәһәрләр төзелгәнче, бу җирләрдә беркем дә яшәмәгән.

Әлеге биләмәгә татар морзалары хуҗа булган

Күптән түгел генә «Приправочный список с дозорной книги города Темникова и Темниковского уезда 1613/14 г.», «Писцовая книга татарским поместным землям Алатырского уезда 1624-1626 годов» һәм «Мордовский фронтир в зеркале приказной статистики (первая четверть XVII века)» исемле китаплар басылып чыкты. Шулай ук «Челобитная вдовы мурзы Тляша Кутыева» исемле кыйммәтле тарихи документ та дөнья күрде. Әлеге чыганакларда татарларның 1443, 1479, 1485, 1490 нчы елларда Түбән өязендә җир сатып алулары турында мәгълүматлар китерелә. Бу исә шушы биләмә Мәскәү кенәзләре хакимлегенә күчкәнче үк аңа татар морзалары хуҗа булганлыгы турында сөйли. Шулай ук Мордовия Республикасы дәүләт архивында саклана торган иң борынгы документ та – «Раздельная запись между потомками [братьев] Идиге и Бегиша 1569/70 года» басылып чыкты. Анда сүз Идегәй һәм Бигеш морза оныкларының печәнлек җирләрне үзара бүлешүе хакында бара. Әмма бу вакыйга инде әлеге биләмә Мәскәү хакимияте карамагына күчкәннән соң була. Шуңа да карамастан, Алтын Урда традициясен дәвам итеп, әлеге кыйммәтле чыганак татар телендә язылган. Имзалаучылар арасында ике урыс кешесе дә бар – алар «послух» дип аталган. Элекке заманда «послух» сүзе «ышанычка лаеклы шаһит» мәгънәсендә кулланылган. Димәк, биредә яшәүче башка милләт кешеләре дә татар телен яхшы белгән.



Идегәй һәм Бигеш морза оныкларының печәнлек җирләрен үзара бүлешүе хакындагы 1569/70 елгы документ. Татар телендә язылган бу чыганак Мордовия Республикасы дәүләт архивында саклана.

Аксюн һәм Татар Тауласы – мөстәкыйль территория

Алда әйтелгән чыганаклар буенча хәзерге Саранск тирәсендәге Аксюн һәм Татар Тауласы авыллары кешеләренең биләмәләре, гомумән, хәзерге Ләмберә районы тулысынча һәм Рузаевка районының көнчыгыш өлеше Түмән өязенә дә, Алатыр өязенә дә карамаганлыгын күрәбез. Шулай ук әлегә кадәр бу җирләрнең Арзамас өязенә керүе турында да тарихи документлар табылмады.

Түмән өязе әлеге биләмәләрдән көнбатышта һәм берникадәр өлеше генә көньяктарак була. Алатыр өязе – көнчыгышта һәм аз гына өлеше көньякта урнашкан, ә төньяктан исә Арзамас өязе белән чиктәш. Ул вакытта Түмән өязе территориясе бик зур була. Ул Мокша елгасының зур өлешеннән, Сура елгасының урта һәм югары агымындагы биләмәләрдән алып көньяк-көнчыгышка таба, Кадады елгасының югары агымына кадәрге җирләргә сузылган. Чыганакта: *«XVI гасыр уртасында Түмән татарлары вотчиналары казан татарлары биләмәләре белән дә чиктәш»,* – дип язылган. Алатыр өязенең торак пунктлары хәзерге Большие Березники авылы тирәсеннән башланып киткән һәм Сура елгасының ике як яры буенча дәвам иткән.

Түмән өязенең көнчыгыш чиген һәм Алатыр өязенең көнбатыш чикләрен билгеләгәндә, ул вакытта административ яктан беркая да карамаган шактый зур территорияне – Аксюн һәм Татар Тауласы җирләрен, хәзерге Рузаевка һәм Саранск калаларын, Ләмберә районындагы биләмәләрне күрәбез. Аның көнбатыш чикләре Түмән өязенең көнчыгыш чикләрендәге Ирсәит (урысча – Ирсеть), Иса (урысча – Исса), Рудня елгаларына кадәр барып җиткән. Анда төрле татар кенәзләре, морзалары һәм йомышлы татарлар көн күргән. Данлыклы кенәз Үтәшевләрнең дә борынгыдан килгән сөрүлек җирләре шунда булган. Биләмәнең көньяк өлеше Таула елгасының югары агымында урнашкан.

Түмән, Арзамас һәм Алатыр өязләренең татар морзалары һәм йомышлы татарлары, сакланып калган күп документлардан күренгәнчә, чик буе ныгытмалары төзегәнче үк бу җирләргә хуҗа булган. Ләкин соңрак – XVIII гасыр башында аларның күбесе көньякка һәм көнчыгышка күченгән.

Аксюн һәм Татар Тауласы авыллары Саранск төзелгәнче үк булган

XVII гасыр башында, ягъни Саранск-Атемар-Сура ныгытмалары төзелгәнче ике дистә ел алдан ук бу тирәдә ким дигәндә ике татар авылы – Аксюн һәм Татар Тауласы булган дип һич тә шикләнми әйтә алабыз. Моны Мордовия Республикасының Үзәк дәүләт архивында саклана торган «О спорном землевладении поручика Литвинова и крестьян деревни Аксенова и Тат-Тавлы» [ЦГАРМ. Ф.16. Оп.1. Д.45. ЛЛ.1-172.] исемле документ дәлилли. Шулай ук Пенза өлкәсенең дәүләт архивында бу авыллардагы җир мөнәсәбәтләренә бәйле башка чыганаклар да бар [ГАПО. Ф.24. Оп.1. Д.274]. Алар арасында иң мөһиме – 1615 елгы теркәү кенәгәсе язмалары. Анда Аксюн һәм Таула татарларының көньяктан – Подлесная Тауладан (бүген анда гына эрзәләр яши) алып хәзерге татар авылы Кривозерьега чаклы җирләре тасвирланган. Бу гаять зур территория һич кенә дә бер генә йомышлы татарның милке була алмый. Димәк, биредә җир-суга хуҗа татар морзалары берничә булган. Шунысын да искәртергә кирәк: әлеге җирләр бу территория Мәскәү дәүләте карамагына кергәнче үк мондагы татарларның биләмәсе булган. «О спорном землевладении поручика Литвинова и крестьян деревни Аксенова и Тат-Тавлы» исемле документта бу турыда менә нинләр



Җир мөнәсәбәтләренә бәйле документның шушы фрагментында 1615 елда Аксюн һәм Таула авылы игенчеләре хакында сүз бара. Чыганак Мордовия Республикасының Үзәк дәүләт архивында саклана.

язылган: *«...Во втором отделении в даче №1 деревень Аксеновы и Тавлы по выписи с писцовых книг 123-го года (1615 ел. – И.Б.) без заглавия за рукою дьяка Данилы Никитина да подьячего Ивана Протопопова написано произведено деревень Аксеновой и Тавлы мурзам и татарам пашни две тысячи триста шездесят четвертей, а с чего по переведению составит три тысячи пятьсот сорок десятин, сенных покосов четыреста семьдесят две десятины, да под усадьбою пятьдесят девять десятин, а всего четыре тысячи семьдесят одна десятина...»*

Таула халкының күченүе, Аксюн-Таула мөнәсәбәтләре

Ә инде 1642 һәм 1685 нче еллардагы теркәү кенәгәләре Аксюн һәм Таула татарлары биләгән мәйданның шактый кечерәйгәнен күрсәтә. Башта бу җирләрне Атемар ныгытмасын төзү, соңрак анда яшәүчеләр өчен тартып алалар, күрәсең. Ә инде 1681-1683 нче елларда җирле урыс булмаган халыкларны көчләп чукындыру кампаниясе вакытында Подлесная Таулада яшәүче татарларга үз биләмәләрен калдырып китәргә туры килә. Бу вакытта атлы казаклардан гына торган таула татарлары чукындыруга керешкән чиркәү отрядларын кырып сала. Миссионерлар җирле халыкны Таула елгасына куып төшерергә өлгергән булалар. Хәзерге көнгә кадәр Подлесная Таула авылында яшәүче эрзәләр әлеге сугыш урынын күрсәтә ала, алар аны хәтерләреннән чыгармыйлар.

Таула татарларының бер өлеше төньякка, татарлар гына яши торган икенче Таула авылына китә. Бу авыл Атемар крепостеннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 3 ча-

крым читтә – «Бәлчек базлары» дигән җирдә урнашкан була. Әмма, Атемарда чиркәү төзелә башлау сәбәпле, татарларга бу урынны янә ташлап китәргә туры килә. Алар Атемардан тиз генә килеп җитәргә мөмкин булмаган җиргә – Елшанка елгасы буена, әмма Аксюнга бик якын урынга төпләнәләр. Бу урын хәзер Каенсар дип атала. Аксюн татарлары белән килеп туган каршылык нәтиҗәсендә, әлеге татарлар Елшанканың сул ягына, нәкъ менә хәзер яши торган җиргә килеп урнашалар.

Риваятьләргә караганда, Подлесная Тауладагы кайбер татар һәм эрзәләрнең бер өлеше, чукынып, шунда яшәп калган. Соңрак алар, эрзәләргә кушылып, үз милләтләрен югалтсалар да, XX гасыр башына кадәр Татар Тауласында яшәүчеләр белән туганлык мөнәсәбәтен өзмиләр. Араларында чукынырга теләмәүче эрзәләр дә була. Алары исә татарлар белән китә һәм, татарлашып, Татар Тауласында яшәп кала.

Күченүләр дәвам итә

Подлесная Тауладан килгән татарларның тагын бер өлеше, Алмыш Елаев һәм Байбашка Байбулатов җитәкчелегендә, 1683 елда көньякка китә һәм Пензадан 30 чакрым ераклыкта урнашып, Оз (урысча Усть-Уза) авылына нигез сала. Бу татарларның кайберләре соңрак үз җирләрен эрзә морзаларына сатып, Татар Тауласына күченәләр. Хәзерге вакытта зур татар авылы Оз янында эрзәләрнең кечкенә генә Усть-Морза авылы урнашу һич кенә дә очраклы күренеш түгел. Таула татарларының да XVII гасыр азагында Уза елгасының Сурага койган җирендә төпләнүе тикмәгә генә булмаган. Бу урынны алар сак хезмәтен башкарганда ук бик яхшы белгәннәр.

Таула татарларының тагын бер төркеме Сураның уң як яры буйлап Алатыр өязенә китә һәм Аксу (Татарская Голышевка) авылына нигез сала. Шулай ук Кочкурово районындагы Татар Ымызы авылына да алар тарафыннан нигез салынган – анда Тауладан килүче морза Бозаевлар хуҗа була.

Аксюн, Татар Тауласы кешеләре белән Пенза өлкәсенең Оз авылы халкы арасындагы никах мөнәсәбәтләре озак еллар дәвам иткән: тел үзенчәлекләрендәге күп кенә уртаклыклар да аларның кардәшлегенә дәлил булып тора. Татар Тауласы имамнарының дога кылган вакытта: «Ике Таула зәрәтләре...» – дип багышлап куюлары да очраклы күренеш түгел.

Аксюн һәм таула татарлары Алтын Урда чорыннан ук биредә яши

1615 елда биредә яшәгәнлекләре теркәлгән татарлар, мөгаен, Алтын Урда чорында да шушында ил-йорт тоткандыр. Бу яшәр өчен бик тә уңайлы урын булган: мал көтәргә киң сахра да, киек-җанвар ауларга урман да бар, елга-күлләр дә якында гына. Әлеге территориянең иң мөһим үзенчәлеге шунда: биредән «Кырым юлы» (төрле чыганакта төрлечә: «Зур илчелек юлы», «Бортас юлы») узган. Бу юл заманында Кырым һәм Казан ханлыкларын үзара бәйләгән.

Бераз көньяктарак, хәзерге Оз авылы тирәсеннән (Пенза өлкәсенең Шемышейка районы) Кырым юлы Бөек Ефәк юлының төньяк тармагы белән кисешкән. Оздан 10 чакрым төньяктарак танылган Золотаревское шәһәрлеге урнашкан.

Ефәк төягән борынгы кәрваннар иң башта Сура елгасын, ә аннары Узаны кичкән. Елганың исеме дә саф татарча – Уза, аның татар телендәге узу, кичү сүзеннән алынганлыгы гаҗәп түгел.

Аксак Тимернең Алтын Урда белән сугышлары вакытында ләмберә татарлары хәзерге Пензаның көнбатыш өлешендәге Мукшы (хәзер Наровчат район үзәге) шәһәрендәге татарлар кебек Урта Азиягә сөрелмәгән. Әлбәттә, Аксак Тимер барлык татарларны да туган җиреннән куып бетерә алмаган. Аларның кайберләре Төмән, Кадом һәм Цна елгасы тирәсендәге урманнарга качып котылган. Соңрак аларны төмән татарлары дип атап йөртә башлыйлар.

«Кыргый дала»да – уяу татарлар

Алтын Урда аерым дәүләтләргә таркалганнан соң, урман белән дала чигендә, ягъни булачак Пенза губернасы территориясендә утрак тормышта яшәүче халык калмаган диярлек. Бу урыннар тарихи чыганакларда «Дикое поле» («Кыргый кыр») дип атала башлый.

Әмма 1443, 1479, 1485, 1490 нчы еллардагы җир һәм сәүдә мөнәсәбәтләренә бәйле документларда төмән һәм ләмберә татарлары, шул исәптән эрзә морзалары да әлеге болын-кырларны умарталык, көтүлек һәм печәнлек җирләре буларак файдаланган. Әлбәттә, яшәр өчен шактый куркыныч бу урында аларның авыллары булмаган, алар, вакытлыча гына тирмә корып, төн уздырганнар. Кораллы җайдаклар төркеме – нугайлар яки башка күчмәннәр килеп чыкса, алар үзләренә бик таныш урман юллары аша төньякка кача торган булганнар.

XVII гасыр башында, әле Саранск-Атемар-Сура чик буе ныгытмасы төзелгәнче үк, монда яшәүче татарлар киң далада хезмәт иткән. Алар, кавалерия отрядлары кебек үк, чик буен саклаган, сахрада 15әр көн хезмәт итеп, күчмә кабиләләрнең, аеруча нугайларның утрак тормыш алып баручыларга һөҗүмен кисәтергә тиеш булган. Кырым-Казан юлында төзелгән Подлесная Таула, Шукша (урысча Синорово)* һәм Оз авыллары элегрәк Аксюн һәм Таула кешеләренең вакытлыча лагере булгандыр дип уйларга нигез бар.

Хакыйкать кайда?

Шулай итеп, Саранск һәм Атемар кальгалары төзелгәнче үк, биредә яшәүче татарлар хәрби хезмәт белән чарланган. XIX гасыр ахырында яшәгән Пенза тарихчысы Григорий Петерсон фикеренчә, хәтта хәзерге Саранск шәһәре урынында да элек татар авылы булган. Тарихи документлар да Саранск һәм Атемар ныгытмасы җирләренең аксюн һәм таула татарлары биләмәсе булганын дәлилли. Соңрак көньяк-көнчыгышка таба яңа территорияләрне яулап килгән Мәскәү дәүләтенең чик буендагы иминлеген саклар өчен батыр, тырыш һәм намуслы татарларның җәлеп ителүе һич тә гаҗәп түгел.

Аксюн авылына 1669 елда Сюнбайка Аксенов нигез салган дигән фикер тарихи дөреслеккә һич кенә дә туры килми. Шулай ук ләмберә татарлары бирегә ныгытмалар төзелгәннән соң гына Төмәннән китерелгән дигән фикернең тарихи хакыйкатьтән ерак икәнлеге аңлашыла.

Аксюн һәм таула татарлары Кырым-Казан юлында ям хезмәтен башкарган, үз биләмәләрен күчмә халыкларның һөҗүменнән саклап, мал асрап, иген игеп көн күргән, мәктәп-мәдрәсәләрдә илгә лаеклы, гыйлемле һәм батыр оланнар (*ир балалар. – Ред.*) тәрбияләгән. ■

---

* БССРның атказанган тренеры, очучы-инструктор, парашют спорты буенча ун мәртәбә дөнья рекорды куйган Мөһәшәт Хөсәен улы Шәиповның туган авылы.

«Иренә ярдәм күрсәтте»

(Үтәмеш кулаклары)

Нияз Исхаков, Резеда Исхакова

РКП(б)ның 1921 елның 14 мартында узган X съездында ил күләмендә Яңа икътисади сәясәт (НЭП) игълан ителеп, ул 1921-1928 нче елларда гамәлгә ашырыла. Аның төп билгеләренең берсе – авыл җирләрендә яшәүчеләргә иркле рәвештә игенчелек, сәүдә һәм башка юнәлешләрдә шөгыльләнү мөмкинлекләре бирелү. Шушы сәясәт крестьяннарга сөрүлек җирләрне арендага алу һәм ялланып эшләү мөмкинлекләрен дә биргән. Хәзерге Тәтеш районына кергән Үтәмештә дә, шуннан файдаланып, хезмәткә актив керешүчеләр булган. Берәүләр үзләренең имана җирләрен генә бик теләп эшкәртә, икенчеләре исә Үтәмештә генә түгел, ә аңа күрше булган авылларда да сөрүлек җирләрне арендага алып, күпләп сату өчен икмәк үстерә. Бу хәлләрнең нәтиҗәсе буларак, авылда кулаклар катламы барлыкка килә, ярлылар, урта хәлләләр һәм байлык туплый алганнар арасында каршылыклар көчәя.

Кулаклар кемнәр алар?

Кулаклар – Октябрь инкыйлабына кадәрге Русиядә таза тормышлы крестьяннарның атамасы. Кулак дип эре җир биләмәләренә һәм җитештерү җиһазларына хуҗа булып, яллап эшләтүчеләрне йөрткәннәр. Ягъни аларның башка кешене яллап эшләтә алулары кулак булмаган крестьяннардан аерып торган төп фактор булган. Юридик яктан караганда, үз гаиләсе көченә генә таянып, яхшы тормыш алып баручы, әмма яллап эшләтү хезмәтеннән файдаланмаучылар кулаклар катламына кертелмәгән. XX гасыр башына кадәр Русиядә кулаклар катламы халыкның якынча 20 процентын тәшкил иткән, ә ил күләмендә җитештерелә торган икмәкнең 50 процентын алар биргән.

Егерменче еллар ахырында СССРда ялгыз крестьян хуҗалыкларын берләштерү юлы белән башта коммуналар, аннары күмәк хуҗалыклар (колхозлар) оештыру кампаниясе башлана. Колхозлар оештыру белән бер үк вакытта «Кулакларны сыйныф буларак юк итү» сәясәте алып барыла башлый. Колхозлар төзү һәм «кулакларны юк итү» кампанияләре Коммунистлар Партиясе инициативасы белән башлана һәм гамәлгә ашырыла.

1930 елның 30 гыйнварында ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы «Тоташ коллективлаштыру үткәрелгән районнарда кулак хуҗалыкларын юк итү буенча чаралар турында» карар чыгара. 1921 елда хөкүмәт законы белән җирне арендага алу һәм яллы хезмәттән файдалану рөхсәт ителгән булса, тугыз елдан соң кабул ителгән әлеге карар буенча җирне арендага алучыларны һәм яллап эшләтүчеләрне кулаклар итеп тану, аларның милекләрен тартып алу һәм авылдан куу кирәклеге турында әйтелә. Кулакларның җитештерү чараларын, мал-туарын, хуҗалык һәм торак корылмаларын, чәчүлек запасларын, терлек өчен әзерләнгән азыкны, финанс байлыкларын (акцияләрен һәм акчалата тупланган запасларын) конфискацияләү

Үтәмештәге кулаклаштыру чорына бәйле документлар

таләп ителә. Тартып алган җитештерү чараларын колхозларга тапшыру һәм аларны ярлылар өчен колхозга керү взносы итеп санау турында әмер бирелә. Кулакларның милекләрен барлау, ачыклау, конфискацияләү һәм гаиләләрен авылдан куу гамәлләрен башта колхозчылар һәм ярлылар җыелышларында карау кирәклеге белдерелә. Хөкем карарларын судларда карамыйча да чыгару рөхсәт ителә. Шул ук вакытта кулакларга яшәгән урыннарыннан үз теләкләре белән күченеп китү һәм милекләрен сату тыела.

Политбюро карары нигезендә кулаклар катламына кертелгәннәрне өч төркемгә бүлеп карыйлар:

- беренче төркемгә «контрреволюцион кулак активы»н, террор һәм фетнәләрне оештыручыларны керткәннәр. Аларны кичекмәстән кулга алырга, гаиләләрен илнең төньяк һәм көнчыгыш районнарына озатырга кушылган;

- икенче төркемгә «контрреволюцион кулак активы»ның калган өлешен, аеруча иң бай кулакларны һәм ярымалпавытларны керткәннәр. Аларны илнең ерак районнарына сөрергә кирәк диган әмер бирелгән;
- өченче төркемгә «башка кулаклар» кертелгән.

Әмерне арттырып үтәү

«Башка кулаклар» – бу бит шикле сүзләр! Кемнәр соң алар «башка кулаклар»? Алар үз районнарында калдырылырга, әмма колхоздан читтә булган участокларга таратып утыртылырга тиеш булган. Игътибар итик: «аларны үз районнарында калдырырга» кушылган. Әмма Үтәмештә бу әмер кәгазьдә генә калган, гамәлдә ул арттырып үтәлгән. Барлык төркем кулаклар да, аерып тормыйча, гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән.

Кулаклар дип саналган гаиләләрдә 18-60 яшьтәге хезмәткә яраклы ирләр булмаса, шулай ук партиядә, комсомолда әгъзалыкта торган һәм революция хәрәкәтендә катнашкан гаилә әгъзалары булса, андыйларны сөргенгә дучар итәргә ярамаган. Үтәмештә бу таләпне дә үтәмәгәннәр.

Шунысы да игътибарга лаек: Политбюро карарында аерым төркемнәргә кертелергә тиеш булганнар санына нормалар билгеләнгән:

- кулак буларак юкка чыгарылучылар 3-5 процент күләмендә булырга тиеш;
- концентрацион лагерьларга 60 мең кешене җибәрергә кирәк;
- 150 мең кеше чит төбәкләргә сөрелергә тиеш.

Шушы гамәлләрне 1930 елның февраль-май айларында башкарып чыгу таләбе куелган. Совет хөкүмәте Политбюро карарын кичекмәстән гамәлгә ашыру максаты белән 1930 елның 1 февралендә Декрет кабул итә. Декретта мондый карарлар игълан ителгән:

- тоташ күмәкләштерү уздырыла торган районнарда (бу исемлеккә Татарстан да керә) аерым крестьян хуҗалыкларына җирләрне арендага алуны һәм яллап эшләтүне рөхсәт иткән закон гамәлдән чыгарыла;
- кулакларның милкен тулысынча конфискацияләргә һәм үзләрен чит төбәкләргә сөрергә;
- кулак хуҗалыкларыннан конфискацияләнгән милекне колхозның бүленми торган фондына тапшырырга һәм ярлылар белән батраклар файдасына аларның колхозга керү взносы итеп санарга.

Күрсәтелгән сәяси яңалыкларны ярлылар хуплап кабул итәләр, чөнки күмәк хуҗалыкка берләшүчеләрнең чәчүлек җирләре хосусыйлаштырыла, ә шәхси милекләренә чикләүләр куела, артыгын күмәк хуҗалык файдасына тапшырырга тиеш булалар. Мәсәлән, барлык атлар күмәк хуҗалыкта туплана, шәхси хуҗалыкта бер сыер һәм өч-дүрт баш сарык асрау гына рөхсәт ителә. Шундый шартларда кулакларның колхозга керүе, йомшак итеп әйткәндә, шикле булган. Кулаклар колхозга кермәгән очракта, бер авыл җирлегендә колхозчы крестьяннарның һәм кулакларның янәшә һәм тыныч яшәвен тәэмин итү дә мөмкин булмаган. Менә шул сәбәпләр аркасында колхозларны оештыру эшләрен башлаганда кулакларны авылларда калдыру кирәк түгел дип табылган.

Рәсми төстә күмәк хуҗалыкка берләшү һәр кеше өчен ирекле дип саналган. Чынбарлыкта исә бай тормышта яшәүчеләрне дә кулаклар катламына кертәләр, милекләрен күмәк хуҗалыкка күчерәләр, ә үзләрен авылдан гына түгел, Татарстаннан да читкә җибәрәләр.

Урта хәллеләргә дә күмәк хуҗалыкка берләшүдән гайре чара калмый, чөнки аларга, күмәк хуҗалыкка кушылмаган очракта, зур күләмле салымнар билгеләнә. Башка төрле чикләүләр дә кертелә, мәсәлән, көтүлек җирләрдән файдалану тыела.

Күмәк хуҗалыкка берләшү вакытында барлыкка килгән үзенчәлекле хәлләр рәтенә авыл йортларына карата кертелгән чикләүләр дә өстәлә. Һәр гаиләдә бер генә өй калырга тиеш булган. Чолан белән бүленгән ике буралы йорт булса, аларның берсен күмәк хуҗалыкка тапшыру каралган. Бу хәлгә калмас өчен, мәсәлән, Исхаков Кәлимулла үзе белән бер хуҗалыкта яшәүче улы Сөнгатулланы һәм аның гаиләсен «аерып чыгара»: ике бураның берсен яңа урынга күчереп, икенче йорт төзиләр һәм Сөнгатулла гаиләсе шунда яши башлый. Исхакова Фатиханың да йорты ике буралы була. Күмәк хуҗалыкка берләшү алдыннан ул бураларның берсен «сатып өлгерә».

Үтәмештә колхоз төзү вакытында, кулак тамгасы куеп, авылдан куылганнарның барлыгы билгеле була, әмма күп еллар буе бу турыда сүз алып бару, фикерләр белдерү хупланмый. Андый хәлләр, бәлки, партия оешмалары тарафыннан тыелган да булгандыр, чөнки әлегә кадәр шул юл белән Үтәмештән куылганнарның кемнәр икәнлеге, моңа нинди сәбәпләр китергәнлеге, бу хәлнең ничек оештырылуы һәм читкә сөрелгәннәрнең язмышлары турында нинди дә булса төгәл мәгълүматның булу-булмавы билгесез иде.

Куылырга тиешле 11 гаилә

Үтәмештә нинди дә булса гаиләне кулак гаиләсе дип тану һәм аны авылдан сөрү турында карар кабул итү өч этаптан торган.

Беренче этапта авылның ярлылар җыелышы тарафыннан кулак булып саналырга тиешле гаиләләрнең исемлеге төзелгән. Җыелышта сайланган һәм, гадәттә, өч кешедән торган төркем һәр гаилә башлыгының тәрҗемәи хәлен язган һәм аңа сәяси характеристика биргән, гаиләнең милкен ачыклаган; һәр милек төренең санын, күләмен һәм акчалата бәясен күрсәтеп, белешмә-документ булдырган. Сәяси характеристикада гаилә әгъзаларының, беренче чиратта, гаилә башлыгының, сөрелүгә нигез булырлык гаепләре билгеләнгән һәм аны нинди төркемгә кертү кирәклеге тәкъдим ителгән. Шушы гаиләләргә ялланып эшләүчеләрне батраклар дип атаганнар. Әлбәттә, ялланып эшләүче һәркем батрак була алмый. Әмма, кулакларны гаепләү факторлары көчлерәк яңгырасын өчен, аларга карата һәр очракта да «батраклары бар» дип күрсәтелгән. Бу берничек тә дәлилләнмәгән. Тупланган мәгълүмат ярлылар һәм колхозга кергән крестьяннар катнашындагы гомуми җыелышта тикшерелгән.

Монда шуны да искәртеп китү урынлы дип саныйбыз: кулакларны сөрү вакытында (1930 елның марты) Үтәмештә колхоз әле оеша гына башлаган була. Колхоз оешуның беренче елы ахырына, ягъни ун айдан соң, колхозда барлыгы 20 хуҗалык булган. Димәк, кулаклар турында карарлар кабул ителгән көннәрдә – 1930 елның март аенда – «колхозга кергән крестьяннар» берничә хуҗалыктан гына торган һәм алар кулаклар турында мәгълүмат туплауны оештыручы һәм башкаручы бик аз санлы ярлылар булган дип уйларга нигез бар. Ярлылар җыелышы ничек итеп оештырылган, анда катнашучы авыл халкының саны күпме, фикер алышулар булганмы – әлеге сорауларга җавап табу мөмкин түгел. Бу хәлләр, бәлки, формаль рәвештә генә үткәндер. Авыл халкының күпчелеген билгесезлек борчыгандыр, чөнки кемгә карата һәм нинди караш барлыкка килүе ачыкланмаган. Кулаклар дип саналырга тиешле кешеләр турында документлар төзүчеләрнең кемнәр икәнлеге дә билгеле

түгел. Һәр документ ахырында бары тик ике фамилия генә күрсәтелгән – Сәлахов (бер урында Сәлахетдинов) һәм Әхмәтшин. Хәтта шул төркемне җитәкләүченең фамилиясе дә билгесез. Һәр очракта, ни сәбәпледер, «Аның өчен Сәлахов» дип язылган. Ул үзенең кем икәнлеген документта күрсәтергә теләмәгәнме яки фамилиясен яза белмәгәнме? Бу турыда белмибез.

Беренче этапның нәтиҗәләре, ягъни ярлылар тарафыннан әзерләнгән материаллар Бакырчы Авыл Советында каралган, хупланган йә кабат карау кирәк дип табылган. Әмма Авыл Советының нинди дә булса мөһим күрсәтмәләр бирүе турында мәгълүмат юк. Димәк, авыл ярлыларының карашы хәлиткеч көчкә ия булган.

Авыл Советы хуплаган материалларның Олы Тархан вулысы җитәкчеләреннән төзелгән «өчлек» («тройка») тарафыннан раслануы һәм аларның үз көченә керүе соңгы этап булып тора. Аерым очракларда авыл ярлылары эшендә вулыс вәкиле дә катнашкан. Гомуми җитәкчелек ролен Буа кантонында оештырылган «өчлек» башкарган, чөнки ул елларда Олы Тархан вулысы Буа кантоны составында булган.

Архив күчермәләреннән күренгәнчә, башта Үтәмештән куылырга тиешләр дип төзелгән исемлектә 11 гаилә була: Дәүләтша Яһудин, Шакирҗан Габдерахманов, Гыйният Сибгатуллин, Хөсәен Әбелханов, Мөхәммәтша Яһудин, Зыятдин Батталов, Әхмәтҗан Габдерахманов, Гариф Рәшитов, Сабирҗан Сабитов, Хәйретдин Хөснетдинов һәм Хөсәен Измайлов гаиләләре. Шушы исемлектәге биш гаилә кабат тикшерелергә тиеш дип табылган. Нинди сәбәпләр аркасында кабат тикшерү кирәк дип табылуы әйтелмәгән. Өстәмә тикшерүләрнең нәтиҗәсе буларак, Гыйният Сибгатуллин, Зыятдин Батталов һәм Сабирҗан Сабитов гаиләләре Үтәмештән куылырга тиешле кулаклар исемлегеннән чыгарылган, әмма моңа нинди сәбәпләрнең нигез булуы әйтелмәгән. Исемлекнең соңгы вариантында Шакирҗан Габдерахманов гаиләсе дә күрсәтелмәгән. Шулай итеп, 1930 елның март аенда җиде гаилә кулак дип танылган һәм Үтәмештән сөрелгән. Шушы җиде гаилә башлыкларының исемнәре: Гариф Рәшитов, Хөсәен Әбелханов, Хөсәен Измайлов, Дәүләтша Яһудин, Әхмәтҗан Габдерахманов, Хәйретдин Хөснетдинов, Мөхәммәтша Яһудин. 6 бала атасы Хөсәен Әбелхановка менә мондый гаепләү тагыла: *«Чыгышы белән ярлы крестьян гаиләсеннән. Әтисеннән аерылып, бераз вакыт узгач, сәүдә итү һәм җирләрне арендага алу белән шөгыльләнде. 1928 елга кадәр батраклар тотты. Шулай итеп, кулакка әверелде. Сайлау хокукыннан мәхрүм ителгән. Спекулянт һәм ростовщик. Ярлыларның җирен сатып алып, башкаларга спекулятив рәвештә сата иде»*. Әхмәтҗан Габдерахманов турында: *«Чыгышы белән урта хәлле крестьян гаиләсеннән. Соңрак кулак кызына өйләнде. Хатынының әтисе үлгәннән соң, зур күләмле мирасы калды. Әхмәтҗан Габдерахманов сәүдә итә башлады. Ялган документлар белән ярлыларның һәм батракларның җирләрен мәңгелек арендага алды»*, – диелә.

Үтәмештән куылган кулак гаиләләренең нинди төбәкләргә җибәрелгән булулары безгә билгеле түгел. 1932 елдан аларның гражданлык хокуклары торгызыла башлаган. Шуннан соң, формаль караш буенча, 1930 елда авылдан куылганнарга даими яшәү өчен Үтәмешкә кайту мөмкин булган. Әмма, әхлакый яктан караганда, аларның шундый адым ясауларын күз алдына китереп булмый.

Совет тактикасы: хатыннарны капшап карарга

Авылдан кулакларны сөрү нәкъ менә колхоз төзелеше белән аерылгысыз бәйләнгән. Кулакларны сөрүнең төп максаты – күмәк хуҗалык төзүне тәэмин итү.

Үтәмеш күләмендә шул максатка ирешелде – «Яңа юл» колхозы төзелде. Колхоз җитәкчеләре ел саен алышынып торды. Аның яшәү рәвеше район түрәләренең әмерләрен үтәүгә юнәлтелде. Кайсы авыллар белән берлектә колхоз төзү, нинди мәйданда һәм нинди культуралар чәчү, нинди терлекчелек һәм кошчылык фермалары булдыру һәм, әлбәттә, җыеп алынган уңышны беренче чиратта һәм тулысынча хөкүмәткә тапшыру – болар һәм башка шундый боерыклар район тарафыннан куела иде. Район түрәләре авылга гел килеп торды, бигрәк тә сугыш елларында ешайдылар һәм алар үзләрен бик иркен, ә кайчакта әхлаксыз тотты. Кырдан кайтучы хатыннарның урланган бөртекләр юкмы икән, дип, эчке кесәләрен капшап карау өчен идарәдә эшләүче йә укытучы апалар җәлеп ителә иде.

Күмәк хуҗалыкта авыл халкы хәл итә торган мәсьәләләр булмады. Авыл халкы үзен хокуксыз итеп тойды. Шуның нәтиҗәсе буларак, колхоз тәмәке утыртты һәм уңышын хөкүмәткә тапшырды. Колхоз кырында гына түгел, колхозчыларның өй арты бакчаларында үстерелгән бәрәңгене дә, салым рәвешендә җыеп, Кыят спирт заводына тапшырдылар. Нәтиҗәсе – хәтта сугыш елларында да кибеттә аракыга кытлык булмады. Иң аянычы – Үтәмеш колхозында дуңгыз фермасы оештырылды. Урам коелары янында дуңгызлар пычрана иде, авыл зиратында колхозның ферма терлекләре, шул исәптән дуңгыз балалары да үзләрен иркен тотып йөриләр иде.

Болар барысы да инициатива күрсәтә алырлык, игенчелек хезмәтенең нечкәлекләрен аңлап эшләүче крестьяннарны авылдан кууның нәтиҗәсе. Авылларда күмәк хуҗалыклар оештырылмаган булса, игенчелек белән уңышлы шөгыльләнүче бай катламны тәшкил иткән крестьяннар һәм кулаклар авылларыннан куылмыйча яшәгән булырлар иде. Кулаклар гына түгел, һәр кеше, әгәр аның гамәлләре, шул исәптән контрреволюцион төргә кергәннәре дә, җинаятьче дип танылса икән, кануни нигездә хөкем ителергә тиеш. Моның өчен, авыл ярлылары тарафыннан төрле төркемнәргә кертеп, авылдан куу кирәк түгел. Бу бернинди дә кануни нормаларга сыймый. Бу чорда яңа оештырылачак колхозларда мөстәкыйль фикер йөртә торган крестьяннар булмаска тиеш, дип саналган, ахры.

Мулла хатыны – исемлектә беренче

Авылдан куылырга тиеш булганнар исемлегендә ике дин әһеленең – Гариф Рәшитовның (аның турында, качып йөри, диелә, шунлыктан исемлек башында хатыны Мәгъсүмә) һәм Гыйният Сибгатуллинның булуы аңлашылмаган иде, чөнки алар берничек тә кулаклар төркеменә кертелә алмыйлар. Беренчесенә: *«Гариф Рәшитов 1909-1928 нче елларда мулла иде. Ул халык җилкәсендә, шул исәптән хезмәте өчен йөкле хатыннардан соңгы кисәкләрен алып яшәде. Булдыклыларны үз хуҗалыгында түләүсез эшләтте. Чехлар баш күтәргәч (оригиналда – нашествие чехов. – Н.И.) Совет хакимиятенә каршы эш алып барды. Мәгъсүмә Рәшитова, мулла хатыны буларак, хатын-кызлар арасында эшләп, иренә тулы ярдәм күрсәтте»,* – дигән гаепләү тагыла. Алар зур күләмдә җир биләүчеләр түгел, сәүдә итү белән дә шөгыльләнмәгәннәр, яллы хезмәттән дә файдаланмаганнар. Өстәвенә, Гыйният Сибгатуллин ярлы гаиләдә туган. Аларны бер фактор берләштерә: Гариф Рәшитов мулла булган, ә Гыйният Сибгатуллин – мөгаллим, мулла. Нәтиҗәдә, шунысы билгеле: кулакларны сөрү сәясәте башланган көннәрдә, ягъни 1930 елның 1 февралендә, СССР ҮБК карары буенча, дини оешмаларның җитәкчеләрен урыннарыннан алу, оешмалардан чыгару таләп ителә. Бу карар кулакларны куу белән бер вакытка махсус туры китерелгән булып чыга. ■

Малмыж татарлары телендә мари атамалары

Илнур Газизуллин

Күпьеллык күзәтүләр нәтиҗәсендә туган мәкаләмнең исеме, мәгълүм әйтемдәгечә, җисеменә туры килә. Беренчедән, бу язма шәхси карашны, ягъни Малмыж татарының җирле мариларны ничек күзаллавын чагылдыра. Биредә тупланган мәгълүмат укучыга кызыклы һәм мавыктыргыч булыр дип өметләнәбез. Бәлки, бу мәкаләдәге кайбер фактлар галимнәрнең дә игътибарын җәлеп итәр һәм алар аны тарихи-этнографик чыганак булара кулланырлар.

Чүмкәле мари хатыны

Яңа Смәил татарлары телендә марилар

Туган авылым Киров өлкәсенең Малмыж районындагы Яңа Смәил авылы 1917 елга кадәр Вятка губернасының Малмыж өязендәге Сәрдекбаш волостена караган. Риваятьләргә ышансак, безнең авыл халкы моннан 300 ел чамасы элек хәзерге Балтач районында урнашкан Смәел авылыннан күченеп килә. Без ул авылны «Иске Смәел» дип атыйбыз.

Авылларның Балтач ягындагысы – «Смәел», ә Малмыж төбәгендәгесе «Смәил» дип языла. Авылда исә [э̕смәйэл] диелә. Сүз башындагы тартык аваз алдына сузык аваз кушылу татар теле фонетикасына хас закончалык. Җирле марилар бу сүзне үзенчәлекле итеп, тарихи яктан караганда дөресрәк әйтәләр: [исмәил]. Башында [и], уртада [ә] чиста итеп, нәкъ безнеңчә – татарча әйтелә, ләкин [йэ] урынына ба-

сым белән [и] әйтелә. Һичшиксез, бу авыл атамасының борынгырак варианты була ала, аңлашылганча, марилар телендәге әйтелеш Исмәгыйль исеменә бик тә якын тора. Ә менә урыслар «Смаиль» дип атыйлар һәм язалар. Смәел атамасы урысча «Измаил» да, «Смаил» да булырга мөмкин. XVI гасырга караган урыс кульъязмаларында, мәсәлән, Мәскәүнең Нугай Урдасы морзалары белән алышкан хатларында, Исмәгыйль морзаның исеме Измаил, Смаил, Исмаил дип бирелә.

Бу якта яшәгән халыкның этник һәм дини составы бик чуар. Монда казан татарларының Малмыж-Чепья төркемчәсе, мөселманнар, керәшеннәр дә бар. Урыслар да бик күп, шулай ук староверлар да шактый яши. Биредә болын як марилары һәм удмуртларның көньяк төркеме дә көн күрә. Араларында борынгы диннәренә тугры калганнар – мәҗүсиләр дә бар.

Тарихи ядкярләргә дә искиткеч бай җир бу. Мәсәлән, биредә мари халкы өчен бик тә мөһим булган, аларның милли тарихларына мөнәсәбәтле авыллар һәм шәһәр бар: Акбатыр белән бәйле Зур Китәк, Балтуш кенәз белән бәйле Малмыж шәһәре, борынгы Азелино археологик культурасына тоташкан Азелино авылы (татарча – «Үҗәл»). Хәзер урыслар яши торган Азелино авылы атамасы, һичшиксез, мариларның борынгы бабалары белән бәйле була ала.

Шәхси күзәтүләрдән чыгып, биредәге марилар турында кайбер мәгълүматларны бүлешәсем килә.

Балачакта малайлар белән урам сугышларында марилар һәм удмуртлар, нигәдер, безгә, татарларга, каршы берләшә иде. Бу хәл мине нык гаҗәпләндерде, шуңа истә калгандыр да инде. Соңрак кына аңладым: алар үзара кардәш милләт – фин-угырлар икән бит! Шуннан соң җирле мариларга игътибар итә башладым һәм миндә аларга карата кызыксыну уянды. Балачактан һәр факт, хәтта иң вaклары да минем башта теркәлеп калган. Өстәвенә, безнең сыйныфның яртысын удмурт балалары алып торса, калган яртысын марилар тәшкил итте, ә татарлардан мин үзем генә идем. Шуңа күрә бу халыкларны «эчтән» өйрәнергә вакыт һәм мөмкинлек булды. Әмма аларның телләрен өйрәнә алмадым. Андый ихтыяҗ да булмады, чөнки безнең якта фин-угырлар үзләре татарча бик яхшы сөйләшә иде.

Безнең фикеребезчә, татар белән мари халкын күптәннән бик тыгыз җепләр бәйли. Этнологиядә әлеге мөнәсәбәтләрнең хәзерге көнгә кадәр өйрәнелгәне юк. Малмыж Смәиле дә, Балтач Смәеле дә – элеккеге мари җирләре.

Барлый башлагач, Яңа Смәил татарларының көнкүрешендә марилар белән бәйле терминнар шактый булуы ачыкланды. Без аларны берничә төркемгә бүлеп бирәбез.

Беренче төркем. Бу группадагы сүзләр-терминнар турыдан-туры мариларга карый һәм алар безнең авылда гына кулланыла яисә элек әйтелеп, хәзер инде онытылган.

«Чүмкә» – мари хатын-кызларының баш киеме яисә баш киеменең аерым детале. Ул яулык астыннан зур булмаган конус сыман булып күренеп тора, күбрәк кызыл җепләр белән чигелгән. Әле 1970 нче елларда аны кайбер мари хатыннары киеп йөри һәм татарлар аларны «чүмкәле әкәй» дип атыйлар иде. Марича термины «шимакш» булырга тиеш. Бу татарлар биргән атама түгелме икән? «Чүмәлә»дән, мәсәлән.

«Чирмеш инәсе» термины белән Яңа Смәил халкы иң зур энәне атый. Аның татар телендәге әдәби вариантта «камыт энәсе» дигән атамасы да бар. Бу сүздән соң күз алдына археологик казулар нәтиҗәсендә табылган борынгы зур энәләр килеп баса.

«Чирмеш чабатасы» дип зур һәм пөхтә булмаган әйбергә әйтәләр. Бу термин күп вакыт күчерелмә мәгънәдә кулланыла. Мәсәлән, балачакта язын резин итекләр белән куе балчык ерып йөри торгач, ул зур, килбәтсез кисәк булып аякка ябыша һәм без аны «чирмеш чабатасы» дип атый идек. Бу атама бездән шактый ерак – Удмурт Республикасының Балезино районындагы Кистем авылында яшәүче нократ татарларында да бар. Әлеге район марилардан читтә урнашкан, анда удмуртлар гына яши. Очраклы гына күренешкә бераз ачыклык та керде. Удмуртиядәге Кистем имамы Илмир Касыймов сүзләренчә, заманында, ә төгәлрәге, XIX гасыр ахырында алар авылының мулласы белән безнең авыл мулласы Мөхәммәдзыя Бәхтияров мәшһүр Түнтәр мәдрәсәсендә бергә укыган икән. Аларга бу атама шуннан килгәндер дип фаразлый алабыз.

Мари һәм татар халкы яратып кулланган тагын бер термин – *«көмешкә»*. Өйдә кудырыла торган бу эчемлек, гадәттә, ашлыктан ясала. Ислам дине катгый тыйганлыктан, татарлар беркайчан да аны үзләре ясамаган, әмма ут күршеләре мариларның сый-хөрмәтеннән баш тартмаганнар. Чыгышы буенча бу термин татарча «кудыру/перегонять» сүзеннән булырга тиеш, чөнки мари телендә «шолтырмыш» атамасы бар.

Балачактан тагын бер сүзтезмә хәтергә уелган – *«әкәй алкасы»*. Бу үзенчәлекле урман куагының кара нокталы кызыл төстәге җимешләре була. Күрәсең, ул мари хатын-кызларының нииндидер бизәнү әйберенә охшаган булгандыр. Әдәби татар телендә бу үсемлек «кабар агачы» дип аталса, русчасы – «бересклет бородовчатый».

Хәзер инде микротопонимнарга күчик. Безнең авылда һәм тирә-якларда мариларга кагылышлы урам һәм тау исемнәре бар. Мәсәлән, *«Китәк базары юлы»*. Хәзерге рәсми исеме – Школьная урамы. Мин моны 1896 елгы бабаем Хәбибрахман Шаһимәрдән улының сөйләвеннән беләм. Күрәсең, марилар яши торган Китәк авылындагы базар Яңа Смәил татарлары тормышында бик мөһим роль уйнаган. Алар моннан көндәлек кирәк-ярак алган һәм үзләре җитештергән әйберләрне саткан. Мәсәлән, минем бабай агачтан ясаган кисмәкләр һәм көянтәләр белән сәүдә иткән.

«Китәк тавы» – Зур Китәк авылы башындагы текә тау. Бу тау белән безнең авыл татарларының бик күп риваятьләре бәйле. Минем нәселгә мөнәсәбәтлесе аеруча шомлы. Китәк базарыннан кайтканда бабаемның абыйсы Әхтәм Шаһимәрдән улын таш белән башына бәреп харап итәләр. Бу вакыйга XX гасырның уртасында була.

Иске Йөрек татарлары телендә марилар

Икенче төркемгә Малмыж районына керә торган иң зур татар авылы Иске Йөрек халкының мариларга бәйле атамаларын кертергә мөмкин. Мин биредә 1970 нче елларда берникадәр яшәдем һәм үземне күпмедер дәрәҗәдә бу авылныкы дип хис итәм. Иске Йөрек авылы барлыкка килү турындагы риваятьләргә таянсак, татарлар килеп урнашканчы (XVI гасырда, Явыз Иван заманында булырга тиеш) бу җирләрдә марилар яшәгән. Җирле тарихчы Мөнир ага Әһлиев уйлавынча, соңрак аларның Малмыжга яисә Мари Малмыжга күченгән булулары ихтимал. Шулай ук бер өлеше килгән татарларга кушылган. Кушылмаганнары да татарлар белән тыгыз мөнәсәбәттә яшәгән. Шул сәбәпле, бу авылда да марилар белән бәйле терминнарны һәм риваятьләрне шактый гына табарга була.

Мәсәлән:

«Шадыр» – урам исеме. Аны авылның бер очы дисәк тә була. Риваять буенча, марилар Иске Йөрек авылының шушы җирендә яшәгән. Бу урам авылны урта җиреннән бик тирән һәм көчле чишмәле ерганак белән аерып тора.

«Мари нәселе» дигән сүзтезмә Иске Йөректә еш очрый. Һичшиксез, бу термин: «Марилар татарлар арасында ассимиляцияләнгәнме яки юкмы?» – дигән сорауга ачыклык кертә.

«Алан түре» – мариларның кичке уен үткәрә торган җирләре. Иске Йөректән чагыштырмача шактый ерак, 2-3 чакрым китеп, елга янында урнашкан урын ул. Риваятьтә сөйләнгәнчә, алар шау-шулы халык булган, ә татар-мөселманнарга, мөгаен, муллаларга бу гадәт бер дә ошамаган. Шунын өчен марилар үзләренең уеннарын Алан түрендә уздырганнар. Башка риваять буенча, Иске Йөрек авылы элегрәк шунда урнашкан була.

«Кама бабай» – Иске Йөрек авылы риваятьләрендәге легендар герой. Әйтелеше – [Къ-а(о)-ма]. «Ул менә бу чишмәләрне ерган», – дип сөйли иде аның хакында авыл халкы. Милләте буенча Кама бабай татар дип әйтелә. Татармы, әллә маримы – мәгълүм түгел. Безнең фикеребезчә, ул мари да була ала. Монда ике вариант бар, хакыйкать кайсысында – анысы безгә билгеле түгел. Камай исеме татарларда бар һәм безнең якта ул фамилия кебек сакланган. Мәсәлән, Камаевлар. Шуны да искә төшерик: тарихта нугайлардан чыккан Камай морза билгеле. Икенче фикерне алсак, монда элек марилар яшәгәнлектән, риваять, буыннан-буынга күчеп, алардан да кала ала. Шулай ук Кама елгасын да онытмаска кирәк. Ә бу исә борынгы фин-угыр топонимы дип санала. Мәсәлән, «Кама» сүзе удмуртларда Вятка елгасының борынгы атамасы. Татарларда исә «кама» дип аталучы җәнлек тә бар, русчасы – *«выдра»*.

«Кама чишмәсе» – гаять үзенчәлекле табигать ядкяре. Беренчедән, җир астыннан ургылып чыкканлыктан, аның агымы бик көчле. Галим Марсель Әхмәтҗанов сүзләренчә, әлеге чишмә Казан арты буйлап баручы бик зур җир асты елгасы булырга тиеш. Бик тә аномаль зона дип атар идем аны. Иске Йөрек халкы сөйләвенчә, бу җирләрдә, ягъни Кама чишмәсендә һәм бигрәк тә Алан түрендә кайчак сәер хәлләр дә булгалый. Халыкта аны «Шайтанлы җир» дип тә йөртәләр. Балачактан истә калган: аның җир астында кирпеч яисә таш белән гөмбәзләп тезеп ныгытылган базы бар иде. Мондый корылма ясау кешедән күп көч һәм чыгым сорый. Ә аны эшләүче һич кенә дә гади кеше була алмый. Ул ниндидер хакимлек көченә ия булырга тиеш. Бәлки, ул берәр кенәз, бәк, морза булгандыр. Мәсәлән, рус кулъязмаларында Камай Смильнев дигән нугай кенәзе искә алына, яисә ул җирле мари кабиләсенең башлыгы була ала.

«Чирмеш малае» – Чутайдан чыккан нәселдә үксез бала мәгънәсендә кулланыла. Бу атама ишетелгәч, ятим, тәрбиядән мәхрүм малай күз алдына килеп баса. Кайвакыт татар телен оныткан, сары чәчле балаларга шулай дип әйтәләр. Безнең авылда бу сүзтезмәне ишеткәнем юк, ә менә Иске Йөректә, күрше Чутай авылыннан чыккан кешеләрдән әлеге гыйбарәне еш ишетергә туры килә. Шулай ук Казан артындагы XVIII-XIX гасыр татар кулъязмаларында да бу атама очрый икән. ■

100 ел элек татар дөньясы: Сабан туйлары

Балалар көрәшенең кызган мәле

Зур Сабан туе

4, 7, 9 һәм 11 июнь көннәрендә бу елга кадәр күрелмәгән зур программада Сабан туе ясалачак.

Теләгән кешеләр Сабан туена акча белән автомобильдә яисә аэропланда бара алачаклар. Иртә белән Сабан туе Казанның үзендә башланып, сәгать 2дән соң Аркадия бакчасында булачак.

Казанның һәр бакчасында хозур урыннары ясалачак. Урамнарда кинематографлар уйналачак. Казан шәһәре бизәләчәк.

Сабан туена узышырга атларын алып килергә теләгән кешеләр рәхим итсеннәр. Алда килгән атларга кыйммәтле нәрсәләр биреләчәк.

«Татарстан». – 1922. – 1 июнь.

Яз бәйрәмен һәм Сабан туен уздыру хакында положение

4 июньдәге Сабан туе көне, якшәмбе көн, «Яз бәйрәме» итеп игълан ителә.

1. Бу көн ТатЦИКның Ачларга ярдәм комиссиясе, үзенең моңарчы эшләгән эшләренә хисап бирү белән бергә, Ачларга ярдәм фондына һәртөрле иганәләр җыячак.

2. Эшнең технический ягын һәм урыннарда күзәтү эшен Студентларның ачларга ярдәм комитеты алып барачак.

3. Оештыру расходларына кирәк булган кадәр акчаны Ачларга ярдәм мәркәз комиссиясе бирә.

4. Бәйрәмне алып бару һәм гомуми күзәтү эшен махсус Мәркәз комиссиясе алып бара. Комиссия мондый кешеләрдән гыйбарәт: Өлкә комитеты һәм Мәркәз башкарма вәкиле иптәш Мансуров, Ачларга ярдәм комиссиясе вәкиле иптәш Лаврентьев, Студентларның ачларга ярдәм комитеты вәкиле иптәш Дикарицкий, Кызыл яу (Кызыл Армиянең икенче исеме. – *Ред.*) вәкиле иптәш Панов, Татпрофсовет вәкиле иптәш Абрамов, Кантон мәркәз комиссары Зәбиров, Сәяси аң-белем тарату баш идарәсе вәкиле иптәш Сметанин.

5. Саф доходның 80 проценты – ТатЦИКның Ачларга ярдәм фондына, 20 проценты исә Студентларның ачларга ярдәм комитетының Казан шәһәрендәге гали мәктәпләрдә укучы студентларны тәэмин итү фондына тапшырыла.

6. Даими эшләрне эшләү һәм ашыгыч мәсьәләләрне хәл кылу өчен, Яз бәйрәмен уздыру комиссиясенең бюросы төзелә; бюро мондый кешеләрдән гыйбарәт: рәис – иптәш Мансуров, әгъзалар – Сметанин, Лаврентьев, технический секретарь – Студентларның ачларга ярдәм комитетының секретаре Серебрянников.

7. 4 июнь көнендә буш күңел ачу урыннары Мәркәз комиссия кулында була; комиссиянең рөхсәтеннән башка һичбер нәрсәне куярга, уйнарга мөмкин булмый.

8. Шәһәр буенча төн буе йөрергә мөмкин булачак.

9. Төрле язуларны җибәргән чакта Мәркәз комиссиясе ТатЦИК хозурындагы Ачларга ярдәм Мәркәз комиссиясе штамп һәм пичәте белән файдаланыр.

ТатЦИК һәм Ачларга ярдәм комиссиясе рәисе урынбасары Исхак Казаков.
«Татарстан». – 1922. – 1 июнь.

Әсбаплар җыю кампаниясе, уздыруның гомуми программасы

3 июньдә кич сәгать 5тә киләчәк көн өчен агитация хәзерлекләре башлана. Тиешле плакатлар, хитапнамәләр белән, автотранспорт һәм трамвайлар ярдәме белән, халык һәм балалар йортларының булышлыклары белән халык нөмаишләре ясала. Мәйданнарда күчмә митинглар ясалып, махсус номер газеталар чыгарыла. Һичбер төрле сборлар эшләнми. Гаскәр бүлекләрендә, фабрик һәм заводларда бәйрәмнең әһәмияте һәм аннан максуд турыларында хәзерлек докладлары бирелә.

4 июньдә сәгать 9да университет ишегалдында районнарга таралачак сборчыларның җыелышлары булып, алар шуннан районнарга таралалар. Шул ук вакытта балалар белән 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләре укучыларының университет алдындагы мәйданда җыелышлары булып, аннан «Русский Швейцария» бакчасына таба сәйраннары була. Анда көндез сәгать 2гә кадәр балалар туе, гуляние һәм ачык һавада уеннар ясала. Шәһәрдә иганәләр җыю, урамнарда һәм мәйданнарда сәяр концертлар ясала.

Көндез сәгать 2дә Аркадия бакчасында Сабан туеның һәм бик зур лоторейның беренче көне, олимпиада уеннары, узышлар һәм акча түләп аэропланга утырып очулар.

Кич сәгать 5тән башлап шәһәрдәге бөтен бакчаларда Областком тарафыннан махсус төзелгән программ буенча гуляние һәм концертлар. 7 июньдә, чәршәмбе көн, Аркадия бакчасында Сабан туе һәм лоторейның икенче көне. Җомга көн 9 июньдә Сабан туе һәм лоторейның актык көне.

«Татарстан». – 1922. – 6 июнь.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Истанбул мәктүбләре
(1912-1913)

Фатих Кәрими

Триполитания күренеше

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2022) санында.

23 нче мәктүб

Әнвәр бәк янында

Уңнан сулга: Рокыя Юнысова, Өммегөлсем Камалова, Тәүфикъ Наһид, Әнвәр бәк, Мәрьям Ягъкубова, Шәриф Әхмәд Җаниф. ***Фотосурәт 1913 елгы оригиналь басмадан алынды.***

Аман йа Рабби! Кеше белән кеше арасында никадәр фәрекъ *(аерма)* бар. Кулында 50 мең гаскәре, җитәрлек азыгы, мөкәммәл коралы булындыгы хәлдә һич рәтләп сугышмаенча Сәланикне *(Салоники шәһәре)* юнаннарга тәслим иткән *(биреп харап иткән)* вә шул сәбәпле төрек милләтенең намусын кырган, вә йөз меңнәрчә кешенең сәфаләтенә *(бозыклыгына)* сәбәп булган Тәхсин паша исеме зикер ителгәндә *(искә алынганда)*, һәммә кешенең чәһрәсендә *(йөзендә)* никадәр нәфрәт вә ачу галәмәте заһир булмакта исә, Төркия инкыйлабы вә Траблус сугышы вакытында зур каһарманлыклар күрсәткән Әнвәр бәк[1] исеме ишетелгән вакытта бөтен төрекләрнең йөзендә шул нисбәттән ифтихар вә мәгърурият *(горурлык)* галәмәтләре заһир була, һәркем аның исемен хөрмәт илә яд итә, һәркем аны күрәсе вә рәхмәт әйтәсе килә.

Әнвәр, Ниязи[2] – бу ике исем төрекләр каршында мөкатдәстер. Бу ике исем хәзергә кадәр пакь вә гали калмышлардыр. Хәтта инкыйлабны ясаучы яшь

[1] Әнвәр бәк (Исмәгыйль Әнвәр, 1881-1922) – сәясәтче һәм гаскәри. 1911-1912 нче елларда Италия-Төркия сугышында Триполитаниядә итальяннарга каршы хәрәкәтне җитәкли. 1912 елда Истанбулга килә, ә 1913 елның гыйнварында түнтәрелеш оештыруда катнаша. Әнвәр бәк – 1913-1918 нче елларда «триумвират» заманында Тәлгать паша һәм Җәмал паша белән берлектә хакимияткә килеп, Госманлы дәүләтенең Беренче бөтендөнья сугышына кушылуына карар биргән гаскәри һәм сәясәтче.

[2] Әхмәд Ниязи бәк (1873-1913) – чыгышы белән албанияле госманлы гаскәрие. 1897 елгы Төркия-Греция сугышында дан казана. Яшь төрекләр инкыйлабында (1908) роле зур. Әнвәр бәк кебек үк, Триполитаниядә итальяннарга каршы сугыша (1911-1912). 1913 елның апрелендә солтан сакчылары тарафыннан үтерелә.

Безнең мирас №6 июнь 2022

Әхмәд Ниязи бәк

Әнвәр бәк

төрекләр арасында исемнәре һич керләнмәенчә, хөррият вә игътибарлары халык күзендә һич төшмәенчә, әүвәлгесе кеби гали вә мөкатдәс булып калган исемнәр ялңыз шушы икесеннән генә гыйбарәт дияргә ярый. Яшь төрекләр партия низаглары илә берсен-берсе кимердекләре хәлдә, бу ике кеше, һичбер якка катнашмаенча, бөтен калыпларыйла ялңыз ватан вә милләт файдасына тырышканнар. Үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен искә төшермәгәннәр. Ватан файдасы өчен кайда барырга вә нишләргә кирәк булса, алар шунда барганнар вә шуны эшләгәннәр. Ниязи бәк Македониядә юнаннарга каршы бер четә *(ихтилал фиркасы)* тәшкил иткән[3]. Янә бер такым фидакяр каһарманнарны туплаган. Юнан гаскәренә һич рәхәт бирми, аларны кыра, йөдәтә, тынычлыкларын качыра. Юнан хөкүмәте Ниязи бәкне тере көенчә тотып китерүчегә – 150 мең, башын китерүчегә 100 мең франк мөкафәт *(бүләк)* бирәчәген игълан итә. Ләкин каһарман Ниязиның йомышында да юк. Үз эшендә дәвам итә.

Әнвәр бәк тә Траблус сугышында рух иде, бөтен мөҗаһидләргә җан бирде. Әнвәр исеме бөтен Африкага яңгырады. Әнвәр бәк – яшь бер офицер, Яурупа тәрбиясе күргән бер гаскәридер. Ләкин аның күңеле милләт вә ватан мәхәббәте берлән тулган. Аның хәяте халык хәяте берлән мөштәриктер *(уртактыр)*. Ул ватан мәнфәгате вә халык сәгадәте өчен үзен фида итәргә һәрвакыт хәзердер. Ул һичбер вакыт мөшкеллектән качмый, бәлки, кайда мөшкеллек чыкса, шунда барып җитә дә, иң алгы сафка чыга вә һәммә авырлыкларга каршы күкрәк киереп тора. Шуның өчен халык аны сөя, шуның өчен бөтен дуст вә дошманнары аны хөрмәт итәләр. Затән милләтләрнең тарихларына шәриф бирүчеләр, милләтләрнең барлыкларын вә яшәргә истигъдадларын *(сәләтен)* дөньяга күрсәтүчеләр ул – милләтләр арасын-

[3] Сүз 1897 елгы Төркия-Греция сугышы турында бара.

да шулай сирәк-сирәк кенә заһир була торган каләм, фикер вә кылыч каһарманнарыдыр.

Әнвәр бәк Траблустан *(Триполитаниядән, хәзерге Ливия)* Истанбулга кайтты. Аны зурлап каршы алмадылар, чөнки бәгъзе әсбаптан тулае *(кайбер сәбәпләргә күрә)*, хәбәр бирмәенчә шау-шусыз кайтты. Икенче тарафтан да сугыш фәлакәтләре *(фаҗигаләре)* сәбәпле, һәркемнең күңеле төшек. Шанлыклар, тантаналар ясауның вакыты түгел. Мәкаме хиләфәтнең *(хәлифәлек җиренең)* вә алты йөз еллык зур бер дәүләтнең намусына гаять авыр бер зарбә урылганлык *(зыян килү)* сәбәпле, һәркем матәм эчендә, кешеләрнең күзләреннән яшь акмаса да, йөрәкләреннән кан тама. Һәркемнең калебендә интикам *(үч алу)* хисе ташый. Шуларны бик яхшы белгәнгә күрә, Әнвәр бәк үзе дә тантаналы каршы алуларны кабул итмәгән булыр иде.

Траблус сугышы вакытында Әнвәр бәк җитәкчелегендәге мөҗаһид гаскәренең маршы

***

«Төрек юрду»ның мөдире Йосыф бәк Акчура вә мәзкүр мәҗмуганың *(әлеге журналның)* мөхәррирләреннән Казыйм Намы бәкләр илә берлектә без 14 нче декабрьдә, җомга көн иртә сәгать 10да Әнвәр бәк илә күрешергә киттек. Галата тарафында, Бишекташ мәхәлләсендә аның фатирына барып ишегеннән керүемезгә, безне вәкарьле вә кибар гына бер карт кеше каршы алды, Казыйм Намы бәк, бу зат Әнвәр бәкнең атасы дия, безне аның илә таныштырды. Урта катта безне бер бүлмәгә керттеләр. Эчтә гаскәри киемендә өч офицер сөйләшеп утыралар. Бунларның арасында иң яшь булган берсе Әнвәр бәк икәнлеген тану бик җиңел, чөнки аның рәсемнәре әллә никадәр журналлар вә газеталарда күрелгән иде.

Без кергәч тә, аякка торып, ачык йөз берлән кабул иттеләр. Утырдык. Таныштык. Сәламәт кайтуы вә шулкадәр бөек каһарманлыклары күрсәтүе илә үзен тәбрик иттек. Үзендә һич тәклиф-тәкәллеф юк. Гаять простой бер кеше. Африкада бер ел сугышып, бөтен дөньяга шөһрәт чыгарып кайткан бер кеше төсле кыланмый: «Әфәндем, шулай итү бурычымыздыр, бары бурычымызны гына үтәдек, тәбрик ителәчәк бернәрсә юк, хөсне тәвәҗҗеһеңезгә *(яхшы мөгамәләгез өчен)* рәхмәт», – ди.

Үтәдән-биредән бераз сөйләшкәннән соң, мин аңардан:

– Траблуслылар Төркиянең Италия илә мосаләхә *(солых)* ясавына ни күз белән карадылар, разый булдылармы? – дип сорадым.

– Юк, Италиягә тәслим ителүгә *(Италия хакимиятенә кучүгә)* анлар һич разый түгелләр, затән Италиянең эчкә таба кереп анларны забит итә алуы *(яулавы)* тиз генә була торган эш түгелдер, – дип җавап бирде[4].

Әнвәр бәкнең дидегенә күрә, җирле гарәпләрдә итальяннарга дошманлык хисе гаять нык җирләшкән, вә шуның өстенә, анлар шул бер ел дәвам иткән сугыш мөддәтендә *(вакытында)* сугышка бик өйрәнгәннәр, җирле халыктан тәшкил ителгән

[4] Сүз 1911-1912 елгы Төркия-Италия сугышы турында бара. Италия Траблусны (Триполитания, хәзерге Ливия) яулап алганнан соң, җирле халык Италия хакимияте урнашуына каршы көрәш башлый.

гаскәр кулында мылтык вә корал бик күп, хәтта үзләреннән пулемет фиркаләре төзелгән, тупны да бик яхшы истигъмаль итә *(файдалана)* беләләр. Хәтта траблуслылар үзләре янында калган төрек офицерларын вә солдатларын да җибәрмиләр. Италия моны белсә дә, бәйләнеп гарәпләрнең ачуларын китерергә теләми. Шул сәбәпле, бу гаскәриләрнең тәрбиясе өчен Төркия тарафыннан рәсми сурәттә күп микъдарда акча җибәрелеп тора икән. Итальяннар сугыштан тәмам арыган вә йончыганга күрә, эчкә кереп бөтенләй забит итә *(сугыша)* алуны хәзергә искә дә төшермиләр. Төркия илә ясаган рәсми мосаләхәгә *(солыхка)* канәгатьләнгәннәр.

– Соң траблуслылар шул рәвешчә озак яши алырлармы икән? – дидем.

Буңа каршы Әнвәр бәк:

– Яшәр өчен бары үлемнән генә курыкмаска кирәк. Үлемнән курыкмаган кеше яки милләт озак һәм рәхәт яши ала. Траблуслылар исә үлемнән курыкмыйлар, алар үлемне истихкар итәләр *(түбән күрәләр)*. Шул сәбәпле мин аларның яшәүләреннән әминем, – диде.

Ул шул сүзләрне сөйләгәндә бүлмәмезгә яңа бер кеше килеп керде. Штатский киемдә, башында фәс иде. Бу кешене: «Траблусгарептән *(Триполидан)* сабикъ *(элекке)* депутат Йосыф Шәтван[5] әфәнде», – дип таныштырдылар. Ул Әнвәр бәк илә моннан элек күрешкән икән. Бүген тагын килгән. Әнвәр бәккә шулкадәр хөрмәт күзе берлән карый вә шулкадәр самими хиссият гарыз итә ки, тәгъриф *(моны тасвирлау)* мөмкин түгел.

Ул да булмады, Әнвәр бәккә бер визитный карточка кертеп бирделәр вә: «Шаһзадә Габделмәҗид әфәнде[6] җибәргән, аның кешесе китерде», – диделәр.

Әнвәр бәк бик сөемле, бик простой гына рәвештә тагын безнең белән сөйләшүдә дәвам итте. Сүз солых мәсьәләсенә күчкән иде:

– Мин Чаталҗага *(Чаталджа – Истанбулга якын бистә, башкаланы яклауда мөһим стратегик урын)* барып, андагы истихкямнарны *(хәрби ныгытмаларны)* карап вә гаскәриләрнең әхвәлен өйрәнеп кайттым, хәзер гаскәриләрнең әхвәле бик яхшы, истихкямнарымыз *(кыләчәгебез)* исә ышанычлы бер хәлдә. Яңадан сугыш башлана калса, безнең муаффәкыятемез *(уңышыбыз)* бик өмидледер, әгәр дошманнарымыз безнең хәзерге хәлемезне аңласалар, уступкага китми чаралары юктыр, анларның гаскәриләре гаять арыган һәм гаскәриләренең иң яхшы кыйсме *(өлеше)* кырылып беткән, безнең исә сугышка һич кермәгән әллә никадәр яңа вә свежий гаскәремез бар, – диде.

Шул арада тагын безнең бүлмәгә кереп, Әнвәр бәккә: «Гадилия назыйры *(юстиция министры)* тарафыннан берәү килгән, Сезнең илә аерым күрешергә тели», – диделәр. Әнвәр бәк аны икенче бүлмәгә алып керергә кушты вә көтеп торуын үтенде. Бер арадан соң без дә, үзе берлән исәнләшеп, яныннан аерылдык.

Әнвәр бәкнең төсе вә кыяфәте гүзәл вә кыланышы садә вә тәкәллефсездер *(гади)*. Сөйләгән һәрбер сүзенең тугры вә самими икәнлеге әллә кайдан беленеп тора. Шул сәбәпле, аның берлән күрешү миндә бик яхшы тәэсир калдырды, вә, зан итәмен ки *(уйлыймын)*, башкаларга да шулайдыр.

Әнвәр бәк солтанның кардәшләреннән берсенең кызы илә нишанланган *(ярәшкән)* булса да, һәнүз *(әле дә)* никахлары булып өйләнгәне юк икән.

---

[5] Йосыф Шәтван (1868-1949) – гарәп чыгышлы госманлы сәясәтчесе. 1908-1912 нче елларда госманлы парламентында Триполитания депутаты вазыйфаларын башкара.

[6] Габделмәҗид әфәнде (соңрак – Габделмәҗид II, 1868-1944) – 1861-1874 нче еллардагы солтан Габделгазиз Iнең дүртенче улы. 1922-1924 нче елларда Госман нәселеннән соңгы хәлифә. Госманлы империясендә солтан титулын алмаган бердәнбер хәлифә.

Итальяннар Триполи (Траблус/Траблусгареп) шәһәрендә

Траблуста әсир төшкәннәр Неаполь шәһәрендә

Моннан соң үзенең янәдән Траблуска китү ниятендә булынып-булмаганлыгын вә шәех Сәнусинең хәрәкәте[7] ни хәлдә булганлыгын сорау күңелемә килсә дә, муафыйк күрмәдем. Ихтимал ки, мондый мәсьәләләр хакында ачык мәгълүмат бирүне тиеш тапмас дип зан иттем.

Газета мөхбирләре берлән күрешү соңыннан кешегә уңайсызлык бирә. Төркиянең Одессадагы консулы Гатыйф бәк илә мин газета мөхбире сыйфатыйлә күрешеп сөйләшкән вә визитный карточкамны үзенә биреп кем икәнлегемне таныткан һәм сөйләгән сүзләрен газетага язачагымны да белдергән идем[8]. Инде хосусый сурәттә ишетүемә күрә, үзенең сүзләрен газетада басылып чыгуына уңайсызлана икән. Хәлбуки, мин аның һичбер сүзен үзгәртмәенчә яздым. Ул сүзләрен канцеляриясендә берничә кятибләре *(сәркатибләре)* алдында сөйләде. Шулай сөйләнергә яраган сүзләрнең язылырга яравында да шөбһә юктыр. Мәга ма фиһ *(шуның белән бергә)*, кешенең уңайсызлыкка төшүенә сәбәп булу газета мөхбирләренең үзләре өчен дә уңайлы түгелдер.

Әнвәр бәк кебек бөек вә мөхтәрәм бер затның уңайсызлыкка төшүенә сәбәбият *(сәбәп)* бирү ихтималы булганлыктан, андый нәрсәләр сорарга вә сөйләгәннәренең дә бәгъзеләрен язарга муафыйк *(кирәк)* күрмәдем.

Текстны басмага КФУдагы Халыкара мөнәсәбәтләр институтының 3 нче курс студенты ***Азат Якупов*** *әзерләде.* ■

---

[7] Әхмәд Шәриф Сәнуси (Сәед Әхмәд әш-Шәриф бин Мөхәммәд әш-Шәриф бин Мөхәммәд бин Гали әс-Сәнуси, 1873-1933) – Сәнусия тәрикатенә нигез салучының оныгы. 1911-1912 нче елларда Италия-Төркия сугышында Триполитаниядә итальяннарга каршы мөселман отрядлары оештырып, көрәш алып бара.

[8] Бу вакыйгалар 3 нче мәктүбтә тасвирлана.

Без кем яки Бер китап тирәсендә уйланулар

Индус Таһиров, академик

Атаклы «Диване лөгатет-төрек» («Төрки телләр сүзлеге») авторы, XI гасыр башларында (1028-1029 нчы елларда) Караханилар дәүләте заманында Көнчыгыш Төркстанның Кашгар шәһәрендә туган Мәхмүд Кашгари (1101 елда вафат)

II. Монгол чоры.

Бәлки, моны чор дип тә атап булмыйдыр, чөнки ул тарих өчен әллә ни күп булмаган бер-ике буынның гомерен генә тәшкил итә. Тик менә ничек кенә булмасын, ул елларны әйләнеп үтү мөмкин түгел. Чөнки бу – татарларның, тарихи бөеклектән коллык упкынына төшеп, фаҗиганең дә фаҗигасен кичергән еллары.

Ләкин монысына, хөрмәтле укучыларым, аз гына соңрак тукталырбыз. Ә хәзер исә сүз әнә шул җиңелү турында булыр.

Татарларның бөеклек чоры Чыңгыз ханның кытайлар ярдәмендә татар ханы Муджин Султуны җиңеп, аның үзен үтереп, бик күп татарларны кыруы белән тәмамлана. Шуның белән татар тарихының монгол чоры башлана.

Бу чорны татар-монгол мөнәсәбәтләрен ачыкламастан дәвам итү мөмкин түгел, чөнки күп вакыт татарларны монголлар белән бутап, аларны бер кавем

Ахыры. Башы журналның 5 нче (2022) санында.

итеп күрсәтә килделәр. Ләкин бу һич кенә дә дөреслеккә туры килми. Әгәр дә алар бер кавем булсалар, Чыңгыз аларга карата коточкыч, башка сыймаслык вәхшилек кылган булыр идеме? Юк, әлбәттә, юк!

XI гасыр филологы Мәхмүд Кашгари татарларны 20 төрки кабилә арасында күрсәткән. Ул, алар, печәнәкләр, башкортлар, кыпчаклар һәм кыргызлар кебек үк, төрки телдә сөйләшкәннәр, дип язган. 1160-1223 нче елларда гомер кичергән гарәп тарихчысы Ибн-Асир язмаларында да татарлар төрки кабиләләр арасында.



Фарсы дәүләт эшлеклесе, табиб һәм галим Рашидеддин Фазлулледдин Хәмәди (1250-1318) һәйкәле (Иран)

Монголларның «Сокровенное сказание»сендә татарлар һәм монголлар килешә алмаслык дошманнар дип язылган. Бу, чыннан да, шулай булган.

Баштарак боларның икесе арасындагы бәрелешләрдә татарлар өстен чыгалар. Җиңелүчеләрне хәтта кара татарлар, дип тә атый торган булганнар. Инде моңа кадәр искә алынган Рашидеддин үз язмаларында татарларның башка кабиләләрдән үзләренең бөеклекләре белән аерылып һәм монголларның да хуҗалары булып торганлыкларын күрсәтә[1].

«Көнчыгыш илләренә сәяхәт» китабы авторы, монах, сәяхәтче Рубрук Вильгельм де Гильом (1215-1220 нче еллар – якынча 1270)

Тарих тәгәрмәче төрлечә әйләнә. Әгәр моңа кадәр монголлар татар хакимлегендә яшәгән булсалар, Чыңгыз ханнан башлап, киресенчә, татарлар үзләре аларга буйсынып яши башлыйлар. Алай гына да түгел, Чыңгыз татарларның арба чәкүшкәсеннән биегрәк булганнарын бөтенләй юк итәргә кушкан була. Эш хәтта йөкле хатыннарның эчләрен ярып, балаларын алуга кадәр барып җитә. Ләкин, дип язган шул ук Рашидеддин, бу әмер үтәлми кала[2]. Татар кабиләләренең шактые качып котыла, калганнары монгол гаскәренә кушыла. (Бәлки, Зәки Вәлиди күрсәткән татар кабиләләре нәкъ шул вакытта һәм шул сәбәпле Казан тирәсенә килеп урнашканнардыр.)

---

[1] Рашид-ад-дин. Сборник летописи, т.1, кн.1. – С.78.
[2] Шунда ук, с.305.

Философ, тарихчы Эдуард Сәлмән улы Кульпин-Гобәйдуллин (1939-2015)

Татарларны монголлардан бик яхшы аера белгән көнбатыш сәяхәтчесе Вильгельм Рубрук язганча, Чыңгыз походларда һәрвакыт татарларны алдан җибәрә торган булган һәм: «Әнә татарлар килә!» – дигән аваз һәрчак яңгырап торган. Шунлыктан «татар» исеме янә киң тарала башлаган. Әйе, нәкъ борынгы замандагы кебек!

Монголлар кыпчак далаларында, Болгар илендә, төркиләр камалышында калалар. Шушы камалыштагы йогынты хәтта Чыңгыз нәселенең үзен дә әйләнеп үтми. Алтын Урда ханнары да татарлашалар.

XIV гасыр авторы Әл-Гомәри азчылык тәшкил иткән монголларның тиз арада төрки күпчелеккә сеңеп беткәнлеген ошбу сүзләр белән белдерә: *«Борынгы заманда бу дәүләт Кыпчак иле булган, ә инде аны монголлар яулаганнан соң, кыпчаклар алар кул астында калдылар. Аннан соң монголлар кыпчаклар белән аралашып туганлашып беттеләр һәм җир аларның табигый һәм раса сыйфатларын җиңеп, үзенең өстенлеген раслады. Шуннан соң алар, бер нәселдән диярсең, нәкъ кыпчакларга охшаш булдылар»*[3].

Үзбәк хан заманында Алтын Урдага килгән гарәп авторы Ибн-Батута, хан, үзе монголча белсә дә, кыпчак телендә сөйләшә, дип язып калдырган. Аның күзәтүенчә, хан тирәсендәге югары катлам монголлар да төркиләрнең гореф-гадәтләрен үзләштереп, төркиләшеп беткән булалар. Бу процессны Үзбәк ханның исламны дәүләт дине итеп игълан итүе дә тизләштерә.

Күренекле тарихчы Э.С.Кульпин үзенең тикшеренүләре нәтиҗәсендә, әгәр дә 1236 елны яки Батый ханның Көнбатыш походы башланган елны төркиләр һәм монголлар аерым этнослар булып башласалар, 1273-1291 нче елларда алар барысы да төркигә әвереләләр дигән фикергә килә.

III. Татар өр-яңадан бөеклегенә кайта.

Менә инде хәзер татар тарихының Алтын Урда чорына тукталыр вакыт җитте. Без шуннан чыккан татарлармы?.. Кыпчакларммы? Болгарлармы? Әйе, бу сораулар да җавап таләп итәләр.

Алтын Урданы Дәшти кыпчак дип тә атаганнар. Чыңгыз белән килгән татарлар һәм азчылык тәшкил иткән монголлар алар яшәгән дала киңлегенә чәчеләләр. Болгарлар да алар белән бергә шушы дәүләттә барлыкка килгән төрки казанда кайныйлар: тел, лөгать вә әхлак алмашып гомер кичерәләр. Шуның нәтиҗәсендә гомум «татар» атамасы өстенлек ала. Акрынлап боларның барысын да шушы исем белән йөртә башлыйлар.

[3] Шунда ук, 307 нче бит.

Ә тел? Алтай якларыннан килгән татарлар, болгарлар һәм кыпчаклар, төрки кабиләләр буларак, бер-беренә якын диалектларда сөйләшкәннәр. Ләкин аралашулар нәтиҗәсендә, кыпчак диалекты өстенлек итә башлаган. Шушы яңа рәвештәге татар теленең нигезе кыпчак диалекты була. Тик бу телнең формалашуында борынгы татар һәм болгар сөйләмнәренең дә өлеше аз түгел. Монысын да онытырга ярамый.

Алтын Урда дәүләте иксез-чиксез кыпчак далаларына ныклап нигезләнгәч, кыпчак теленең әһәмияте арта. 1340 елны Италиядә язылган бер китапта әлеге дәүләттә яшәүчеләрнең кыпчак телендә сөйләшкәнлекләре язылган. Европа белән үзара сәүдә мөнәсәбәтләре, гомумән, аралашу ихтыяҗы бу телнең әһәмиятен тагын да үстерә төшкән. Шунлыктан 1303 елда Италиядә «Codex Cumanicus» дип аталган кыпчак сүзлеге төзелә[4]. Шушы турыда язган Франческо Пеголотти Алтын Урдага баручы сәүдәгәрләргә куман (кыпчакларны куманнар дип тә йөрткәннәр) телен белүче тәрҗемәчеләр ялларга киңәш иткән.

Алтын Урдада кыпчак теленең тантана итүе хакында шул вакытларда язылган «Мәхәббәтнамә», «Нәһҗел-фәрадис» кебек әсәрләрнең шул телдә язылган булуы да раслый.

Алтын Урда чоры төрки тамырларыбызны бер казанда кайнатып, юкка чыккан бөеклегебезне кайтаруга сәбәп була.

Алай гына да түгел, татарлар, монголлар төзегән Алтын Урда дәүләтен үзләштереп, татар тамырының искиткеч көчкә ия икәнлеген исбатлыйлар. Э.С.Кульпин: *«Икенче буыннан башлап яки 1236 елдан шушы дәүләттә төп рольне төркиләр уйный башлый, ә өченче буын яшәгән 1273-1291 нче елларда алар илнең төп хуҗаларына әвереләләр һәм төп аралашу теле төрки булган кебек, төп культура да төркиләрнекенә әверелә»,* – дип яза. (Кара: Э.С.Кульпин. Золотая Орда: судьбы поколений. М.: Исан, 2008.)

Моны мин могҗизаның да могҗизасы дип атар идем. Э.Паркер кебек тарих чоңгылына ныклап күз сала алган галимнәр өчен бу могҗиза – объектив рәвештә барлыкка килгән катлаулыдан-катлаулы, каршылыклыдан-каршылыклы тарихи процесс нәтиҗәсе.

Тик совет җәмгыятендә моны күрсәтүгә дә табу салынган иде. Русиядә күп еллар буе безне татарлыктан биздерү сәясәте тантана итеп килде. Имештер, татарлар – Чыңгыз хан белән килгән явыз, кыргый монгол калдыклары. Алар, башкаларны талап, аларны үтереп, шәһәр-авылларын җимерүчеләр. Һәм иң әһәмиятлесе – рус дәүләтенең һәм халкының иң явыз дошманнары. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августындагы «Татарстан партия оешмасында агитация һәм пропаганда эшенең торышы» исемле карары менә шушы карашка нигез сала. Шуннан соң Алтын Урда дәүләте тик тискәре рәвештә генә күрсәтелә башлый. Партия диктаты хөкем сөргән заманда бу карардан, аның күрсәтмәләреннән читкә тайпылу гөнаһларның да гөнаһы, аларның да иң зурысы булып санала. Кая инде анда «Идегәй» дастанының 300 еллыгын үткәрү! Гәрчә Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан шул идеяне партия Өлкә комитеты үзе тәкъдим иткән булса да!..

Татар атамасы хурлыклы тамгага әверелә. Бигрәк тә безгә туганнан-туган кырым татарларын гаделсез рәвештә ил-җирләреннән сөргәннән соң.

«Юк, без монгол да түгел, татар да түгел, без – болгарлар. Безгә бу хурлыклы

[4] Шунда ук, 307-308 нче битләр.

атаманы тик кемнәрдер таккан гына!» Ни кызганыч, мондый авазларны әле дә юк-юк дигәндә ишеткәләргә туры килә.

Моның да сәбәбе шул ук – татарның тарихта бөек булырга хакы юк! Бу илдә һәрвакыт бер милләт кенә бөек булган һәм бөек булып калырга да тиеш!..

Нәкъ менә шуның өчен хәтта Алтын Урда һәм татарлар турындагы дөреслекне чамалы рәвештә генә биргән Карамзин, Соловьев, Ключевский кебек революциягә кадәрге тарихчыларга да урын тарая. Ә алар хакындагы тулы дөреслеккә омтылган В.Сергеевич кебек «Древности русского права» исемле әсәр тудырган галимнәрнең хезмәтләре бөтенләй онытыла дияргә була.

Ни өчен? Рус җирләрен җыючы рәвешендә күрсәтелеп килгән Иван Калитаның чын образын биргәненә күрә. Ул ханның иң турылыклы колы булганга. Бу сүзләремнең ышанычлы булуын дәлилләп, В.Сергеевичның әнә шул әсәреннән оригиналдагыча өзек китерәм: *«Рабская угодливость перед Ордой доставила Калите (1328) обладание великим княжеством, которое он занимал до своей смерти. В завещании он ни одним словом не упоминает о судьбе великого княжения по смерти своей. Это совершенно согласно с его раболепным отношением к Орде: великим княжением распоряжаются ордынские цари; Иван Данилович, их покорный слуга, это знает и в права владык своих не вмешивается»*. Сергеевич, бу грамотаның хан ризалыгы һәм аның раславы нигезендә язылганлыгын аның мөһере раслый, дип язган һәм болай дип өстәп куйган: *«Калита – добрый и зажиточный семьянин, которому хорошо жилось под властью ордынских царей. Ничего лучшего он и для детей своих не желал»*. Татарга тылмач кирәкмәгән кебек үк, әлеге сүзләргә дә бернинди өстәмә кирәкмидер дип уйлыйм.

Бу галимнең ошбу сүзләре дә бөекдержавачыларны рухландырырдай түгел. Аларны да мин, дөреслеккә хилафлык кылмау максатыннан чыгып, рус телендә бирәм: *«Северо-восточные княжения получили первое, но чисто внешнее объединение в 1238 году, по покорении их татарами. С этого момента возникло общее подчинение их ордынским ханам. В лице ханов впервые создалась высшая власть над всеми князьями Русской земли. Ханы не только распределяли столы между князьями по своему усмотрению, но и призывали их к своему суду и вольны были в их жизни и смерти. Татары, таким образом, явились проводниками начала объединения Русской земли под главенством великого князя Владимирского... Татарское завоевание оставило глубокий след в нашей истории»*.

Әйе, тирән эзләр, бүгенге тарихчы-политологлар Юрий Пивоваров һәм Андрей Фурсенко язганча, Алтын Урда чоры рус тарихының иң бай катламын тәшкил итә. Юрий Пивоваров үзенең шушы фикерен «Комсомольская правда» газетасының 2010 елгы 28 август санындагы «От кого взяло государство российское: от Византии или Золотой Орды?» исемле мәкаләсендә тагын бер кат кабатлаган.

Ләкин Ричард Пайпс әйткәнчә, рус тарихчылары бу турыда язарга ояла-лар. Чөнки дөресен яза башласаң, Александр Невскийның да шундый ук, үз мәнфәгатьләренә ирешү өчен үз туганын, хәтта улын да кызганмый торган кол икәнлеге, Дмитрий Донскойның Мамай белән бәрелеш вакытында куркуыннан гади сугышчы киеменә яшеренгәнлеге, Мәскәүгә Туктамыш ханның якынлашуын ишеткәч, ханнан куркып, шәһәрдән чыгып качканлыгы хакында да язарга туры килер иде. Дмитрийның Мәскәүдән чыгып качуының сәбәбен рус елъязмалары «убоявшись законного царя», дип аңлаталар. Ә законный царь яки кануни патша ул – Туктамыш.

Ләкин шул ук Туктамыш ханнан башлап татар янә бөеклектән аска таба тәгәри башлый. Үзара сугышлар, бер-берсе белән аңлаша белмәү Алтын Урданы эчке яктан кимерә. Һәм ахыр чиктә Алтын Урда бердәм дәүләт буларак таркала. Ә монысы инде, хөрмәтле укучыларым, аерым тема.

Шулай булгач, сүземне болгар тамырыбызга багышланган сүзләр белән дәвам итәм. Моңа бу хакта әледән-әле чыгып торган һәм бигрәк тә «Яңарыш» фонды барлыкка килгәч куерып киткән бәхәсләр төп сәбәп булып тора.

Мин бу фондның һич кенә дә татарларны «болгарлык»ка кайтару яки тик бүгенге Татарстан чикләренә генә бикләп калдыру максатыннан оештырылмавын ассызыклыйм. Мондый шикләнүләргә бернинди нигез дә юк.

Берәү дә Татарстаныбызны Болгарстан итеп игълан итәргә җыенмый. Фондның башында торган Минтимер Шәймиев тә, хөкүмәт җитәкчеләре дә. Аларның төп максаты – урта гасырлардан калган болгар хәрабәләрен элеккеге хәленә китереп, аларны Европа дәрәҗәсендәге мәдәният учагына әверелдерүдән гыйбарәт. Шунлыктан бу изге максатның вакыты-вакыты белән чыгып торган бәхәсләргә бернинди катнашы да юк.

Ә менә илдә 2010 елның октябрендә үткән халык санын алу кампаниясенә әзерләнүләрнең шаукымы тими калмагандыр, ахрысы. Чөнки 2002 елгы җанисәп вакытында да болгарчылык хәрәкәте үзен белдергән иде. Ул вакытта берничә йөз кеше үзләрен болгар дип яздырып, татарлыктан китәргә маташты.

Тик бит менә татарлыктан алай гына котылып булмый. Әгәр телең, гореф-гадәтләрең татарныкы, ата-бабаларың татар икән, син инде, кем булып язылуыңа да карамастан, татар булып каласың!..

Ни өчен? Чөнки татарның болгарлык чоры инде күптән үткән. Үткән эшкә салават, диләр халыкта. Бу, чыннан да, шулай. Бүген без инде күптән формалашкан татар милләте булып яшибез.

Моны болгарлыктан йөз чөерү дип атап буламы? Бу сорауга катгый рәвештә «юк» дип җавап бирергә кирәк. Ни өчен? Чөнки бу – динебезнең рәсми башы. Барлык уңайлыклары булган шәһәрләр кору, күпләрне таң калдыра килгән һөнәрчелек, җир эшкәртеп мул уңыш алу сәнәгате, заманча сәүдә итү, ислам культурасы һәм башка бик күп нәрсәләр болгар чорында барлыкка килгән. Болар барысы бергә ныклы тамыр җәеп, булачак татарлыкның нигезен салуга зур өлеш керткән.

Кол Гали, аның үлмәс «Кыйссаи Йосыф»ы, болгар чорының башка рухи ядкярләре һәрвакыт халык күңелендә һәм телендә.

Милләттәшенең җырын тыңлаганда Тукаебызның да күз алдына юкка гына Болгар һәм Агыйдел буйлары килеп басмагандыр. Күрәсең, шушы моң сөекле шагыйребезнең канына сеңгән тарихыбызны тоемлавы булгандыр. Ләкин Тукай һәрвакыт, горурланып: «Татар мин!» – дип әйтеп килгән.

Вакыты-вакыты белән безнең каныбызда болгарлык та кайнап ала һәм ул үзен сиздергәләп тора. Ләкин без – татарлар!

Э.Паркерның хезмәте тик Чыңгыз заманына кадәр генә булган чорны алса да, ул җыеп туплаган мәгълүматлар татарның алдагы бөеклекләрен ныклап аңлауга юл ача.

Без әле бүген дә кайбер тарихчыларның татарларны объектив рәвештә тасвирлаган хезмәтләренә тиешле игътибар биреп җиткермибез. Әллә инде вакыт җитми, әллә күңел күзе күрми… Ә күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе ботак тишеге, диләр…



Тарихи һәм фантастик китаплар авторы, И.А.Ефремов исемендәге премия лауреаты (2021) Александр Александрович Бушков (1956)

Укучыларымның игътибарын Александр Бушков исемле рус кешесенең шул хезмәтләр арасында аерым урын алып торган, Чыңгыз хан һәм ул төзегән империягә багышлап язган китабына җәлеп итәсем килә. (Чингизхан. Неизвестная Азия: М., 2007.) Аны күрмәмешкә салынучылар да, күреп тә, анда язганнарга ышанычсызлык белдерүчеләр дә булды. Бу рус кешесе монголларның Чыңгызга кадәр бернинди дәүләт төзү тәҗрибәсе булмавын һәм ул тәҗрибәнең тик татарларда гына булуын исбатлый.

Ул хәтта Чыңгызның үзен дә татардан чыккан дип исәпли. Безгә исә Чыңгызның чыгышы нинди булуы улкадәр әһәмиятле түгел. Анысы мәңгелек бәхәсле тема булып калсын. Безнең өчен бу авторның татарларның зур дәүләти тәҗрибәгә ия булганлыкларын раслый торган мәгълүмат туплаган, шуның белән Паркерның татар бөеклегенә багышланган язмаларына аваздаш булуында.

Ул да татарларны кыргыйлар итеп түгел, ә иң борынгы халыкларның берсе һәм хәзерге татарларны аларның дәвамчылары рәвешендә тасвирлый. А.Бушков Алтын Урданың башкаласы Сарайның, ышанычлы чыганакларга таянып, үз заманының иң гүзәл каласы икәнлеген күрсәтә.

Хәзер, Аллага шөкер, зур авырлыклар белән булса да, татарлар хакындагы дөрес тарих үзенә юл яра. Һәм Бушков китабы бердәнбер түгел. Алар хәзер дә бар һәм яңалары да язылып тора.

Хөрмәтле укучыларым, дөньякүләм танылган инглиз галиме Э.Паркер татарлар турындагы дөреслекне күрсәтүгә юл ачты. Аның хезмәтенең инде, ниһаять, безгә ирешүе очраклы хәл түгел. Чөнки без капчыкта ятмый, кайчан да булса аны тишеп чыга. Чын татар тарихы да шулай – гасырлар чоңгылыннан бүгенге көн яктысына ыргыла. ■

Рәфыйк Фәтхуллов: «Сабан туен татарны танытырлык итеп оештырабыз»

(Мордовия Республикасының Аксюн авылы эшмәкәре Рәфыйк Аяз улы Фәтхуллов белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

Рәфыйк Фәтхуллов

«Без иманлы әби-бабайларыбызга бурычлы»

– Һәр кешенең туган авылы – изге төшенчә. Авылдан булу сәбәпле, без кечкенәдән үк һәрнәрсәне белеп үстек, фикеребез ачык булды. Кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтен күрдек. Олыны – олы, кечене – кече дип белергә өйрәндек. Безне күмәк уеннар, соңрак хезмәт чыныктырды. Шәхеснең, аеруча ир кешенең формалашуында әтиләрнең һәм бабайларның да йогынтысы искиткеч зур.

– Аксюн авылында туып-үстем һәм туган җиремдә хезмәт итәм. Әни ягыннан Зәкәрия бабам авылыбызда озак вакытлар мулла булып торган. Әле дә яхшы хәтерлим: бабайлар, бер әбинең кечкенә генә ызбасына җыелып, җомга һәм гает намазларын, тәравих укыйлар, Коръән хәтем кылалар иде. Өйдә калган әбиләр дә намаздан аерылмады, уразасын да калдырмый тотты. Алар совет чорында да динебезне югалтмадылар, кыен шартларда да өмет белән алга карап

Аксюн авылы күрсәткече

яшәделәр. Аксюн авылында хәзерге көндә дин үсә, халык рухи яңарыш кичерә һәм хәзер мул, матур тормышта яшибез икән, без, иң беренче чиратта, шундый игелекле бабай һәм әбиләребезгә бурычлы. Алар динебезне безнең буынга кадәр китереп җиткерде.

Ә әтием ягыннан бабам Хәсән һәм аның туганы Бөек Ватан сугышында һәлак булган. Әтием Аяз 45 ел дәвамында Саранскидагы приборлар төзү заводында эшләде. Ул – хезмәт ветераны, шәһәрнең һәм авылның хөрмәтле кешесе булды. Картлыгын Аллаһка, дин юлына багышлады, көннәрен мәчеттә уздырды, халыкка дини йолаларны, вәгазьләрне оештырырга ярдәм итте. Аны кешеләр бик ярата иде.

Әнием Зәйтүнә исә озак еллар дәвамында резина заводында эшләде. Алар әтием белән Саранскида яшәделәр, ә аннары Аксюнга кайтып төпләнделәр. Әнием, Аллаһка шөкер, исән-сау. Аңа – 82 яшь.

«Авылыгыз югала, диделәр һәм мин эшкә тотындым»

– Хәзерге көндә җир һәм икмәк өчен борчылып йөргәнегезне күреп торам. Күп мәшәкатьләрне җиңеп чыгасыз. Кайдан көч табасыз?

– Без бит яшьтән хезмәт белән тәрбияләнеп үскән буын. Ун классны авылда тәмамладым. Укыганда утын әзерли, су китерә идек, йорт-хуҗалык эшләренең дә күбесе безнең өстә булды. Кешеләр һәрвакыт хәрәкәттә иде. Хәзер, Аллаһның рәхмәте, бөтен уңайлыклар бар – барысы да өйгә кертелгән. Армия хезмәтен Калининград өлкәсенең Неман шәһәрендәге «особый отдел»да үттем. Кооператив институтын тәмамлап, Инсар районында склад мөдире булып эшләдем. 1990 нчы елларда туган авылымда колхоз тарала башлады, аның 40 миллионлап бурычы бар иде. Шунда миңа район хакимияте башлыгы: «Әйдә, авылны

Аксюн авылының өченче мәчете

үз карамагыңа ал, авылыгыз тарала, кешеләре китә, тора-бара берни дә калмаячак, җиргә чын хуҗа кирәк!» – диде. Шулай итеп, колхоз рәисе булып эшли башладым. Соңрак «Юлдаш» крестьян-фермер хуҗалыгы оештырып җибәрдем. Хәзерге көндә 2400 гектар җиребез бар. Солы, арпа, бодай чәчәбез, елкы үрчетәбез. Үзебезнең колбаса цехы эшли, 27 төрле колбаса җитештерәбез, ит һәм кабырга ыслыйбыз. «Юлдаш» дигән кунакханә комплексыбыз, хәләл азык-төлек сата торган кибетләребез бар. Казан, Саранск һәм Ульяновск шәһәрләрендә без җитештергән азык-төлекне бик яратып алалар, чөнки барысы да хәләл һәм эшебезне намус белән башкарабыз. Аллаһка шөкер, дөньялар үзгәрде: хәзер һәр кеше хәләл ризык ашарга тели.

– Сез 2017 елда үзегез кебек эшкуарларны бер канат астына туплауга ирешкәнсез...

– Мордовиядә татар эшмәкәрләре клубы оештырып җибәрдек. Ул кырыкка якын авылда яшәүче эшлекле кешеләрне берләштерә. Без киңәшмәләр оештырабыз, колбаса һәм итләребезне күргәзмәләргә алып барабыз. Үземә дә якын-тирәдә эшләгән булдыклы татарларның тәҗрибәсе бик кирәк. Кемдер чимал җитештерә, кемдәдер куәтлерәк техника бар; Азюрканыкылар келәнгечләр фасовать итеп[1] базарга чыгара, Саранскида уңышлы эшләүче сәүдәгәрләр, базарларда ит сатучылар, төрле һөнәр кешеләре бар. Бер-береңне яхшы белгәндә, сәүдә урыннарында товарны алмашып саткан бизнес та нәтиҗәле эшли. Белгәнегезчә, хәләл кәсеп белән генә шөгыльләнәбез. Төп сатып алучыларбыз да – мөселманнар. Чиста, тәртипле, тәмле һәм намуслы рәвештә җитештерелгән азык-төлекне сатып алыр өчен, башка милләт һәм дин кешеләре дә безгә тартыла.

Аксюнның өченче мәчетендә авыл зыялылары, Рәфыйк Фәтхуллов һәм аның уллары белән күмәк фотосурәт

[1] Мордовия өлкәсенең Азюрка (Белозерье) авылында яшәүче милләттәшләребез көнбагыш үстерә. «Симәнке чирткәндә» тутырылган кабына игътибар итегез әле: ул шушы авылдан булыр.

Аксюн авылы мәктәбе

Аксюн авылы мәктәбе укытучылары белән

«Кем исламда – аның гаиләсендә алтышар олан[2] бар»

– Аксюнда өч мәчетне күрдем. Иң зурысы яңа гына төзелеп беткән дип аңладым, эшләре алгы ягында гына калып килә...

– Аллаһка шөкер, мәчетләребез яхшы гына эшли. Халкыбыз, аеруча бабайларыбыз бик тә кинәнеп йөриләр. Җомга, ифтар, тәравих һәм гает намазларында кеше аеруча күп була. Оланнарыбыз яшь вакыттан ук исламда икән, алар авылда кала, чөнки гыйбадәт кылырга мәчетнең якында гына булуы кирәк. Игътибар итегез: кемнәр исламда – аларның гаиләсендә дүрт-биш, кайберләрендә хәтта алтышар олан бар. Без моның белән горурланабыз!

– Авылыгыз елдан-ел тернәкләнеп, үсеп килә. Туган тел мәсьәләсе ничек куелган?

– Әлбәттә, мәктәптә башлангыч сыйныфтан алып 11нчегә кадәр татар теле һәм әдәбияты укытыла. Укытучыларыбызның барысы да татарлар. Узган ел гына авылыбызда өр-яңа мәктәп ачылды. Ул заманча итеп җиһазландырылган, белем алырга, динне, туган телне өйрәнергә барлык мөмкинлекләр дә бар. Хәзер авылыбызда юлларга асфальт салына, урамнар яктыртыла. Бөтенроссия федераль авыл Сабан туена да бик тырышып әзерләнәбез.

– Борынгы Аксюн авылында узачак Сабан туе татар халкын бар дөньяга танытыр дип уйлыйм.

– 2019 елда авылыбызның 350 еллыгын уздырдык, әмма Аксюнга 450 яшь дип әйтергә була. Риваятьләргә караганда, Әхсән исемле бабай җитәкчелегендәге 70 гаилә бергә килеп төпләнә. Авылыбыз шуның иseme белән Әхсән дип аталган, торабара Аксюнга әйләнеп киткән. Әхсән бабай бай, җир-суларга, мал-мөлкәткә ия кеше булган. Аның тырышлыгы белән авыл үскән, биредә яшәүчеләрнең дә саны арткан.

«Улларым Коръәннән өч җөзне яттан белә»

– Туган авыл өчен янып-көеп йөрү – бик изге гамәл. Әгәр дә гаиләң, тылың нык булса, шатланып-сөенеп, елмаеп йөрисең. Өйгә кайтсаң, тәмле аш, якты йөз каршы ала. Хатының белән әниең бер үк исемдә – икесе дә Зәйтүнәләр икән. Авылга кереп килгәндә улларың каршы алды.

– Хатыным Зәйтүнә – Азюрка авылыннан. Ул якта да татар халкы эшчән һәм булдыклы. Раушан һәм Дамир исемле улларыбыз бар. Аларның икесе дә югары белем

[2] Олан – углан, угыл, ул. Монда исә бала-чага мәгънәсендә.

алды, үз янымда эшлиләр. Уларыма теләсә нинди эшне ышанып тапшыра алам. Рамазан аенда мәчеттә берсе Коръән хәтем кылды, икенчесе тәравихны алып барды. Икесе дә Коръәннән өчәр җөзне яттан белә. Аллаһка шөкер, шуларга кинәнеп барам[3]!

– Амин, нәселегез шулай дәвам итсен! Без, Казанда яшәүчеләр, җиргә якынаю өчен, дача сатып алабыз. Үзебезчә һаман җирдә эшләргә тырышабыз, әмма анда хезмәтнең бетәсе юк, төзекләндерү эшенең дә очы-кырые күренми. Ә Сезнең кулда тулы бер авыл, аның хуҗалыгы. Тагын нинди планнарыгыз бар?

– Аллаһка шөкер, эшебез яхшы бара, әмма бу дөньяда иң мөһиме – саулык. Аллаһ ярдәме белән булганны үстерергә, техниканы ремонтлау өчен гараж салырга, эшчеләргә хезмәт шартларын яхшыртырга уйлыйбыз. Быел, Сабан туе вакытында, мәчетне тантаналы итеп ачарга ниятлибез. Аны бар күңелемне биреп, җан җылысы салып эшләттем. Аллаһка шөкер, мәчеткә керсәм, чыккы келәми[4], күңел иманга тартыла. Шунда ук дини укуларны да оештырып җибәрдек.

«Аксюн хезмәт кешеләре белән данлыклы»

– Мордовия төбәге татар әдәбиятына Габдрахман Әпсәләмов, Шәриф Камал, Һади Такташ кебек талантларыбызны биргән. Аксюн авылыннан дип искә алырлык нинди шәхесләр бар?

– Авыл хезмәт кешеләре белән данлыклы. Кемдер механизатор булып эшләгән, кемдер сыер сауган. Совет чорында бик күпләр Саранскига барып эшли иде. Араларында кранчы, төзүче, инженерлар бар. Авылыбызга иртән унбишләп вахта автобусы килеп, тырыш, булдыклы халыкны производствога эшкә алып бара һәм кичен кайтарып куя торган иде. Акыллы, эшлекле кешеләр авылыбызда күп. Районда, шәһәрдә җитәкче булып эшләүче милләттәшлеребез дә бар. Алар татарлар өчен бик күп игелекле гамәлләр башкарды. Аллаһка шөкер, әле дә бер-беребезгә ярдәм итәргә тырышабыз.

– Бөтендөнья татар конгрессы оешуга быел 30 ел. Аның сезгә йогынтысы, ярдәме бармы? Халык күңеленә кайсы шәһәр якынрак – Саранскимы, әллә Ульяновск, Мәскәү, Казанмы?

– Аллаһка шөкер, Татар конгрессы безне берләштерә. Күптән түгел генә татар эшкуарлары җыеныннан кайттык, инде менә дин әһелләре форумы булып узды. Казан – безнең рухи башкала. Конгресс җитәкчеләре Васил Шәйхразиевка, Ринат Зиннур улына һәм Данис Фәнис улына рәхмәтебез чиксез, алар безгә гел төпле киңәшләрен биреп тора. Үзем дә ел саен республика күләмендә «Авылым тавышлары» исемле фестиваль оештырам. Бәйрәмгә ике меңләп кеше җыела. Районнарыбызда да талантлы җырчы-биюче яшьләр бар. Фестиваль вакытында алар бер-берсе белән таныша, аралаша, соңрак үзара концертларга да йөриләр. Күптән түгел Ләмберәдә бик яхшы клуб ачылды, анда да татар мәдәнияте актив үсештә. Бу районда татарлар аеруча күп яши. Яшьләр Казанга төрле фестиваль һәм конкурсларга йөри, шунда белем алырга баралар.

– Татар халкын берләштерүдә Сабан туеның роле зур дип уйлыйм.

– Сабан туен яхшы итеп, татар халкын, Мордовия татарларын, Аксюнны бар дөньяга матур яктан гына танытырлык итеп үткәрергә тырышабыз. Халык җырмоңнарыбызны, артистларыбызны бик тә сагынып көтеп ала. Шул уңайдан Аксюнда зур төзекләндерү эшләре башкарыла. Сезне дә милли бәйрәмебездә көтеп калабыз.■

---

[3] Кинәнеп барам – куанып яшим.

[4] Чыккы келәми – чыгасы килми.

Ике тарихны бергә кушкан мәдрәсә

Ильяс хәзрәт Җиһаншин

Ильяс хәзрәт Җиһаншин шәкертләргә дәрес бирә.

Болгар иле – Идел буе җирлегендә Аллаһның Коръән аһәңнәре мең елдан артык туктамады. Бу җирләр бик күп вакыйгаларны күргән: су басуларны, корылыкларны, ызгыш-сугышларны, әрнеткеч зур ачлыкларны, тыныч елларны... Әлхәмдүлилләһ, биредә яшәгән газиз халкыбыз иман нурын күңел-калебләреннән чыгармыйча саклап килде, изге гамәлләрне буыннан-буынга тапшыра барды. Егерменче гасырда дәһрилек республикабызны да читләтеп үтмәде, әмма гыйлем чишмәсенең агуын туктата алмады. 80 нче еллар ахырында искән «йомшак җилләр» зур үзгәреш алып килде, динсезлекнең җансыз ташлары аша халкыбызның үзаңы калкып чыга башлады. Ата-бабаларыбыз иң авыр, изелгән вакытларында йөрәк бәгыреннән кан саркытып, әрнеп-әрнеп, күз яшен түгә-түгә: «Йа Раббым, балаларыбыз, оныкларыбыз, халкыбыз мондый авырлыкларны күрмәсеннәр иде!» – дип дога кылды. Шул догаларның нәтиҗәсе булып XX гасырның 90 нчы еллары башында Татарстанда мөселман өммәте кабат үсешкә юл тотты, яңа дини уку йортлары барлыкка килде, мәчет-мәдрәсә биналары мөселманнарга кайтарылды һәм яңалары төзелде.

«Кабан арты»ндагы рухи башлангыч

1991 елның 5 октябреннән Кабан арты мәчете каршында мәдрәсә ачылып, анда укулар башланды. Мәдрәсәне оештыручылар остаз Габделхак хәзрәт Саматов һәм мөдир Исхак хәзрәт Лотфуллин булды. 1992 елда республикабызда мөстәкыйль Диния нәзарәте формалашты. Аның җитәкчелеге Ислам динен кабул итүгә 1000

ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең эшчәнлеге белән кызыксынып торырга тырышты. Чөнки Диния нәзарәте оешу белән бергә, мәчет һәм мәдрәсәләр өчен имам һәм мөдәррисләр булдыру зарурлыгы көн кадагына куелды. СССР таркалып, традицион имамнар әзерли торган Бохара һәм Ташкент кебек үзәкләрнең Казан белән бәйләнеше өзелгәч, үзебезнең мәдрәсәләрне булдырып, аларны тиешле югарылыкка күтәрү өстендә эзлек-ле эш башланды. Ниһаять, ата-бабаларыбыз югалтмыйча безгә җиткергән дини мирасның кадерен аңлау чорына җиттек. Инкыйлабка кадәр эшләп килгән мәдрәсәләр тарихын, укытылган әсбапларны, программаларны һәм без йөри торган җирләрдән үз вакытында атлаган мәшһүр галимнәребез һәм шәхесләребезнең хезмәтләрен, әсәрләрен, тәрҗемәи хәлләрен өйрәнү, заманында көчле тарикать әһелләреннән булган ишаннарның рухи мираслары белән кызыксыну, дәфен кылынган каберләрен барлау башланды.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе үзенең башлангыч елларында икееллык белем бирү дәрәҗәсе белән эшләп килсә, 1993 елның 5 ноябреннән ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре советы тарафыннан бирелгән 21 нче шәһадәтнамә нигезендә дүртьеллык белем дәрәҗәсен алды. 1990 нчы елларның икенче яртысында мәдрәсә җитәкчелегенә аның элеккеге шәкертләре килде. Алар, мәдрәсәнең моңарчы урнашкан тәртип-йолаларына тугры калып, ата-бабаларыбыз мирасына нигезләнгән гыйлем учагын тергезү эшенә җиң сызганып кереште. Укыту программасына зур игътибар бирелде, шәкертләрнең тәтбикъ (практика) үтү мәсьәләсе җайга салынды.

Шул ук вакытта чишелмәгән мәсьәләләр дә күп булды: бүлмәләр җитми, булганнары ремонт күрмәгән, заманча җиһазландырылган аудиторияләр, китапханә, компьютер классы, шәкертләрнең тору урыннары уңайсыз иде. Тулаем әйткәндә, укытуны бер йодрыкка туплаган мәдрәсә оештыру турында уйлый идек.

Ал мәчет без кабул итеп алганда менә шундый хәлдә иде.

Мәчет-мәдрәсә комплексы. 2018 ел

Шәкертләр дәресләр җәдвәле белән таныша.

Ал мәчеттә рухи яңарыш

1997 елны «Мелита» мех АҖ үзенең санаторий-профилакторий урнашкан мәчет комплексы (элекке Ал мәчет һәм Якуб мәдрәсәсе) биналарын Татарстан хөкүмәтенә кайтарып бирү турындагы фикерен дин әһелләренә җиткерде. Әлеге форсаттан файдаланып, уку-укыту базасын киңәйтү ниятеннән, Мәҗит Гафури урамындагы тарихи биналарны мәдрәсәгә алу турындагы тәкъдим белән чыктык. Ал мәчет һәм 10 нчы мәхәллә мәдрәсәсе биналары, Казан шәһәре хакимияте башлыгының 1998 елның 1 июлендә имзалаган 1351 нче карары нигезендә, мөселманнарга кайтарып бирелде.

Шулай итеп, 1998 елда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе Кабан арты мәчетеннән Ал мәчеткә күчте. Мәдрәсә мөгаллимнәре, хезмәткәрләре һәм шәкертләре уку базасын булдыру өчен көне-төне ялсыз эшләде. Яңа урында булган авырлыкларга карамастан, уку елына әзерләнеп өлгердек. Октябрьдә укулар башланып китте. Дини һәм дөньяви фәннәрне укытырга югары белемле мөгаллимнәр чакырылды. Күптән көн кадагында торган китапханә проблемасы хәл ителде, компьютер классы җиһазлана башлады. Районнарның имам-мөхтәсибләре гошер садакасы белән булышлык итү нәтиҗәсендә, йөзгә якын шәкертне тәүлегенә өч тапкыр бушка ашату мәсьәләсе хәл ителде.

Яңа уку бинасына күчү үзен аклады. Укыту процессы төрләнде һәм тулы көченә алып барыла башлады. Эчке тәртипкә игътибар артты: мөгаллимнәр һәм шәкертләр өчен махсус форма булдырылды. Мәдрәсәнең абруе һәм даны артты. Ал мәчеткә күчкән икенче елны ук мәдрәсәгә керергә теләүчеләрнең саны, урыннар санына караганда, 2,5 тапкырга күбрәк иде. 2000 елда мәдрәсә бишь-

еллыкка үзгәртелде, укыту формалары һәм программалар яңадан каралды. Дини фәннәр белән бергә, гарәп һәм татар телләре, татар әдәбияты, татар халкы тарихы, информатика, хокук, физкультура һәм умартачылык дәресләре кертелде.

Шәкертләребезгә урын җитмәү мәсьәләсен игътибарга алып, хөкүмәтебездән Ал мәчет янындагы иске биналарны – Кызыл Татарстан урамындагы 3 нче һәм 3а йортларын мәдрәсәгә кайтарып бирүне үтендек. Бу бина җирләре инкыйлабка кадәр мәдрәсә комплексына кергән. Аллаһының ярдәме белән, Казан шәһәре хакимияте башлыгы карары нигезендә, биналарны мәдрәсә карамагына бирделәр. Матди авырлыкларга карамастан, өч ай эчендә анда мөгаллимнәргә гаиләләре белән яшәү өчен торак урыннар ясалды һәм беренче катта шәкертләргә спорт бүлмәсе булдырылды. Җирдән фундамент салып, өске ягын кирпечтән күтәреп, ярымай куелды, мәдрәсәнең территориясе матур тимер рәшәткә белән уратып алынды. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең карары нигезендә, М.Гафури урамындагы борынгы тарихи (10 нчы мәчет каршында төзелгән сәүдә лавкасы) бина – 65 нче йорт та мәдрәсәгә бирелде.

2013 елда Бөтендөнья Универсиадасы үткәрелү сәбәпле, Кызыл Татарстан урамындагы 3 нче йорт бинасы сүтелде. Кызыл Татарстан урамындагы кирпечтән салынган ике катлы бинаны саклап, агач өлешен сүтеп, түбәсен тулысынча калай белән яптык, нигезен ныгыттык. 2014 елда электр челтәренә турыдан-туры тоташу эшләрен башкарып чыктык. Шул ук елны мәчет-мәдрәсәнең фундаменты, керә торган баскычы бетоннан коелып ныгытылды. 2015 елда ишегалдына йөзгә якын агач утырттык. Шул ук елда, күп кыенлыкларны җиңеп, гомуми газ челтәренә тоташтык.

Балтачта мәдрәсәбезнең кечке бүлеге оешты. Аны район мөхтәсибәте һәм мәдрәсә арасындагы килешү нигезендә ачу насыйп булды. Мондагы укулар тулысынча Казандагы мәдрәсә программасы нигезендә алып барыла. Шәкертләргә, биредә укуны тәмамлагач, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә дипломнары тапшырыла.

2015 елда тарихи истәлекле ядкярләребезне халыкка күрсәтер өчен мәдрәсәдә музей оештырдык. 2016 елның Рамазан аенда мәдрәсәдә яңадан төзекләндерү эшләре дәвам итте. Уку залы булган китапханә ясап чыктык. Моннан тыш, уку классларына, коридор диварларына ремонт ясалды, түшәмнәр, идәннәр алмаштырылды, барлык бүлмәләргә затлы һәм нык ишекләр куелды, ашханә бүлмәсе җиһазландырылды, яңа компьютер классы булдырылды. Барлык су, электр һәм канализация челтәрләре заманча итеп үткәрелде. Боларның барысы да фәкать мөселман кардәшләребез булышлыгы аркасында эшләнде.

Янә дә мәдрәсә шәкертләренә урын җитми башлады. Кечке бүлектә ирләр һәм хатын-кызлар бергә укыйлар. Сыйныфлар кысан, 18 м^2, өч дистәгә якын кешегә утырырга авыр, суларга һава да җитми. Шәкертләребез, мөгаллимнәребез һәр намаз саен аерым мәдрәсә бинасы булсын иде дип дога кылалар иде. Нәтиҗәдә, 2017 елның декабрь аенда М.Гафури урамындагы 65 нче бинаны киңәйтеп, дүрт зур сыйныф бүлмәсе, ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым тәһарәтханә, өс киеме кую урыннарын булдыру өчен яңарту эшләре башланды. Шәкертләр үзләре дә яңа бинада уку сыйныфларын җыештыруда, уку җиһазларын урнаштыруда бик теләп катнашты. Аллаһы Тәгалә изге эштә ярдәмче: инде менә, мәдрәсәбезнең мактауга вә хөрмәткә лаек химаячеләре ярдәмендә, бу эшнең күркәм нәтиҗәләрен дә күрдек. Яңа бинада беренче дәресләр 2019 елның де-

кабрь аенда үткәрелде.

2021 елда мәчет-мәдрәсә комплексы өчен берничә күренекле вакыйга булды. 90 елдан соң гыйбадәт йортының михрабы торгызылды, фарыз залы, заманча төзекләндерелеп, киңәйтелде. Шул ук елны, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Готыф улы Әхмәтов ярдәме белән, мәчет бинасы тарихи ал төсен алды һәм умарталык 30 данә яңа оя белән яңартылды.

Шәкерт, мәдрәсәнең көндезге уку бүлегендә белем алгач, ахыргы курста авыл мәчетендә практика уза һәм диплом эше яклый. Аларга «Ислам белгечлеге» юнәлеше һәм «Ислам белгече һәм гарәп теле мөгаллиме» квалификациясе белән диплом бирелә. «Умартачылык» белгечлеге турында урта һөнәри шәһадәтнамә дә тапшырыла. Шәкертләрдән Коръән хафизлар әзерли башладык. 2021 елдан мәдрәсәдә тәравих намазлары вакытында Коръән Кәрим шундый шәкертләр тарафыннан хәтем ителә.

Мәдрәсә 30 ел эчендә барлыгы өч меңгә якын шәкерт укытып чыгарды. Аларның күпчелеге бүген, имам-хатыйблар булып, Татарстанның, Россиянең төрле төбәкләрендәге мәхәлләләрдә халкыбызга иман нуры тарата. Соңгы елларда Әстерхан, Ставрополь һәм Владивосток якларыннан килгән шәкертләрне тәрбияләп озаттык.

«Мәдрәсәбезнең тагын бер милли тәрбия мәйданчыгы – каберстаннарга булган игътибар. Без ел саен, 1998 елдан башлап, 2 май көнне Яңа бистәдәге Татар зиратында остазларны искә алабыз, каберләрен чистартып кайтабыз, иске ташларны эзлибез, өйрәнәбез, аларны хәлдән килгәнчә төзекләндерәбез. Монда җирләнгән күренекле шәхесләрне барлыйбыз.

Безнең мәдрәсә – Яңа Татар бистәсенең рухи-мәдәни үзәге

Моннан 24 ел элек Яңа Бистәгә күчү белән ике мәдрәсә тарихын бергә берләштердек. Дин иреге бирелгәч оештырылган беренче дини уку йортын һәм 200 еллык тарихы булган Якубия мәдрәсәсе традицияләрен кушу зур нәтиҗәләргә китерде.

Мәдрәсәбезнең тагын бер милли тәрбия мәйданчыгы – каберстаннарга булган игътибар. Без ел саен, 1998 елдан башлап, 2 май көнне Яңа бистәдәге Татар зиратында остазларны искә алабыз, каберләрен чистартып кайтабыз, иске ташларны эзлибез, өйрәнәбез, аларны хәлдән килгәнчә төзекләндерәбез. Монда җирләнгән күренекле шәхесләрне барлыйбыз. Мәсәлән, күптән түгел «Әл-Иткан» тәфсиренең авторы Шәйхелислам хәзрәт Хәмидинең, Габделкаюм хәзрәт Бадыйковның, Шаһиәхмәт хәзрәт Имәнкуловның, Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте, атаклы иганәче Мөхәммәдсадыйк Галикәевнең каберләрен табып төзекләндердек.

Мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин (уртада) галимнәр Наил Таиров (сулда) һәм Марсель Әхмәтҗанов белән

Мәдрәсәнең китапханәсендә ун меңнән артык басма бар. Соңгы елларда олы имамнар җыйган китапханәләрне мәдрәсәгә мирас итеп калдыру гадәткә керде. Әлхәмдүлилләһ, мәшһүр татар зыялылары бездә бик еш кунак кына түгел, алар бездә дәрес тә бирә, чәебез һәрвакыт кайнап тора, ашыбыз өлгергән – татар табыны милләттәшләребез өчен һәрвакыт әзер. Үзебезнең мәдрәсәне тәмамлаган татар эшмәкәрләре мәчет-мәдрәсәне тәэмин итүгә өлешләрен кертә. Галикәевләр, Әхмәревлар, Әҗемовлар кебек күренекле татар нәселләренең дәвамчылары белән элемтәдә торабыз. Мәдрәсәдә укулар, эчке рәсми кәгазьләрне язу татар телендә алып барыла. Бүген без мәдрәсәнең, мәхәлләнең тарихын тасвирлап чыктык дип әйтә алабыз. Бу тарихны шәкертләребезгә дә өйрәтәбез. Мәдрәсә музеенда күренекле имамнарыбызның шәҗәрәләре эленеп тора. Шәкертләргә дә нәсел агачын төзергә өйрәтүне мәдрәсәнең укыту программасына фән буларак та керттек. Шулай итеп, мәдрәсәбез тулысынча үз асылына кайтты – янәдән Яңа Татар бистәсенең рухи-мәдәни үзәгенә әверелде.

Әйе, эшләгән эшләребез бар, Аллаһка шөкер. Мәдрәсә үз яшәешен ун шәкерт һәм бер мөгаллим белән башлаган булса, хәзер биредә өч йөздән артык шәкерт (көндезге, кичке, читтән торып) белем ала. Аларга ике дистәдән артык югары белемле мөгаллимнәр сабак бирә. Ниятебез изге: җәмгыятькә хәерле һәм зыялы дин әһелләрен тәрбияләү, иншәАллаһ. Төп бурычыбыз хәзер бик тирән – дини һәм милли мирасыбызны өйрәнеп, аны саклап, исламга, милләтебезгә тугрылыклы булып алга бару, бу гамәлләребезне заманча вә алдынгы технологияләр белән баетып эшләү. ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

Сәйдәш Шәмсетдинов: «Эшебезне Аллаһка тапшырдык»

(Ульяновск өлкәсенең махсуслашкан медицина ярдәме күрсәтүче клиник үзәге хирургы, Россия Федерациясенең атказанган табибы Сәйдәш Миркасыйм улы Шәмсетдинов белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

РФнең атказанган табибы Сәйдәш Шәмсетдинов

«Бабай тәрбиясендә калдым»

– Сәйдәш әфәнде, әңгәмәне туган төбәкне, ата-бабаларны искә төшерүдән башлыйк әле...

– Буа районының Адав-Толымбай дигән авылында тудым. 1946 елда әтием Миркасыйм әнием Ркыя Исхак кызы белән гаилә кора. Шуннан бер-бер артлы аларның Рөстәм, Мәдинә, Сәйдәш һәм Нәҗия исемле балалары дөньяга килә.

Кызганыч, Наҗиябез 1955 елда вафат булды. Әти 39 яшендә бакый дөньяга күчте. Әнием Ркыя нибары дүрт класс белемле иде, гомер буе колхозда эшләде. Әтием Толымбайда башта – 7, аннары Кугальнада 10 классны тәмамлый. Аны Юридик институттан армиягә алалар. 1939 елда ул Фин сугышында була, шуннан Бөек Ватан сугышына китә һәм Волхов фронтында каты яраланып, 1944 елда туган авылына кайта.

Әтием фотога төшерергә бик яратты. Моннан тыш, аларның нәселе бик оста балта осталары: тәрәзә, ишек, шкаф һәм өстәлләр ясыйлар иде. Әтинең чоланда верстагы барлыгын яхшы хәтерлим. Бабам белән бергә алар бик күп эшләде. Әти үлгәннән соң, бабай тәрбиясендә калдым. Миңа бу вакытта нибары 7 яшь иде. Бабай мине күп һөнәрләргә – мич чыгарырга да, агач эшенә дә өйрәтте.

«Бер генә спектакльне дә калдырмый идек»

– Аллаһы Тәгалә Сезгә кешеләрне дәвалау бәхетен биргән...

– Әтинең иң кечкенә энесе Марат хирург булып башта – Апаста, аннары гомере буе Әстерханда эшләде. Мәктәпне бетергәндә ул миңа: «Фәкать мединститутка гына барасың, аның да лечебный факультетына! Хирург буласың!» – дип, киңәшен бирде. Аның сүзеннән чыкмадым. Авылда 8 нче сыйныфны тәмамлагач, Буадагы Вахитов исемендәге мәктәптә 9-10 нчы сыйныфларда укып, Казан медицина институтына укырга кердем. Студент вакытта бер генә спектакльне дә калдырмый торган идек. Төркемдәшләрем арасында язучы Роберт Мөхәммәдиев (Ринат Мөхәммәдиевнең энесе), Камил Исмәгыйлев, Рәис Хафизов, Нурия Хәсәнова кебек талантлы терапевтлар бар. Алар белән әле дә аралашып торабыз. Институтны тәмамлаганнан соң, мине Ульяновск шәһәренә эшкә озаттылар. Армия хезмәтендә танк полкында табиб булып хезмәт иттем.

Ульяновск хастаханәсенең бүлек мөдире, Россиянең атказанган табибы Нигъмәтулла Закир улы Сибгатуллин 59 яшендә инфарктан вафат булды. Шуннан

«Һәр операцияне дога белән башлыйм»

соң мине әлеге вазыйфага тәгаенләделәр. Шулай итеп, 33 ел дәвамында бүлек мөдире булып эшләдем. Хәзерге вакытта Ульяновск дәүләт университетының 5-6 курс студентларына госпиталь хирургиясе буенча белем бирәм. Зур, авыр операцияләр вакытында яшьләргә ярдәм итәм. Бу хастаханәдә бөтен хирурглар, табибларның күбесе – минем укучылар.

«Безне сыер коткарды»

– Сезнең турында: «Хирург от Бога», – диләр. Ульяновск өлкәсенең иң яхшы хирургы булып танылгансыз. Биредәге авырулар белән аралашканда да Сезнең хакта: «Иң талантлы табиб!» – дигән сүзләрне еш ишеттем. Шушы дәрәҗәгә ничек ирештегез? Бу нәселдәнлекме, максатчанлыкмы, үҗәтлекме яки эшкә мәхәббәтме?

– Әйткәнемчә, абыем Марат сүзеннән чыкмадым. Яшь вакытта башка туганнарыма ияреп агроном булырмын дип уйладым, спорт юнәлешенә дә кереп китү мөмкинлегем бар иде. Ул өлкәдә үрнәк булырлык шәхесләрне атап үтәм – абыем Сабирҗан Нәфыйков – танылган тренер. Заманында Розалин Бакиев, МДУ доценты Рафаэль Рәхимов кебек данлыклы спорт осталарын тәрбияләгән кеше ул.

Эшләп үстек. Әни, мескен, безне берүзе карады, кеше итте. Әле дә хәтерлим: аңа бер гектар чөгендер җире бирәләр иде. Мәктәптән кайткач, кырга китеп, караңгы төшкәнче шунда эшләдек. Җәйләрен печән өсте башлана. Безне сыер коткарды. Көнаралаш, иртәнге дүрттә торып, Буага сөт сатарга йөрдем: литры – 25 тиен, ә ипи 16 тиен тора. Сөт саткан акчага чират торып ипи сатып алам да яңадан 5 чакрым авылга – Толымбайга йөгерәм, чөнки дәресләр башланганчы мәктәпкә өлгерергә кирәк. Мәктәпне «5»ле билгеләренә генә тәмамладым. Акча җитмәгәнлектән, 1 нче курстан ук психиатрия хастаханәсенә эшкә урнаштым. 3 нче курска кадәр шунда эшләдем. Менә шулар барысы да үз эшемә җаваплы караш, тырышлык һәм үҗәтлек сыйфатлары тәрбияләгәндер дип уйлыйм.

«Толымбай – хирурглар авылы»

– Мәгълүм булганча, Толымбай авылы хирурглар белән данлыклы...

– Толымбай, гомумән, талантларга бай авыл. Язучы һәм әдәбият галиме Гомәр Толымбай, Буа театрының директоры Раил Садриев, космик өлкә белгече Эдуард Сәгъдиев – минем авылдашларым. Әйе, миннән башка, тагын Ирек Әхмәтҗанов, Ирек Камалов, абыем Марат, улым Альберт кебек танылган хирурглар да бар.

«Бу елларны күңелле вакытлар итеп искә алам»

– Ир кеше яхшы тылдан башка уңышка ирешә алмый. Бу җәһәттән хатыныгыз Клара белән танышу тарихын искә алып үтсәгез иде.

– Ул Мәдинә апам белән укый иде. Апам янына барып йөргәндә аның белән дә таныштым. Аннары Клара, химия-биология факультетын тәмамлап, Актаныш районының Сәфәр авылына балалар укытырга кайтып китте. Ике ел дәвамында аның белән хатлар язышып, аралашып яшәдек. Мин институтны тәмамлаганнан соң өйләнештек. Клара Ульяновскидагы кичке мәктәпкә химия укытучысы булып урнашты. Мин хәрби хезмәткә киткәндә ул йөкле килеш Толымбайда калды. Львовта дүрт ай хезмәт иткәннән соң, аны үз яныма алып килдем, аннары Жито-

Хатыны Клара, улы – булачак нейрохирург Альберт һәм хәрби табиб Сәйдәш Шәмсетдинов

мирга күчендек. 1975 елда улым Альберт дөньяга килде. Ике елдан соң яңадан шушы хастаханәгә кайттым.

Клара миңа гел ярдәм итеп торды. Аның бервакытта да каршы әйткәнен хәтерләмим. Яшь вакытта көндез – хастаханәдә, ә төннәрен ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасында эшли идем. Мәскәү, Петербург һәм Киев шәһәрләренә барып, озак вакытлар укырга туры килде. Бу елларда гаилә мәшәкатьләре тулысынча Клара өстендә булды. Ул – гаять төгәл һәм пөхтә кеше.

Актаныштагы бабай һәм әби (хатыны Кларaның әтисе белән әнисе. – *Ред.*) белән дә мөнәсәбәтләр бик яхшы булды. Аларга утын, печән әзерләү эшләрендә хәлдән килгәнче булыша идек. Бу елларны шулхәтле күңелле вакытлар итеп искә алам. Гомер менә шулай үтеп китте.

«Улым: «Чүкеч күтәреп йөрмим әле», – диде»

– Улым Альберт та табиб һөнәрен сайлады, дидегез...

– Улым мәктәптә укыганда ук: «Табиб булам!» – диде. Ульяновскида университет тәмамлады да: «Невролог булып, чүкеч күтәреп йөрмим әле, нейрохирург булырга, профессор Валерий Иванович Даниловта укырга телим», – диде. Шулай итеп, Казан медицина университетының неврология һәм нейрохирургия кафедрасында интернатура һәм ординатура тәмамлады. 2001 елдан бирле ул РКБда эшли, хәзер исә югары категорияле табиб-нейрохирург, медицина фәннәре кандидаты.

Дөрес, аның спортны сайлау мөмкинлеге дә бар иде. Альберт ун яшьтән бирле бокс белән шөгыльләнде. Ул 6 нчы курста укып йөргән вакытта Чаллы шәһәрендә бокс буенча Россия беренчелеге узды. Альберт шунда көмеш медаль яулады һәм спорт мастеры дәрәҗәсенә ия булды. Тренерлары улымны спорт-

ка җәлеп итмәкче иде, әмма ул: «Спортта үз урынымны таптым инде, хәзер хирургия белән генә шөгыльләним, кешеләргә ярдәм итәсем килә», – дип җавап бирде. Хатыны белән Кәрим һәм Әсгать исемле улларын үстерәләр.

– Һәр операциягә керер алдыннан дога укыйм, дидегез. Шуны тагын бер кабатлагыз әле...

– Бер генә операцияне дә догасыз башлаганым юк. Төнлә, ашыгыч операцияләргә чакырып алганда да, хатын: «Теге догаңны онытма!» – дип, кабат-кабат искә төшерә. Мин аны кечкенә вакытта ук әбиемнән өйрәнеп калган идем. Син дә исеңдә калдыр: «Хәсбүн Аллаһу вә нигъмәл Вәкил»*.

Җырчы Әлфия Авзалова Сембер татарлары янында. 2006 елның 15 ноябре

*Әлеге дога Коръән-Кәримдәге Әл-Гыймран сүрәсенең 173 нче аятеннән. Аның тулысынча тәрҗемәсе менә болай: «Бер кеше, ягъни Нүгайм сәхабәләргә хәбәр бирде: «Тәхкыйк, Кораеш җәмәгате сугышка әзерләнгән, бәс куркыгыз ул Кораештан», – диде. Бәс, (бу сүзләр) аларның иманын арттырды. Ягъни, Нүгаймнән бу сүзне ишеткәч, сәхабәләр камил тәвәккәл белән сугышка әзерләнделәр вә әйттеләр ки: «Ярдәм йөзеннән безгә Аллаһ җитәдер, ни хуш Вәкилдер. Эшебезне Аллаһка тапшырдык», – дип».

«Пушкин, давай, пас!»

– Сәйдәш әфәнде, Сез, хирург буларак, кешене эчтән яхшы беләсез. Эчке органнар сәламәт булсын өчен «Безнең мирас» укучыларына ниләр киңәш итәр идегез?

– Мин гел хәрәкәттә булуны яратам. 40 яшькә кадәр ишегалдында бала-чага белән туп типтем. Яшь вакытта чәчләрем көдрә иде. Урамда уйнаучы малайлар миңа «Пушкин» дигән кушамат тактылар. «Пушкин, давай, пас!» – дигән сүзләр безнең ишегадында еш яңгырап торды. Өйдәгеләр әйтүенчә, төннәрен дежурга калсам, малайлар: «Пушкин бүген чыгамы?» – дип, ишек шакыйлар икән.

Сезнең соравыгыз күршемне, хирург дустымны искә төшерде әле. Ул, табиб булса да, гел тәмәке тартырга, бәйрәм вакытларында салгаларга ярата иде. Нәтиҗәдә, инсульттан яшьли вафат булды. Шуңа күрә, сәламәт булыйм дисәң, иң беренче чиратта, начар гадәтләрдән арынырга кирәк. Икенчедән, кеше һәрвакыт хәрәкәттә булырга тиеш! Хәзерге вакытта һәр кичне хатыным Клара белән 10 мең адым атлап, саф һава сулап кайтабыз.

– Ходай Сезне сәламәтлектән аермасын!

– Амин. Менә инде мине бер авыру көтеп тора. Шуңа һәм аңа операция ясаучы шәкертемә ярдәм итәргә ашыгам... ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – язучылар һәм сәнгать әһелләре июнь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 июнь – рәссам, 1994 елдан ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы **Зиннур Миңнеәхмәт улы Миңнеәхмәтов**ка 75 яшь (1947);

2 июнь – актриса, Татарстанның атказанган (1996) һәм Татарстанның халык артисты (2012), Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылы тумасы **Фирая Барый кызы Әкбәрова**га 70 яшь (1952);

3 июнь – актриса, Татарстанның атказанган (1995) һәм Татарстанның халык артисты (2007), ТРның Әлмәт районындагы Габдерахман авылы тумасы **Гөлүсә Гомәр кызы Җамалиева-Гайнетдинова**га 70 яшь (1952);

4 июнь – шагыйрә, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1993), С.Сөләйманова (2014), Абдулла Алиш (2021) һәм Каюм Насыйри исемендәге (2022) әдәби премияләр иясе, 1985 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, ТРның Мөслим районындагы Симәк авылы тумасы **Эльмира Мөхәммәт кызы Шәрифуллина**га 75 яшь (1947);

6 июнь – актриса, Татарстанның атказанган артисты, ТРның Саба районындагы Чәбки-Саба авылы тумасы **Әлфия Якуп кызы Хәсәнова**га 70 яшь (1952).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Йанцзыцзян елгасы. Кытай

Пекинда Мәккәдән килгән бер сәйид[1] белән күрешү

Пекинда яшәгәндә мин беркөнне Мәккәдән килгән бер сәйид белән очраштым. Исеме Сәйид Хөсәен иде.

Бу шәхес ике ел ярым дәвамында Кытай иле буйлап сәяхәт иткән, көнбатыштан көнчыгышка таба, бер авылны калдырмыйча диярлек, йөреп чыккан. Әгәр сүзләре хак булса, ул менә нәрсәләр сөйләде:

«Мин Кытайның бөтен җирен гиздем. Бер-ике кич кунган яки берәр атна яшәп калган җиремдә гел өйләндем, 16 саф кыз никахымнан үтте. Мин боларның хәлләрен энәсеннән-җебенә кадәр беләм. Кытай мөселманнарында гомумән, намаз кабул булырлык итеп Коръән укый белүче кеше юк. Хатыннары, аякларын кечерәйтүләре аркасында, тәһарәт ала алмыйлар, чөнки андый аякка басып, кулларына авыр комган күтәрә алулары мөмкин хәл түгел.

Шулай булса да, илнең бөтен җирендә дә, кытай мөселманнарының дини ныклыклары гаҗәпкә калдырырлык. Дин хакына нинди генә фидакярлекләр эшләмиләр! Мәчет һәм мәдрәсәләре дә бик төзек. Бик кечкенә авылларда да, мәчет янында, мотлак, бер мәдрәсә дә була. Бу яклары белән хәтта безнең гарәпләрне дә уздырганнар, дип әйтә алам.

Боларның дин юлындагы бердәмлекләре дә мактауга һәм хуплауга лаек. Әйе, араларында дошманлашу аз түгел, ләкин дингә кагылышлы мәсьәләләрне

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Сәйид – Хәзрәте Мөхәммәднең (с.г.в.) нәселеннән дип саналган әфәнде *(тәрҗ.иск.)*.

хәл итәргә кирәк булса, шәхси дошманлыкларын шунда ук хәтерләреннән сызалар».

Мәккәдән килгән бу сәйидне, Кытайда ике ел ярым сәяхәт иткәннән соң, шушы кадәр булса да фикер әйтә алуы белән тәбрик итмичә булмый.

Кытайда чәчсез кеше

Пекинга якын гына урнашкан Ван-фан-чак дигән авылда чәчсез ике кешене очраттым. Боларны күреп аптырап калдым, чөнки Кытайда чәчсез кытай күрү мөмкин түгел.

Боларның берсе – Абдуррахман – гаять дәрәҗәдә дингә бирелгән мөселман кешесе, гарәпчә исеменнән башка исемен дә кабул итми. Икенчесе – шуның улы Юныс әфәнде, кытайча исеме Мәрдиян-чин икән.

Бу кешеләр белән танышканнан соң, чәчләрен ник кистергәннәрен сорадым. Юныс болай диде:

– «Руху-л-бәйан»да[2] язылганны укыдым. Ирләр хатыннар кебек бизәнергә-ясанырга тиеш түгел, дигән.

–Чәчләрегезне кайчан кистердегез? Кытайлар гаеп итмәделәрме?

–Чәч кистергәнгә өч ел булды. «Руху-л-бәйан»да язылганнарны укыгач, мин башта бу хакта атама әйттем. Ул шунда ук чәчен кистерде. Икенче көнне мин дә кистердем. Шуннан соң шәһәребездә кыямәт купты. Безгә бер яктан хөкүмәт кешеләре, икенче яктан голәмәбез ташланды. Аллаһының рәхмәте киң, нәтиҗәдә, бераз тынычландырдык, китаптан ул сүзләрне укып күрсәттек. Ниятебезнең сафлыгы коткарды безне.

Кешеләрнең рухи хәлләре бик гаҗәеп нәрсә. Менә мондый гади генә бер хәл миллионнарча адәм баласына ышану өчен үрнәк була. Шул ук вакытта, һич уйламаганда, шундый ук гади генә кешеләр тарафыннан ул ышану нигезеннән җимерелә дә ала. Гомумән, андый ышануларның нигезендә җаһиллек ята, ул аннары бер зәгыйфь кенә кешенең көчсез генә йодрыгы белән җимерелә дә.

Пекиннан китү

Пекиннан китәргә җыенам. Китәсе дә, ләкин юлга акча юк. Нишләргә? Иркутскидагы Шәйхулла әфәндегә хат язып, акча җибәрүен үтендем. Шул көннәрдә миңа бер төш керде.

Төшемдә яшь кенә бер кытай кешесе яныма килде дә миңа: «Сезне банкка чакырдылар, акча килгән», – диде. Мин, акчаны алырга дип, банкка бардым. Миңа дигән акча ниндидер бер дивармы, коймамы өстендә ята икән дим. Акчаның өстенә бер рус жандармы утырган. Шулай, ничектер, мин акчаны ала алмадым.

Төш лә инде, дидем, дөрес булмавы да мөмкин. Өметемне өзмичә, сабырсызлык белән акча көтәм.

Беркөнне иртән сәгать уннар тирәсендә бүлмәмдә утыра идем, бер кытай егете килде. Ник килгәнен аңлый алмыйм, ләкин егет үзе таныш кебек. Тәрҗемәче чакырдым да егетнең ник килгәнен сорадым.

Егет әйтә: «Сезгә хәбәр бирергә килдем. «Банкта 100 сум акчасы бар, килеп алсын», – диделәр».

[2] Исмаил Хаккы Бурсавиның (1725 елда вафат булган) Коръәне Кәрим аятьләрен аңлатып язган әсәре *(тәрҗ.иск.)*.

Минем ул көнне, ничектер, бер дә җаем юк иде. «Иртәгә килеп алырмын», – дидем.

Икенче көнне иртән банкка килдем. «Сезгә акча юк. Ялгыш хәбәр бирелгән», – диделәр. Миңа бу сүзләрне әйткәндә, банк хезмәткәренең йөзе бер агарды, бер кызарды.

Мин бик аптырадым. Кире кайтканда, күпме генә уйлансам да, хәбәрнең ялгыш булуын берничек тә башыма сыйдыра алмадым. Өйгә бик нык күңелсезләнеп кайтып кердем.

Шулвакыт берәр атна элек күргән теге төшем исемә төште. Кичә миңа хәбәр бирергә килгән егетнең ник таныш тоелуын да аңлап алдым. Ул шул төшемдә күргән кытай егете иде, ахры.

Инде банктан өметем өзелде. Сынаганым бар: төшләрем дә гел дөрескә чыгып тора. Бу акчаларга ни булса шул булды, бер чараң да юк, эзләп эзенә төшәрлек түгел. Инде Пекиннан китәр өчен башка чара табарга кирәк. Акчасыз ничек юлга чыгасың?! Мөфти Абдуррахман әфәндедән бурычка 50 доллар акча сорадым. Сәер инде, ул да таба алмады. Бичара, аннан-моннан җыештырып, 20 доллар бирде. Шул акчага ничек кенә булса да Пекиннан китәргә, дип карар кылдым. Җөмәдиәл-ахырның, ягъни июнь аеның ахырларында Кытайның пайтәхете Пекин шәһәреннән китеп бардым.

Банктагы рус хезмәткәрләренең икейөзлелеге

Акчаның миңа килеп җитмәве турында мин Шәйхулла әфәндегә язган идем. Ул әлеге рус-кытай банкының Иркутск бүлекчәсенә барган, акчаның барып җитмәвен әйтеп, кире бирүләрен таләп иткән.

Иркутск банк бүлекчәсе Пекинга җибәрелгән таләбенә: «Акча тапшырылды», – дигән җавап алган. Тапшырылган, ләкин кемгә тапшырылуы билгеле түгел.

Мин исә сәяхәтемне дәвам иттем. Инде Истанбулга килеп җиткәч, ягъни нәкъ бер ел узгач, Шәйхулла әфәнде миңа Пекин банк бүлекчәсеннән белдерү кәгазе алуын хәбәр итте.

Мин, шунда ук Пекинда яшәүче Али Рыза әфәндегә хат язып, акчаның кемгә бирелгәнлеген кабат банкка барып белешүен үтендем. Миңа җибәргән хәбәрендә Али Рыза әфәнде болай дигән: «Акча Сез Пекинда булганда ук килгән, ләкин андагы рус хезмәткәрләре, ниндидер бер сәбәп белән, Сезгә бирмәгәннәр, Сез киткәннән соң, Нуҗе мөфтие Абдуррахман Ван-Куан җәнапларына тапшырганнар. Абдуррахман җәнаплары акчагызны Сезгә җибәрәчәк».

Карагыз инде бу икейөзлелеккә! Минем кебек бер бичара сәяхәтчегә көн күрер өчен бирелгән шул акчаны тоткарлаганнар, кулыма килеп ирешүенә каршы төшкәннәр. Без сәүдә-акча йорты дип уйлаган ул банклар да җасуслык, ягъни шпионлык вазыйфаларын башкара икән ләбаса!

Мондый хәлнең беренче генә булуы түгел. Шундый ук вакыйга Йокохамада яшәгәндә дә булган иде. Анда да әлеге банкның бүлекчәсе шундый ук мөгамәлә күрсәтеп, инде килгән акчаны миңа тапшырмыйча, кире җибәргән иде.

Менә, мәдәният дигәнең шул дәрәҗәдәге икейөзлелектән гыйбарәт булгач, әйтерең бармы?! Нәкъ шулай, боларның гадәтләре бу, бик канәгать калганнардыр. Өнәмәгән кешеләренә аяк чалсалар, берничә көнгә генә булса да аларны тоткан юлларыннан тайпылдырсалар – бик шәпләп үч алган булалардыр инде, күрәсең.

Ханькоу

Ханькоу бик зур үзәк. Иң зур чәй фабрикалары да биредә урнашкан. Ханькоу диюгә, чәй искә төшә. Монда чәйнең бөтен төрләре җитештерелә. Кытай иле, гомумән, чәе белән шөһрәт казанган булса да, чәй Ханькоуда һәм аның әйләнә-тирәсендә җитештерелгән кадәр башка бер генә төбәктә дә җитештерелми икән.

Ханькоу Кытайның мәшһүр шәһәрләренең берсе булып тора. Пекин белән Ханькоу арасында бик төзек тимер юл сузылган, атнада өч сәфәр поезд йөри, ара – 754 мил[3]. Поезд төнлә бармый, бары тик иртән генә кузгала, көне буе бара да, төнгә туктап тора. Шул сәбәпле юлны өч көндә уза. Бу ике шәһәр арасында да мөселманнар яши торган шәһәрчекләр күп. Мөселман авылларының һәм шәһәрчекләренең һәммәсендә дә мәчет бар.

Мин Ханькоудан Шанхайга китәргә уйлыйм. Монда яшәп калып булмый да, чөнки кесәмдә сукыр бер тиен дә калмады. Бәрәкәт бирсен, анда рус-кытай банк бүлекчәсендә эшләүче Васильев дигән бер рус кешесен очраттым. Ике-өч көн шуның өендә яшәдем. Мәдрәсәләрдә куна калырга да мөмкин булыр иде. Тик кеше кайчакларда шулкадәр арый, хәсрәтләнә, берни күрәсе килми башлый. Ханькоуда мин бик арган хәлдә идем. Пекиндагы соңгы көннәремне авырып хастаханәдә үткәргәнгә, аннан киткәндә дә әле бик хәлсез идем.

Колның хәле Кодрәт каршысында буйсынып тез чүгүдән гыйбарәт. Бигрәк тә сәфәрләрдә, кулында акча да булмаса, ихтыяры калмый, теләсә дә, теләмәсә дә, үзен Кодрәт кулына тапшыра. Кеше үз язмышын күбесенчә менә шундый вакытларда раслый булса кирәк.

Мин дә үземне тулысынча Кодрәт кулына тапшырдым да, Ханькоудан Шанхайга кадәр җәяү барырга карар кылдым. Беркөнне иртән иртүк, сәгать алтылар тирәсендә, йөгемне җилкәмә салып – тырышлык билбавы билдә, тәвәккәл таягы



Ханькоу. 1910 ел

[3] 1,609 километрга тәңгәл юл үлчәү берәмлеге *(тәрҗ.иск.)*.

кулда, адым санагыч сәгать кесәдә – Ханькоу шәһәреннән көнчыгышка карап – табаннарга көч-куәт: «Мәдәт синнән, йа Рабби!» – дип, юлга чыктым.

Ханькоудан китеш

Шәгъбан аеның 3енчеме, 4енчеме көнендә Ханькоудан чыгып киттем. Мин җәяү йөрүдән армыйм да, туймыйм да. Кытай илендә гизүнең ысулларын да инде яхшы беләм. Юлларның тыныч, ышанычлы икәнен дә, куркыныч булмавын да беләм. Һөҗүм итә калса, шул бер бүре һөҗүм итәргә мөмкин. Аның да чарасын беләм. Һәрвакыт янында кечерәк бер капчыкта ап-ак туфрак йөртергә кирәк. Төнлә берәр җирдә ятып йокларга кирәк булса, әйләнәңә шул туфракны сибеп боҗра ясыйсың. Кеше шул боҗраның эчендә булганда, бүреләр аңа һөҗүм итми. Бу бик киң таралган ышану.

(Шуны әйтәсем килә: Кытайның бүреләре дә Аурупа кешеләреннән «мәдәнирәк», чөнки чикнең ни икәнен яхшы аңлыйлар.)

Ханькоу белән Шанхай арасы – 585 мил. Акрын-акрын барам. Юлда авыллар тезелеп киткән. Кытай илендә авыллар, гомумән, бер-беренә бик якын урнашкан. Авылларны үткәндә, карап калучыларның күплеге игътибарны җәлеп итә. Төркем-төркем булып озата баралар. Кайчак, авыл мәчете янынннан үтсәм, ишек төбенә барып утырып, бераз хәл алам. Шунда ук, мине күзәтергә йөзләрчә кеше җыела. Мөселманнар булса: «Мүслүмани! Мүслүмани!» – диләр, чөнки мыекларымның пөхтәләп киселгәнен күрәләр. Мәҗүсиләр исә: «Хой! Хой!» – диләр, сәгатьләр буе ияреп баралар. Бик гаҗәпләнеп сакалыма карыйлар.

Билгеле булганча, кытайларда сакаллы кеше бик сирәк очрый. Булса да, бездәге кебек сакал һич юк. Шул сәбәпле, сакалга бик аптырап карыйлар. Бу хәл авылларда гына түгел, башкала булган Пекин шәһәрендә дә нәкъ шулай төркем-төркем булып ияреп йөриләр иде. Өйнең урамга караган тәрәзәсе янында утырсам, йөзләп кеше тәрәзә каршысына җыела, урам үтеп йөри алмаслык хәлгә килә. Кайчакларда юри сәгатьләр буе утыра идем.

Тагын бернәрсә хәтерләдем: мондый кыргыйлык кытайларга гына хас дип уйласак, ялгыш булыр. Аурупа шәһәрләре булган Петербург һәм Мәскәүдә дә, әгәр бер кытай кешесе үз милли киемен яки берәр төрек кешесе фәс киеп йөрсә, шәһәр кешеләре артларыннан ияреп карап йөриячәк. Бүгенге көнгә кадәр илчеләребезнең Аурупада фәс киеп йөри алмауларының сәбәбе дә шул.

Моннан 30-40 ел элек, татарлар Петербургка килеп сәүдә капкаларын ачканда, әйләнә-тирәдәге руслар, 20-30 километр юл үтеп, шәһәргә нәкъ менә татар күрү өчен килә торган булганнар. Мәрхүм Ибраһим әфәнде Алишев бу хакта гел: «Кайчак шулай 20-30 кеше әйләнәбезне сырып ала да күз дә алмый карап тора», – дип сөйли иде.

35 елдан соң Пекинда шундый ук хәлләр була икән, монда гаҗәпләнер урын юк. Шул рәвешле, авылдан-авылга озатып баручылар белән бергә, сәяхәтемне дәвам итәм. Ул көнне кич җиткәнче бардым да бардым, адым санагычым 38 меңне күрсәтте.

Төнгә, мөмкин булган кадәр, мөселман авылларына туры килергә тырыша идем. Мәҗүси авылларында да тукталдым, ләкин чагыштырмача бик аз.

Шулай итеп, 11 көн буе бертуктамый җәяү барып, 586 118 адым араны үтү мине бик арытты. Аруым сәбәпле, анда күргәннәремнең күбесен теркәп тә куя алмадым. Авылларда мин бик сәер хәлләр күрдем. Йанҗийан (Йанцзыцзян,

Янцзы) елгасы яры буйлап барганда, бик сәер пристаньнар очраттым. Бик матур җирләр, манзаралар да күрдем. Кайчак тауларда кычкырып азан әйтә идем. Коръән укый-укый күпме ара үтә алуымны да ачыкладым. Бер җүз[4] Коръән укып, 3 километргa якын ара үтә идем. Һавалар бик рәхәт, эсселек 28-35 градус тирәсе була иде. Йанҗийан-Кингин елгасында юына, ара-тирә елга ярында ятып йоклый, йә ял итеп утыра идем. Авылларга килгәч, гел бала-чагага игътибар итә идем. Алар арасында мөселман балалар булса, минем йөземә, мыекларыма карап: «Мүслүмани, мүслүмани, лэйла, лэйла [Мөселман, мөселман, рәхим итегез]», – дип, мине туп-туры мәчеткә китерәләр дә: «Либэ йасы», – диләр иде. Мәчет дигән сүзләре.

Балалардагы бу хисслелек минем игътибарымнан һич читтә калмый иде. Алардагы сөенеч, лэйла, лэйла, дип чакырулары әхлакларыннан, хис-тойгыларыннан килә иде. Ул йөзләрендәге, күзләрендәге нурлы елмаюны күреп күңелем тула, елар дәрәҗәгә җитә, кайчак елый да идем. Бервакыт бер елга ярында ял итеп утыра идем, тамагым бик ачкан иде. Гаҗизлектән күзләремә яшь тулды. Якында гына, 13-14 яшьләрендә булыр, бер ир бала да бар иде. Карасам, ул да елый. Икебез арасындагы тәрҗемәче дә шул күзләребездән аккан яшьләр иде. Балалардагы бу табигый хисләр – һичшиксез, ислам әхлагыннан килә торган могҗиза билгесе. Ул сабыйларның хис-тойгылары миңа һәрвакыт бик нык тәэсир итә иде.

Мөселман авылларына кергәч, өйләрнең капкаларына гарәп хәрефләре белән язылган кәлимә-и тәүхид [лә иләһә илләАллаһ], йә мүфәттиха-л-әбваб [йә ишекләрне ачучы], бисмиллаһ-и шәрифә [бисмилләәһиир-рахмәәниир рахиим] игътибарымны җәлеп итә иде. Мөселман кешеләренең кибет ишекләрендә комган, тәсбих рәсемнәре булу, кытайлашкан кешеләрнең исламият аша үзләрен аерып күрсәтергә тырышуларына дәлил булып тора иде.

Кыскасы, исламиятнең хәйран калдыра торган әхлакый билгеләре аз түгел, боларны күрер өчен исә, инсафтан башка берни кирәкми. Аз гына инсафы булган кеше моны инкяр итә алмас.

Мин анда христиан кытайларны да күрдем, хәтта бик күп күрдем. Боларның балалары, Америкаданмы, бүтән илдәнме килгән башка берәр христиан кешесен күрсәләр, качалар.

Унбер көн эчендә мин монда бик зур мөселман шәһәрләреннән дә үттем. 4-5 мәчете, хәтта 10-20 мәчете булган шәһәрләр күрдем. Нанкин шәһәрендә, мәсәлән, 52 мәчет бар, араларында бик матурлары, бик төзекләре очрый.

Ниһаять, беркөнне Тайсу пристанена килдем, монда бер-ике көн хәл алдым. Бу пристаньнан көн саен бик матур япон кораблары китә һәм килә. Болар Ханькоу белән Шанхай арасында һәркөн почта ташыйлар икән. Бу кораблар Русиянең Идел елгасында йөри торган «Кавказ и Меркурий»[5] пароходларын хәтерләтәләр иде. Бик кечкенәләре дә бар. Елга кораблары барысы да японнарныкы.

Беркөнне иртән пристаньда торган пароходка кердем, хезмәткәрләрнең берсе белән таныштым. «Инде хәзер кая юл тотарга уйлыйсыз?» – дип сорады. «Шанхайга», – дидем. Ул миңа үз пароходлары белән китәргә тәкъдим итте. Беренче дәрәҗәле каютада урын бирәчәкләрен дә әйтте.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

---

[4] Җүз – гарәп телендә «бүлек» дигәнне аңлата. Коръәне Кәрим 30 җүздән гыйбарәт, һәр җүз 20 бит тәшкил итә *(тәрҗ.иск.)*.

[5] Революциягә кадәрге Русиядә 1849 елдан 1918 елга кадәр эшләгән пароходчылык компаниясе *(тәрҗ.иск.)*.

Ислам. Дини сүзлек

Кәгъбәтуллаһ

Кәгъбәтуллаһ – мөселманнарның Мәккәдәге изге йорты, Әл-Мәсҗид әл-Хәрам, ягъни изге мәчет, Аллаһ йорты. Ул соры таштан эшләнгән яссы түбәле, дүрт почмаклы бина.

Кәгъбәтуллаһның озынлыгы – 13, иңе – 12, биеклеге 15 метр чамасы. Ишеге мәйдан өслегеннән 2,5 метр биеклектә, шуңа күрә аның эченә баскыч куеп кына керергә мөмкин.

Кәгъбәтуллаһның почмаклары дөньяның дүрт тарафына карап тора. Көнчыгыш яктагысы «кара почмак» дип атала.


Кәгъбәтуллаһ

Кәгъбәтуллаһның бер як диварына тышкы яктан «кара таш» кертеп урнаштырылган. Кәгъбәтуллаһ тышкы яктан кисвә белән капланган.

Кәгъбәтуллаһның төньяк почмагы – «Гыйрак», көнбатышы – «Сүрия», көньягы «Йәмән» дип атала.

II гасырда ук грек географы Птолемей, Мокарәбәдә (Мәккә ул чакта шулай аталган) мәҗүси гарәпләрнең изге урыны бар, дип яза.

Риваятьләргә караганда, ул чагында бу изге таш койма белән әйләндерелгән туры почмаклы йорт булып, аның эчендә төрле кабиләләр аллаларының таштан ясалган потлары торган.

Мөхәммәд (с.г.в.) заманында инде ул ябык бина итеп эшләнгән Кәгъбәтуллаһны үз кулларына төшерү кораеш кабиләләре башлыкларының абруен сизелерлек күтәргән.

Хәзерге вакытта Кәгъбәтуллаһ хаҗ кылу урыны булып тора.

Кәгъбәтуллаһка ел саен хаҗ кылырга бару – ислам диненең төп нигезләренең берсе.

Хаҗ кылган мөселманнарны хаҗилар дип атыйлар.

«Кара таш» каршында изге Зәмзәм чишмәсе чыга.

«Ислам. Белешмә-сүзлек» китабыннан (1993, Татарстан китап нәшрияты) алынды. ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре[1]

Әхмәдвәли Рәхими

37

Габдулла бин Габбас разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Иләнмәгән чи тире, исе һәм нәҗес юеше бетерелсә, пакь булыр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

38

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең хатыны Сәүдә: «Куебыз үлгән иде, тирене иләдек тә тузганчы су салып йөрттек», – дип сөйләгән.

Укы һәм исеңдә калдыр!

39

Әл-Мөгыйрә бине Шүгъбә разыйаллаһу ганһү риваять итә: «Мин Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәлламнең ике читегенең заһиренә *(тышына)* мәсех[2] кылганын күрдем».

Укы һәм исеңдә калдыр!

40

Хүзәйфә разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Без адәмнәр өч сыйфат белән артык кылындык: 1) сафларыбыз фәрештәләр сафлары кебек кылынды; 2) җир йөзенең көлле *(һәр җирендә)* мәчет кылынды; 3) су белән тәһарәт алу мөмкинлеге булмаганда тәһарәт урынына чиста җир пакьләүче кылынды *(тәяммум)*».

Укы һәм исеңдә калдыр!

41

Ибн Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Җомгага килүче кеше госел коенсын».

Укы һәм исеңдә калдыр!

42

Гайшә разыйаллаһу ганһә: «Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам, миндә хәез *(күрем вакыты)* булганда, итәгемә таянып, Коръән укыйдыр иде», – дип сөйләгән.

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

[1] Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.
[2] Мәсех – тәһарәт алганда кул бармакларын суга чылатып, ике кулның өч урта бармагы белән читекләрнең өстеннән тубыкка кадәр сыпырып алу.

Текстны басмага ***Айсылу Вәлиева*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Уникенче дәрес

Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) атасы вә анасы. Атасының вафаты. Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) дөньяга килүе. Әминәнең вафаты. Габделмоталлиб тәрбиясенә күчүе. Аның вафаты. Әбү Талиб тәрбиясенә күчүе. Әбү Талиб белән Шәмгә баруы. Хәдичәгә өйләнүе. Хира тавында гыйбадәт кылуы. Аңа пәйгамбәрлек килүе

Мөгаллим: Бу вакытка кадәр мин сезгә берничә пәйгамбәр турында сөйләдем. Кемнәрне сөйләгән идем әле, Габдуллаһ?

Шәкерт: Адәм һәм Ибраһим пәйгамбәрләрне (г.с.) сөйләдегез.

Мөгаллим: Тагы кемнәр хакында сөйләдем?

Шәкерт: Исмәгыйль һәм Исхак пәйгамбәрләрне (г.с.) сөйләдегез.

Мөгаллим: Дөрес әйттең. Алар турында да азрак сүз булды. Ягъкуб исемле бер пәйгамбәрне (г.с.) дә телгә алып узган идем. Болардан соң да Аллаһы Тәгалә, бәндәләрен туры юлга күндерү өчен, пәйгамбәрләр җибәреп торган. Болар арасында Муса вә Гайсә исемле ике олуг пәйгамбәр (г.с.) дә булган. Хәзрәти Муса (г.с.) Гайсәдән (г.с.) күп вакытлар элек килгән. Ул да, хәзрәти Гайсә (г.с.) дә Ягъкуб пәйгамбәр (г.с.) нәселеннән булганнар. Алар икесе дә бәни Исраилгә, ягъни Исраил кавеменә җибәрелгән булганнар, ягъни Аллаһы Тәгалә аларга шушы кавемне туры юлга күндерергә кушкан булган. Аларның икесенә дә китап биргән.

Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) белән Исмәгыйль пәйгамбәр (г.с.) Кәгъбәтуллаһны бина кылганда нинди дога кылганнар дигән идек әле?

Шәкерт: Аллаһы Тәгаләдән үз нәселләреннән бер пәйгамбәр җибәрүне сораганнар, дигән идек.

Мөгаллим: Дөрес, шулай дигән идем. Бу пәйгамбәрнең безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) икәнлеген дә искә төшереп узган идем. Менә шушы пәйгамбәрнең (с.г.в.) килүе турында олуг пәйгамбәрләрдән хәзрәти Муса (г.с.) вә хәзрәти Гайсәгә (г.с.) бирелгән китапларда да сөенеч булган. Хәзрәти Гайсәдән (г.с.) соң 600 еллар узгач, бу Пәйгамбәр (с.г.в.) дә дөньяга килгән. Ул Пәйгамбәр (с.г.в.) Гарәбстан дигән мәмләкәтнең Мәккә дигән шәһәрендә туган. Анда гарәп кавеме дигән халык торган. Бу Пәйгамбәр (с.г.в.) дә әнә шул гарәпләрдән булган. Аның атасы – гарәпләрнең көраеш дигән кабиләсеннән. Аның исеме – Габдуллаһ. Ул кораеш кабиләсе бик зур, шәп, игътибарлы кабилә булган. Габдуллаһның атасы, ягъни пәйгамбәрнең (с.г.в.) бабасы кораеш гарәпләренә җитәкчелек иткән. Ул Габделмоталлиб исемле булган.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Габделмоталлиб, улы Габдуллаһ үсеп буйга җиткәч, аны Әминә исемле бер кыз белән ярәштергән. Әлеге Ибраһим пәйгамбәр (г.с), дога кылып, Аллаһыдан бала сораган һәм менә шул хәзрәти Әминәдән Муса (г.с.) вә Гайсә пәйгамбәрләргә (г.с.) бирелгән китапларда хәбәр ителгән Пәйгамбәр (с.г.в.) туган. Аңа Мөхәммәд исемен кушканнар. Ул туган вакытта атасы Габдуллаһ инде вафат булган. Ул карында гына калган. Алты-җиде яшькә җиткәндә, анасы да вафат булып, ата-анадан бөтенләй ятим калган. Моннан соң ул бабасы Габделмоталлиб тәрбиясенә күчкән. Габделмоталлиб аны бик яраткан. Иң сөекле улының баласы булу өстенә, аның киләчәктә олуг бер кеше булачагын аңлаган. Чөнки Мөхәммәд (с.г.в.) үзенең яшьтәшләренә бер дә охшамаган, бәләкәй вакытта ук олылар кебек акыллы, әдәпле, инсафлы булган. Габделмоталлиб кулында бик рәхәт кенә торганда, бервакыт әҗәл ирешеп, ул да дөньядан күчкән. Шуннан соң, Габделмоталлибның васыяте буенча, Мөхәммәд (с.г.в.) аның өлкән улы Әбү Талиб тәрбиясенә күчкән. Әбү Талиб та, атасы кебек, аны бик яраткан. Әбү Талиб сәүдәгәр кеше икән. Ул сәүдә белән гел Шәм дигән җиргә бара торган булган. Бервакыт, Мөхәммәдкә (с.г.в.) тугыз яшь тулганда, ул, кораеш гарәпләренең кәрванына кушылып, Шәмгә китәргә уйлаган. Шулвакыт Мөхәммәд (с.г.в.) Әбү Талибтан каласы килмичә елаган. Әбү Талиб, аны бик ятраткалыктан, кызганып, үзе белән Шәмгә алып киткән. Алар Шәмгә барганда бер авыл янына туктаганнар. Шул җирдә хәзрәти Гайсә (г.с.) шәригате буенча гамәл кыла торган бер суфи аның Гайсә Пәйгамбәргә (г.с.) җибәрелгән китапта хәбәр ителгән Пәйгамбәр (с.г.в.) булачагын аңлаган. Ул кәрвандагы кешеләрнең бәгъзеләренә бу турыда сөйләгән дә әле.

Мөхәммәд (с.г.в.), егерме биш яшькә җиткәч, Мәккәдәге Хәдичә исемле бер бай хатынга өйләнгән. Ул хатын бу вакытта кырык яшендә булган. Ул үзе, байлыгы өстенә, бик әхлаклы, бик яхшы табигатьле, саф күңелле, туры сүзле бер хатын да икән. Хәдичә Мөхәммәднең (с.г.в.) дә бик яхшы, бик туры, бик күркәм холыклы, бер дә хыянәтсез, олуг нәселле бер егет икәнлеген белгәнлектән, аңа кияүгә чыгарга үзе теләгән һәм башлап аңа сүз салдырган. Чыннан да, хәзрәти Мөхәммәд (с.г.в.) яшьтән үк халыкка бик сөйкемле, бик тугры булган. Ул бер дә бозыклыкта булмаган, хыянәт кылмаган, бик шәфкатьле вә мәрхәмәтле булган, шуңа күрә халык аны бик яраткан. Хәзрәти Хәдичәнең аңа соклануы да менә шул сәбәпле икән.

Бу вакытта гарәп халкы бабалары Ибраһим (г.с.) вә Исмәгыйль (г.с.) пәйгамбәрләр китергән дин вә шәригатьне, үзләрен яраткан бер Аллаһны бөтенләй онытканнар. Таш вә агачлардан әллә нинди сурәтләр ясап, шуңа гыйбадәт кыла вә шуңардан Аллаһтан ярдәм сораган кебек ярдәм сорый, аларның алдына тезләнеп, ялына-ялвара торган булганнар, ягъни алар потка табынганнар. Андыйларны мөшрикләр диләр. Хәзрәти Мөхәммәд (с.г.в.) гарәпләрнең бу эшләренә бик аптыраган. Ул аларда таралган чиксез бозыклыкларга ни әйтергә дә белмәгән. Мөхәммәд (с.г.в.) үзе аларча гыйбадәт кылмаган, алар кебек бозык эшләр эшләмәгән. Ул үзенчә бер Аллаһка гыйбадәт кыла башлаган. Мөхәммәд (с.г.в.), Мәккәгә якын урнашкан Хира дигән тауга барып, күп вакытын шунда гыйбадәт белән уздыра башлаган. Анда төн куныйп та калгалаган. Ашарына бетсә, Мөхәммәд (с.г.в.), кайтып, азык алып китә торган булган. Менә шул рәвешчә, Хира тавында гыйбадәт кылган кичләрнең берсендә, аңа Аллаһы Тәгалә тарафыннан Җәбраил фәрештә килеп, аның Пәйгамбәр (с.г.в.) булганлыгын белдергән. Мөхәммәд (с.г.в.) шуннан соң пәйгамбәр булып, халыкны туры юлга өндәргә тотынган.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

«Тәрҗемәи хәлем»

(Аерым бүлек-кисәкләре)

Хәсән Хәмидулла


- 158 -

فینلاندیەدە

نیك آلای؟

ترجمه حالمدن 5

بز ئەلی فینلاندیەدە. امیدسز حالدە توركیەدە
یاشاب كیم حور، مسكن بولوب بتكەن جان تەنلرمز
گویەكە ایندی موندا ترپلەچەك، ایندی آلار بزگە
توش كورو كبك كنە قالاچاق كبی امیدلر اچندە فین
توفراغینا آیاقلارمزنی باصاقدا كوكللرمز بیوق،
موندا غی كشیلر هم دوستلار آراسندا مسكن بولب
اویالوب تورولارمز تیز اوق بتمەدی.

Ахыры. Башы журналның 5 нче (2022) санында.

Без Вазага килеб төшкәч, апам Хәлимә һәм җизнәй Садыйк Гайнеддинләрнең шадлыклары дөньяга сыймаслык булды. Аларның беренче сүзләре: «Сез инде монда калыгыз. Андый еракка Кемигә бармагыз…» – диеб безгә бәйләнүләре булды.

Бу без киткәндәге бер ел эчендә бик алмашынган шәһәрне багыб йөрергә китдек. Яңа эшләнгән чаршыда (базарда. – *Х.М.*) Хәлимәләрнең дә хатын-кыз күлмәкләре өчен яңа кибетләре бар булуы сәбәбле, шуны багарга китдек. Иске эшләрен дә ташламыйча, Вазаның рынкасында (базарында) чатыр белән Садыйк үзе сату итеб торганга, ул анда тукталыб калыб, без Хәлимә белән аның шул яңа чаршындагы күлмәкләр кибетенә аны ачарга китдек. Чөнки кибетләрне инде иртә белән ачу заманы иде. Кибет ачу белән үк ул, без һич уйламаганча, бик сату итә башлагач, безнең бик исемез китде, хәйранга калдык. Хәлимә безгә: «Менә бакыгыз: монда менә нинди сатулар шәб! Монда калсагыз, сезгә Алла бирер иде», – диде. Ул инде безнең фәкыйрьлегемезне белә, безгә инде мондый кибет кебекләрне ачыб маташырга насыйб түгел, безгә инде икмәк кайгысы гына кирәк. Кемидә бит бар да белгән, андагы финнең иң зур фабрикаларындагы эшче халкына өйдән-өйгә йөреб (асламчы) булыб сату итеб йөреб яшәргә була… һәм әтием дә анда булганлыкдан һәм төреккә киткәндә әтием белән икәү бергәлеккә эшләгән өемезнең үз өлешемне аңарга сатыб киткән булсам да, әле дә әтиемдән 5000 марка алачагым да бар һәм минем анда яши белүем шөбһәсез булуы сәбәбле, Хәлимә апаемның монда калырга димләве мине мыскыллаган кебек кенә тоелды.

Шул өмидсез хыялларның һәм Хәлимәләрнең бик яхшы сату итү хыяллары белән төн буенча йокыларымда саташыб чыгыб, икенче көнне иртә белән шәһәргә чыгыб йөри-йөри шул чаршыга кердем. Хәлимә апам янә анда ишелеб-ишелеб сату итә иде. Унбишләб булган кибетләр арасында бу чаршының эчендә Хәлимәләргә каршы дүрт метр озынлыгында, ике метр киңлегендә бер кибетдә аз малы белән алучыларны көтеб утырыб торучы картрак ир янына барыб сүз башладым: «Кибетеңне сат. Мин аламын», – дидем. Минем ул сүземә ул бик шадланыб, мине сөйләшергә чакырды. «Кибетемне маллары белән сатыб алсаң, бирәм. Хакы 5000 марка», – диде.

Ләкин маллары да модадан чыккан, эшкә яраксыз чәчәкле критун, ягъни тәрәзә пәрдәләренә яки чаршауга гына яраклы булыб, алар да 500 метрдан артык юк һәм төрлесе төрле төсдә япун малы иде.

Мин, көлеб: «Болар бит берсе дә акча тора торган нәрсә түгелләр, боларны пичкә генә бәрергә. Бик бәя сорыйсың… Мин бушка да алмас идем. Ләкин Төркиядән акчамны бетереб киттем. 3000 маркадан артык акчам юк», – диеб, бик тырышлык белән хәлемне, вазыйгатемне аңлатдым. Һәм күземә яшьләрем дә килде.

Ул бераз уйлаб торды да: «Ярый алайса, хәлеңне белдем. Кызганыч кеше икәнсең… Мин барыбер моны ничек булса да бетерергә йөри идем. Кирасы (налогы. – *Х.М.*) бар бит. Бетде. Бир акчаңны», – диде.

Мин, акчаны биреб, ачкычны кулыма алдым. Кибет минеке булды. Кибетче булдым.

Мин әле уйга талдым: «Нишләдем мин, тилердемме? Бөтен акчам бит кулымдан китде. Кемигә барырга билет алырлык да акчам юк бит. Хәлимәләрдән алып торсам да бит, килер-килмәс аларга йөк булу бик оят булыр, моның да бит кирасы бар, аны кайдан алыб түләрсең (160 б.). Бу эшкә яраксыз маллар белән бит монда терәлеб торыб булмый…»

Шул кечерәк дөканымның (кибетемнең. – *Х.М.*) урындыгына утырыб хыялланыб торуымны мөштәриләре (сатып алучылар. – *Х.М.*) юк вакытда каршыдагы Хәлимә күреб, яныма йөгереб килде. «Нәрсә бу? Ник монда утырыб торасың? Иясе кайда?» – диде.

Мин аңарга: «Иясе инде мин булам! Сатыб алдым. Мин моның белән нишлим әле диеб уйлаб торам», – дидем. Ул, исе китеб: «Синеке? Сатыб алдың? Бу эшкә яраксыз чәпиләрне, төсләре киткән чүпрәкләрне?! Гакылың кайда иде? Күпме түләдең? Нишләрсең әле бу черегәнләрең белән?!» – диде.

Ләкин мин инде бу маллардан котыла белү чарасын хәзергә уйлаб алган, күңелем тынычланган иде. Ул тагын миңа: «Тиз генә боларны күздән югалт. Кешеләрдән яхшы түгел. Көлмәсенләр. Без сиңа сатарга үземезнең сатылмый торган күлмәкләрне бирәмез. Сатылмаса – кире кайтару шарты белән», – диде. Кешеләр көлүендән котылу өчен, аның китми торган малларын дөканыма... төяб, тезеб куйсак да бит, минем максадым – маллар сатылсын да, шуның белән яшәб булсын һәм кирасын да түли алыйк иде.

Бая утырыб уйлаб торгандагы карарым буенча, хатынымны дөканга куеб калдырыб, үзем шул эшкә яраксыз маллар белән Кемигә әти белән күрешергә китдем. Чикдән тыш әтиемнең шадлануына минем дә күңелем бик ярсуланыб, күземә яшьләрем килде. Әти миңа: «Угылым, бер дә курыкма! Син әле хаҗи кебек кеше булдың. Изге ислам йортындан изге туфракларын табтаб килдең. Әле монда Финляндиядә бик яхшы гына ябыш та, эшкә тотын... Син бит Төркиягә күчеб киткәндә фирмаларга бурычларыңны түләб китдең. Алар белән сөйләш. Алар сине яңадан күтәрерләр. Миндә 5000 марка акчаларың бар. Шуның белән әле алган кибетеңне бераз башкара белерсең. Эшең бик терәлсә, мин булышырмын», – диде.

Әтиемнең бу сүзләренә шадланыб, күңелем тынычланыб китеб, иске гадәтем буенча шул янымда алыб китергән чәпи (?) малларымны җилкәмә узел бәйләб алыб, өйдән-өйгә йөреб сатарга китдем. Минем белән эш кылырга өйрәнгән мөштәриләрем мине күреб, шадланыб, кочаклаб алдылар. «Кайда йөрдең син?» – диеб сорауларына каршы мин вазыйгатемне аңлаткач, аларга бик җәллек кереб, шул китергән малларымны бик яратулары сәбәбле, ике көн эчендә бөтенләй, бик файдасын күреб сатыб бетердем. Кесәм акча белән тулды.

Хәзер инде минем байлыгым 10 000 маркага менде. Әтием дә, минем бу кадәр бәхетле (161 б.) булуыма хәйранга калыб, үзендән алачак бар булган 5000 марканы чыгарыб бирде.

10 000 марка саф акча белән Вазага кайткач, Төркиягә киткәндә 30 000 марка бурычымны түләб киткән фирма «Лясасила тикануя»га кердем. Алар мине Төркиягә киткәнемчә бурычларымны түләгәндә белгәнләр иде. Алар, мине йөгереб каршы алыб: «Син кайттыңмы? Ник кайтдың?» – диеб сорадылар. «Хәзер инде сез миңа ярдәм итегез... Сездән маллар алганым тәкъдирдә түләве өчен абдыранмагыз», – дидем.

Бер шулай сөйләшкәнемез вакытында ап-ак сакалы белән «Лясасила...» хуҗасы үзе өстке катдан төшеб, мине күреб исе китде, үземнең хәзерге вазгыятем сөйләшкәч, ул миңа: «Бер дә курыкма! Монда без сине баетырмыз (диеб көлеб әйтеб), иртәгә безгә шундый маллар килә. Бүген әлдә гөмрүкдә (таможняда. – *Х.М.*). Ул малны без яһүди «Холстин»га гына сатамыз. Аларга сөйләмә, ул мал күпме булса да, әле китә. Ул бик модада... Фәкать шарты шул: «Холстин»га кайдан алганыңны әйтмә», – диде.

Мин бик шадланыб, үземә яраклы малны алыб, рынкага китдем. Чөнки мин андый әле акчам булыб сәфәрдән кайткач базардан рынка урыны алган идем. Үзем инде әле рынкада чатырда сату итеб, хатыным инде хатыннар киемләре чаршасында (пассажда) да тора һәм анда да инде шактый гына үтемле маллар куйган идем.

Иртә таң белән үк сөйләшкән вәгъдәләр буенча, «Холстин» күрмәсен өчен, «Лясасила...»дан тора торган өемезгә 1000 данә ефәк фаустилары (? – *Х.М.*) килде. Чалмага охшаттырыб, яңа мода итдереб хатынлар башына кия торган бу «турбан»лар фингә бик аз килгәне өчен, аны фингә китерүче фирмалар, яшереб, үзләренең якын мөштәриләренә генә иллешәрләб кенә өләшәләр. Шуның өчен ул халыкка яхшы икән.

Бу кадәр мал килүендән куркыныб калсам, китмәсә бит тәмам хәраб булачагымны белсәм дә, Аллага тәвәккәлләб, малларның өстләрендәге фирма «Лясасила...»ның пичәтләрен ертыб бәреб, рынкадагы өстәлемә һәм чаршыдагы кибетемә куйдым. Чөнки рынкадагы каршымдагы өстәл яһүди «Холстин»ныкы иде.

Йа Раббым, нинди хәл бу? Бу хатынлар шапкасы «фаусти»ның хәзер бик кызган мода вакыты икән дә, бөтен шул 100 дюждинамызны (?) бер көн эчендә чиратда торучыларга сатыб бетердек. Шадлыгымыздан Аллаһу Тәгаләгә еглаб-еглаб шөкерләр кылыб, шактый гына зур суммалы бер сәүдәгәр булдык. Шундан соң инде бу маллар «Лясасила...»га артык килмәде һәм модасы да бетде.

Икенче көнне «Лясасила...» миңа модасындан инде чыккан, ләкин алтмыш косук (?) сатылмыйча ятыб калган бик яхшы, бик бәһале 1 метр 40 синт киңлегендә малын бик очсызга тәкъдим итде. Бу йон (йүн?) малының бер итәк ягы чәчәкле абуркалы булганы һәм шуңарга була модадан да чыккан өчен бу мал минем кәефемә бер дә килмәсә дә, әле инде сата алмасам да, түләрлек акчам булмаганга, «тәвәккәл Аллага», диеб, сораганының ярты хакын тәкъдим итдем. Алар, бик озак уйлаб торгач, кабул итделәр дә – урыннарын тиз генә бушату өчен, хәзер үк минем чаршыдагы кибетемә итәчәк булуларын шарт куйдылар. Мин кабул итдем.

Мин инде йә бетдем, йә уңдым, диеб, бу җәсарәтлегемә (кыюлыгыма, тәвәккәллегемә. – *Х.М.*) үз-үземне бәянләб (бәяләб) чаршуыма килеп кенә йитдем, «Лясасила...»ның бөек йөк актысы малларны китерде. Кибетемезгә сыйдыра алмыйча газаблар күреб, өстләренә меңеб сикреб төшдем; «йир кабдым», диеб, эчләрем әрнегән вакытда ник мондый «хлам», эшкә яраксыз маллар алганым өчен хатынымның дөньяны улатуы, «Дөнья рисвае бит бу! Кеше көлкесе, дөньяга багарлыкымызны калдырмадың!» – диеб акырыб-бакыруы, Хәлимәләр һәм андагы сатучыларның да миндән көлүләре, «Моның соң гакылы кая икән?!» – диеб пышдым-пышдым (мыштым-мыштым. – *Х.М.*) сөйләшүләре минем бик ачуымны кабартыб: «Көлмәгез... Бездә тумаган, бездә яшәмәс», – диеб, кибетнең алгын ябыб, хатыным белән орыша-орыша малларны рәтләргә тотындым. Минем фикрем башка иде. Бу фикрем шул малларны алганда уянган булуы сәбәбле, боларны алыр өчен минем җәсарәтем дә арткан иде (162 б.).

Минем фикерем буенча, бу малларның чәчәкле абуртларын 20 синтләр (сантиметр. – *Х.М.*) кадәр кисеб-ярыб алгач да, әл дә 120 синтләр кадәрге киңлекдә кала иде.

Дөньяда, бәлки, һич охшашы булмаган, төрле-төрле төсдәге, нечкә һәм чын җондан булган бу малны безгә бөтенләй юк-бар хакка килгәне өчен һәркемгә

сатыб була... һәм хатынлар күлмәкләре булса (?), төб кибетемезне матур күлмәкләр белән дә тутырыб була иде.

Кибетемезне кешеләрдән ябыб, хатын белән икәү генә эчдә калгач, бу фикеремне хатыныма сөйләдем. Ул, бик шадланыб: «Дөрест бит! Бу бит чыкмый торган шәб мал! Болардан күлмәкләр эшләтәбез!» – диде.

Инде бар булган юлаучымызны телефон белән чакырдык. Ул бик тиз чабыб йитеб, малларны һәм фикеремезне белде дә: «Сез инде әле бу күлмәкләрегез белән мондагы сатучыларның барысын да әпәйләрен арчыйсыз, йир кабдырсыз!..» – диде. Безнең янган йөрәкләремезгә су салды. Ул да күлмәкне кисеб алыб төнләр буенча йүләб (?) бетерәчәк булыб, кешеләр күрмәсен диеб яшереб алыб китде. Кисеб алган чәчәкле абуртлар да күлмәк якаларына һәм җиң башларына кирәк булыр, шундый яңа бер мода чыгарам диеб чыгыб китде.

Икенче көнне иртә белән үк ул берничә күлмәк алыб безгә китергәч, шуларны без кибетемезнең тышкы ягына алыб куйгач, бөтен шул чаршының сәүдәсе безнең кулымызга төшде. Һәммәсе таңга калдылар. Эшсез торулары сәбәбле, йөрәкләре янды. Без исә яңа юлаучылар табыб, эшне зурайтыб йибәрсәк дә, тышкы якдагы чиратда торучыларга йитәрлек эшләтеб өлгертү мөмкин булмады.

Безнең эшемез, шөһрәтебез арткан саен, туганымыз Хәлимә вә Садыйк белән арамыз бозыла язды. Көнчелек, кызыганчылык һәм шәйтан арага керде. Әле инде без акчалы булганымыз өчен, малларымыз да һәм чаршыда, һәм рынкада яхшыдан-яхшылана баруы сәбәбле, сатучы дошманларымыз белән алнымызартыбыз тулды.

Эшләремез шулай шәбәя бара диеп, бигрәк дә рынкамызга кирәкле булгач, бик күб төрле маллар өчен «Лясасила тикануя»дан башка фирмаларга да иялəшеб, мал көчемез һәм шуның белән бергә бурычларымыз да арта барганга, кул-аягымыз төрле-төрле күб малларга бурычланырга, бурыч түләүләргә бәйләнеб китде.

Хәзер инде көз айлары йитешеб, сезон вакытлары да, мода мәсьәләләре дә артка кала баргач һәм бик суыклар китеб, рынкада утырулар да зәхмәтләнә барган өчен, эшемез тараерга, бурычларымыз да, бурыч түләүләремез дә агырая башладылар. Чаршыдагы сатулар да һәм рынкадагы сатуларымыз да зәгыйфьләнә барган өчен, миңа инде рынканы селдәб (калдырып. – *Х.М.*) иске гадәт буенча авылларга китеб, өйдән-өйгә йөреб сату итәргә һәм шул аз-маз сатулар белән бурычларымызны аз-азлаб түли башларга мәҗбүр булынды. Төркиядән кайтыб килгәч үк ачылган бәхетләремез хәзер инде төш күрү кебеккә генә әйләнгәне өчен, ничек акчалы булу, ничек бурычларымыздан котылу кайгылары көнләрен-төнләрен башымызны кайнатыб, йокыларымыз да качды һәм нервыларымыз да бозылыб китде.

Төркиядә вакытда Искешәһәрдә Хәсән Җәмалга ярдәм өчен бурычка биргән акчаларыма... аңардан алыб килгән 20 данә ирләр костюмнары (элеккеге битләрдән карагыз!) монда кемгә дә яраклы булмаганлыгы өчен сатылмыйча торалар иде.

Төрек паспортымның вакыты 10 көндән соң чыгыб һәм төрек сәфарәте Финляндиядә булмавы, яңартыр өчен Стокһольмгә йибәрү мәшәкатьләре бар булганы өчен, шул паспортымны яңартырга бару сылтавы белән Одесса үтәли Төркиягә дә барам диеб ялганлаб мондагы рус сәфарәтендән (илчелегеннән. – *Х.М.*) Русия үтәли транзит визасы алыб, шул төрек әлбәсәләре (киемнәре. – *Х.М.*) һәм байтак кына маллар белән Ленинградка утырыб китдем. Максадым шуларны

анда сату һәм андан акчаланыб килү вә шулар белән мондагы эшләремне төзәтү иде. Бу сәфәрем хакында «Милли юл» мәҗмугасының 1928 (дөресе – 1929. – *Х.М.*) ел берничә номраларында дәвамлы рәвештә «Совет Русиясендә кунакда» исеме белән хатирәләремне язган идем. Күб номраларын гаиб итүем (югалтуым, таба алмавым. – *Х.М.*) сәбәбле, кулымда сакланыб калган берничәләрен рәсем ысулы белән монда күчерәм*.

(163 б.) Совет илендә башыма бик күб бәлаләр, көтмәгән агырлыклар килеб, Москвага да барыб төрек сәфарәтендән паспортымны яңарткандан соң мең газаб белән андан котылыб, байтак кына акча белән өйгә кайтдым. Түләү вакытлары инде узган бурычларымны түләб, әле инде бурычларымыздан котылыб авылларда өйдән-өйгә сату итеб йөрү эшенә башладым. Кыш айлары бик салкын булу сәбәбле, рынкада утыруымны бетереб, кирасы очсызлырак яңа фатирга күчдек. Моның да сәбәбе, әлбәттә, көмәнле хатынымның углымыз Гомәрне табу вакыты якынайганлыкдан, эчендә сулы бүлмә булуының кирәге иде. Шуның өстенә, әл дә моның кирасы да очсыз хак иде.

Озакламыйча 1928 нче елның декабрь 15ендә хатыным бала тудыргач, безнең өйдәге гаиләмез артыб китү генә түгел, чаршыдагы кибетемездән ул өйгә калыб, кибет сатучы кызымызның кулына калды.

Эшләр агырыб китде. Бик суыклар китеб, күб карлар, буранлар астында кар ерыб еллар өйгән авыл юлларында сату итеб йөрү миңа да бик агыраеб, хәлләремез түзә алмаслык дәрәҗәгә йитде.

Рынкамызда тормасак да, аның һәм өемезнең кирасын түли алмау кайгылары өстенә, заман бозыла башлады – бөтен фингә кризис-кытлык килә башлады. Күб йирдә фабрикалар туктаб эшсезлекләр китде, халыкда һәм эш, һәм акча бетә башлады. Тора-бара бу агырлыклар бөтен дөньяга таралыб, 1930 елда инде бөтен дөньяда кризис тугды. Зур-зур фирмалар банкротлыкка китеб, безнең агай-энеләрнең арасында да бөтен Финляндиядә дүрт-биш кешедән башкалары һәммәсе банкротка китделәр – әлфас итделәр. Мин аларга бурычлы булган банкротка киткән фирмаларның адвокатлары миндә түләнмичә торган алачакларына берничә аз вакытда түләмәсәм каты кул белән алачаклары белән куркытыб, йөрәгемне ярды. Мин Кеми шәһәренә әтием белән сөйләшергә китдем. Әтием миңа: «Син инде җенләнеб анда торма. Монда күч. Үзеңнең бүлмәләреңдәге торучыларны чыгарам; сиңа бирәм. Кира түләб торырсың», – диде.

Мин, Кемигә күчәргә разый булыб, Вазага кайтдым да, озакламыйча ук Вазадан Кемигә күчдек.

[Дәвамы («Кемидә» һ.б. бүлекләре) бар]

Басмага филология фәннәре докторы
***Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

* «Тәрҗемәи хәлем»нең шушы өлеше бирелгән «Ник алай?» китабында «Совет Русиясендә кунакда» язмасының «Милли юл»дагы (1929. – №9; 10) тексты да урнаштырылган.

ӘДИП АВЫЛЫ

Татар Пешләсе

Татар Пешләсе авылының бүгенге күренеше. 18 май, 2022 ел

Татар Пешләсе – атаклы татар әдибе Шәриф Камалның (1884-1942) туган авылы.

Мордовиянең Рузаевка районына караган, Пешлә елгасы буенда урнашкан әлеге авылга XVII гасырда нигез салынган (1631 елда татар морзасы Уразга бирелгән җирдә) дип фаразлана. 1869 елда алынган мәгълүматларга караганда, ул вакытта 4 мәчетле бу авылда 345 хуҗалык булган, анда 2255 кеше яшәгән.

1913 елгы җанисәп буенча, Татар Пешләсендә ул вакытта 584 хуҗалык (3607 кеше), 3 татар мәктәбе, 5 икмәк кибете, 2 янгын машинасы, бер нефть белән эшли торган двигательле тегермән һәм сигез җил тегермәне, 4 тимерчелек алачыгы һәм кирпеч сарае булган.

1928 елда, 28 хуҗалыкны берләштереп, «Көч» колхозы (рәисе – С.И.Зимин) оештырыла.

Бүгенге көндә Татар Пешләсе авылында урта мәктәп, мәдәният йорты, балалар бакчасы, 5 кибет һәм ике мәчет бар. Авылның бер урамы Ш.Камал исемен йөртә.

1907-1910 нчы елларда Ш.Камал туган авылы Татар Пешләсендә мөгаллимлек итә. Абыйлары Гыйматдин һәм Габдулла белән берлектә, алар авылда яңа мәктәп төзетәләр. Мәктәптә, төп укыту программасына өстәп, рус теле укыту, кызларга белем бирү кебек яңалыклар кертәләр.

1974 елда Татар Пешләсе авылы халкы үзләренең мәшһүр авылдашы – атаклы язучы Шәриф Камалның тууына 90 ел тулуны зурлап билгеләп үтә. Тантаналы чарага Казаннан да мәртәбәле кунаклар – шагыйрьләр Хәсән Туфан, Зөлфәт һәм язучы Габдрахман Минский килә. Авыл халкы белән очрашудан тыш, алар район үзәге Рузаевкада һәм Саранскида да була.

Шәриф Камал урамы

Татар Пешләсе авылының тау башына салынган мәчете (ул Русия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә (баш мөфти – шәйхел-ислам Тәлгат хәзрәт Таҗеддин) карый). 18 май, 2022 ел

Татар Пешләсе авылы мәктәбендәге Ш.Камалга нисбәтле музейда. Рәсемдә (сулдан уңга): мәктәп директоры Флора Әхмәтҗан кызы Шамунова, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм татар теле укытучысы Сания Спартак кызы Сәләева. 18 май, 2022 ел

«Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон Татар Пешләсе авылының җирле үзидарәсе башлыгы Рингат Шабаев һәм Рәшит хәзрәт Тарпищев белән мәдәният йортында урнашкан авыл китапханәсендә. 18 май, 2022 ел

Татар Пешләсе авылында Ш.Камал туган йорт нигезе урынына куелган истәлек ташы. 18 май, 2022 ел

Татар Пешләсе авылындагы икенче мәчет. 18 май, 2022 ел ■

Л.Гобәйдуллин һәм Л.Лерон фотолары

Композиторның зур бәхете

Шамил Тимербулатов

Авыр тойгы: якын күршебез, композитор Шамил Тимербулатов инде безнең арабызда юк. Шат күңелле, искиткеч эшчән, тормышны, балаларын, гаиләсен өзелеп яраткан Шамилебез көтмәгәндә-уйламаганда бакыйлыкка күчте. Ул әле яшь, ташып торган энергияле, киләчәккә зур максатлар, зур планнар куеп

яшәүче, тирән музыкаль белемле композитор иде. Ә иң мөһиме – безнең Татарстан урамындагы 7 нче йорт кешеләре өчен һәрвакыт якты йөзле, аралашучан, һәммәбезгә игътибарлы һәм ихтирамлы күрше булды.

1984 ел. Аларда – өч, миндә – ике кыз. Кече кызым Резеда белән Тимербулатовларның иң өлкән кызы Гөлнара алты яшьтән укырга киттеләр. Без аларны ул вакытта Казанда татарча урта белем бирүче бердәнбер булып саналган М.Гафури урамындагы 35 нче мәктәпкә бирдек. Балаларны чиратлап илттек, чиратлап алып кайттык.

Сәрия һәм Шамил Тимербулатовлар кызлары Гөлнараны һәм күршеләре Резеда Шәфигуллинаны мәктәпкә озаталар. 1984 ел

Шамил дә, хатыны Сәрия дә гаҗәп дәрәҗәдә бала, гаилә җанлы кешеләр. Тату, тирә-күршегә үрнәк гаилә. Шамил балаларына үз куллары белән икекатлы караватъ ясап куйды. Ванна бүлмәсен үзгәртеп, нәкъ менә кызлары өчен дип, кечкенә бассейн эшләде. Ә үзенең эш бүлмәсендә рояль, баян, башка төрле музыкаль уен кораллары, спорт җайланмалары, кыскасы, иҗат өчен дә, яшәү өчен дә, шулай ук сәламәтлекне ныгыту өчен дә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Тагын шунысы кыйммәт: гаиләдә Шамилнең талантын тану, олылау, бер-берсенә кайнар мәхәббәт, ир белән хатынның бербөтен булып яшәве һәрвакыт сизелеп тора иде.

Гомумән, Шамил дөньяга аек күз белән караучы, акыл белән дөнья көтүче ир булды. Ул үзенең җәмәгатен бик дөрес сайлаган, алар, әйткәнемчә, бер-берсен тулыландырып яшәүче тиң ярлар, тиң парлар. Әстерхан якларыннан килеп Казанда музыкаль белем алган хатыны Сәрия – күркәм холыклы, аш-суга, кул эшләренә бик оста, бик уңган хуҗабикә. Аның алтын куллары «иҗат итеп», зур зәвык белән җыештырылган фатирлары оҗмахның үзе кебек. Җәен-кышын шау чәчәктә утыручы төрле-төрле гөлләр; төсле җепләрдән әллә нинди катлау-

лы бизәкләр белән бәйләнгән челтәрләр; чигелгән, тегелгән, үрелгән, күз явын алырлык осталык белән эшләнгән картина һәм җиһазлар сокланып туйгысыз. Ишекләрен ачып бусаганы атлауга, сине әнә шундый әкияти матурлык дөньясы каршы ала. Безнең күршебез Шамил менә шундый зур сәнгати зәвык белән бизәлгән гүзәллек эчендә яшәде һәм иҗат итте. Ул гаиләсендә, чын мәгънәсендә, зур абруйга ия, кадерле кеше иде.

Шамил Тимербулатов белән иҗади дуслыгыбыз «Дусларым» җырыннан башланды. Бервакыт ишектә кыңгырау шылтырый. Ачсам, беренче каттан йөгереп менгән күршем тора. «Дуслар турында җыр язасым килә, яңа шигырьләреңне күрсәт әле», – ди. Карыйбыз, укыйбыз, күрәм – аның күңеленә ошаганы юк. Шамил: «Сиңа ике сәгать вакыт, тик мин бер сәгатьтән менәчәкмен», – ди һәм атылган ук кебек төшеп тә китә. Ул – илһам канатында, күңелендә моң кайный, көен сүзләр белән яраштырырга гына кирәк... Җыр шулай туды. Шамил аны күршебез, танылган, барыбызның да яраткан җырчысы Хәйдәр Бигичевка бирде, чөнки ул башта ук Хәйдәрнең көчле тавышын күздә тотып язылган иде. Шулай итеп безнең беренче иҗат җимешебез бүген дә башкарыла торган уңышлы хезмәт булды. Калган җырларыбыз да Шамилнең тынгысызлыгы, һәрвакыт иҗат утында януы, активлыгы белән туды. (Сүз уңаеннан шуны да әйтим: Шамилнең кызы Гөлнара Тимербулатова да минем шигырьләргә бик матур җырлар иҗат итте.)

Әйткәнемчә, Шамил Тимербулатов иҗатта пыскып түгел, дөрләп янып яшәде. Җырлар белән рәттән, зур, күләмле әсәрләр, симфонияләр язды, иҗат кичәләрен үткәреп, хезмәте белән халыкны даими таныштырып торды. Ә иң мөһиме – композиторның иң зур бәхете, иң зур байлыгы – аның эшен дәвам итәрлек, эстафетаны алга алып барырлык балалар үстерүе.

Әтисенең юлын лаеклы дәвам итүче, алга-киләчәккә илтүче, мирасын югалтмыйча халыкка җиткерүче кызы Гөлнара Тимербулатовага олы рәхмәтемне әйтәм. Аңа сәнгать юлында әтисе кебек армый-талмый эшләү, киләчәктә яңадан-яңа үрләр яулау насыйп булсын!

***

Әйткәнемчә, Гөлнара Шамил кызы, эшчәнлеге ягыннан, әтисенә дә, әнисенә дә охшаган. Менә бит, кадерлесенә багышланган «Шамиль Тимербулатов. Жизнь. Судьба» дип аталган истәлекләр китабын чыгарып та өлгергән. Әтисенең вафатыннан соң, Софья Гобәйдуллина исемендәге фестивальдә мәрхүм композиторыбызның «Болгар аһәңнәре» дип аталган соңгы ораториясенең премьерасын яңгыратты Гөлнарабыз. 1921 елда, әтисенең 70 еллыгында, «Ике йөрәк моңнары» исемле концерт программасы төзеп, үзенең һәм әтисенең романсларыннан торган, үтә бер җылылык белән әзерләнгән искә алу кичәсен үткәрде.

Быел июнь аенда кадерле күршем, композитор, Габдулла Тукай бүләге иясе Шамил Тимербулатовның арабыздан китүенә тугыз ел тулды. Аралашкан һәркемдә якты хатирәләр калдырган дустыбызның урыны оҗмахта булсын!

Эльмира Шәрифуллина, *шагыйрә,*
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,
С.Сөләйманова исемендәге премия иясе ■

Эльмира Шәрифуллина шигырьләре

Татар теле мөгаллиме

Яратканга туган телне,
Ана телен яратканга,
Гыйлем эстәү чын татарча
Булсын диеп җан атканда,
Кемнәр генә сүзләмәде,
«Кыйнамады» кемнәр генә?!
Туган тел дип сөйләнделәр,
Калды ләкин сүздә генә.
Татар теле – туган телең –
Бәхетсез тел булып йөрде.
Калдык-постык сәгатьләргә
Иң пучтәк фән булып керде.
«Тара-бара», имеш, аны
Укыта ала һәрбер тинтәк...
Шул кадерсез мөнәсәбәт
Сеңдерелде җайлап-ипләп.
Саташты күп йомры башлар,
Голамәсе, дин хадиме.
Көрәштең син берьялгызың,
Татар теле мөгаллиме.
Сөю, әрну газабыннан
Тамырларың шытым бирде,
Шәкертләрең бил турайтып
Басты бүген, күзең күрде.
Әнә шулай: сабыр холык,
Тыйнак акыл белән димме?!.
Саклап телне, сакла безне,
Татар теле мөгаллиме!

*Сабан туе**

Сабантуйлар килеп җитте исә,
Балаларын көтә карт-коры.
Күрше-күлән сорый: киленебез
Оланнарны алып кайттымы?

Нәсел-нәсәп, кардәш-ыру көтә
Туганыннан туган баланы.
Безнең якка тартты микән, имеш,
Хөрмәтләрме ата-бабаны?

Якын итеп туган ягыбызны
Кайтып-килеп йөрер микән соң?
Үз сөяге итеп карт-корының
Хәлкәенә керер микән соң?

Һәр сулышта, балаларым, диеп,
Көтә алар, ачып капкасын.
Сабантуйга кайтыйк җыелышып,
Картлар хакы җирдә калмасын! ■

* Кыскартып бирелә.

ФАРСЕЛЬ ЗЫЯТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Әгъләмисина

(Шул исемдәге әсәрдән өзек)

....

Фарсель Зыятдинов

Язучы, икътисадчы, бакчачы, икътисад фәннәре докторы (2002), ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1992) Фарсель Зыятдинов (1937-2021)

Дөнья ыгы-зыгысыннан магарәгә качып котылган Әбүгалисина кебек, Мөдәррис Әгъләмовка да каядыр югалып торудан да хәерлерәк чара калмаган иде. Аның «мәгарә»се студент шагыйрьләр тулай торагында булып чыкты. «Даһилар тулай торагы» дигән йортта Мөдәрриснең яшьтәшләре, каләмдәшләре – Ркаил Зәйдуллин, Ләбиб Лерон, элек Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим һәм башкалар яшәсә һәм иҗат итсә, соңрак аларны яшьрәк каләм осталары алыштырды, аннары тагын да яшьрәкләре. Алар, алынган эстафетаны дәвам итеп, аны киләчәк буыннарга тапшыра килде…

Өлкәнрәкләр аның белән гәпләшсә, фикер уртаклашса, яшьләр шигъри мәктәп сабаклары алды, ә ул үзе алардан рухына терәк, иманына ышаныч, яшәүгә дәрт тапты.

«...Мәгарәдән чыккан, диген,
Әгъләмисина...»

Яшьләрнең берсе (Л.Лерон) шаяртып язган бу пародиядәге күрәзәлек ахырдан чынга ашты. Әкияттәге һичкемгә билгесез шәкерт мәгарәдән рухи баеп, зиһен җыеп мәшһүр Әбүгалисина сыйфатында җир йөзенә чыккан сыман, Мөдәррис Әгъләмов та сафланып, көч-куәтен арттырып, акланып-балкып татар дөньясына күтәрелде:

«Бүгенге төн шундый авыр миңа,
Авырлыгын бары үзем беләм...
Авырлыктан кеше сыгыла бит,
Ә мин әле нигә күтәреләм?..»

Әйе, Мөдәррис күтәрелә барды бу көннәрдә. Кичәләрдә, очрашуларда турыдан-туры халык алдына чыгып, көр тавышы белән гаҗәеп шигырьләрен укыды.

«Ул «Әдәби җомга»да тагын кемнәр чыгыш ясагандыр, хәтерләмим, бары Мөдәррис Әгъләмовның шигырь укуы гына истә калган. Кыюлык өчен дипме, әллә бераз «җылынып» алган иде… безгә генә шулай тоелдымы… тавышы башта карлыгып, калтырабрак чыкты, күңел үз урынында түгел икәне, нык әсәрләнгән, дулкын-

ланган булуы сизелә иде. Әмма озакламый ул үзен кулга алды, йомшаруына ачуы килепме, йөзе кырыслана төште:

«...Эт тә үрчи, аларның да
Өреп йөргән көне.
Бәлки, хәбәр салалардыр:
Килә, диеп, бүре;
Үзләре кеше янында
Бүренең бер төре.
Кешеләргә кирәк алар,
Кирәк – безнең кебек.
Мәнсезләнеп йоклаганны
Уяталар өреп...»

Ничәдер ел тоташтан М.Әгъләмов исеменә бәйле рәвештә фәкать урынлы-урынсыз вакчыл тәнкыйть, орышу, астыртын мыскыллау, хәтта сүгү авазларын гына ишетергә күнеккән Тукай клубында, ниһаять, шагыйрьнең үз тавышы, тансык көр тавышы яңгырый», – дип искә ала халкыбызның шулай ук күренекле улы Фәиз Зөлкарнәй.

«...Такта чәйне ваткан кебек,
Бер чиметем ватып, –
Гасырларның катламыннан
Алды мине вакыт.

Алды-салды тормыш дигән
Кайнап торган суга:
Кайный тормыш –
Кандай куе
Җан ачысы чыга...»

«Җан ачысы» тәгъбиренә шагыйрьнең нинди мәгънә салганын хәбәре булганнар төгәл тоемлыйдыр. Шигырь, беренче карашка, күренекле шагыйребез Ш.Бабичның язмышын, аның фаҗигасе үлеменнән соң да дәвам итүен әрнеп сөйли сыман. Ләкин моңа авторның үз «җан ачысы» – шәхси фаҗигасе дә, шигырьнең тирәнрәк катламнарында яткан мәгънәләр – халкыбызның тарихта мәгълүм фидакяр уллары язмышына әрнүле киная дә һәм иң мөһиме – шул язмышлар янында әле һаман кайнашучы «күләгәләр»гә нәфрәт хисе дә өстәлә:

«Алар – дөньядан киткәч тә! –
Күләгәң күк калмый;
Сүгеп тамак туйдырганнар
Мактап туеналар.
Заман «кояшы»ның ничек
Каравына карап,
Кечерәйгән күләгәләр
Озыная кабат!..»

«...Әйе, аның яшәү рәвеше тормышның ул чактагы дөрес һәм бердәнбер дип саналган калыпларына тәңгәл килми иде...» – дип дәвам итә Фәиз Зөлкарнәй үзенең «Чакма чакмый ут чыкмый» дигән мәкаләсендә.

«Күләгәләр» белән якыннан танышлыгы бар шагыйрьнең. Озынымы анда, кыскасымы...

Үткерлеге, төгәллеге белән бу юллар әле бүген генә язылгандай тоела... Ә аларны автор сәхнәдән укыган ул кич, 1980 нче елларның беренче яртысындагы гапгади кич, «торгынлык дәвере»нең гадәти бер киче иде.

Әмма ничек кенә булмасын, олы саф шигъриятнең нинди икәнен өр-яңадан төшенгәндәй тетрәнеп, тынсыз калып тыңлады аны халык:

«Кайный тормыш –
Кандай куе
Җан ачысы чыга...»

Кичә бетте, халык кайтырга кузгалды. Башкалар белән бергә, кысыла-кысыла ишектән Сибгат ага Хәким дә чыгып килә. Шунда аның үзалдынамы, янәшәсендәгеләргәме әйткән өзек-өзек сүзләре колакка чалынды: «Әгъләм, нишләтсәң дә, Әгъләм булып кала. Шагыйрь... ни генә сөйләмәсеннәр...»

Өлкән әдибебезнең сүзләрен ишеткәч, хаклык аңыма барып җитте: бу кичә бит асылда биш-алты елга сузылган тоташ җәберсетү-хурлаулардан соң, ниһаять, М.Әгъләмовның таланты акланү, реабилитацияләнү иде!



Татарстанның халык шагыйре (2007), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2000) Мөдәррис Әгъләмов (Мөдәррис Зөфәр улы Әгъләметдинов)

Әйе, аның яшәү рәвеше тормышның ул чакта «дөрес» һәм бердәнбер дип саналган калыпларына тәңгәл килми, бәйсез, туры холыклы булуы рәсми фикер кысаларына сыеша алмый иде. Аның ачы, үткер теле дә үз эшен эшләгәндер, әлбәттә, шагыйрьгә әүлия генә булырга димәгәндер ич! Ягъни М.Әгъләмов, дошманнарга сылтау булмасын әле, дип, дөрес-төгәл сүзләр генә сөйләп йөрүчеләрдән, дөрес-төгәл генә яшәүчеләрдән түгел – аның турында төрле легендалар, имеш-мимешләр тумаса, хәтта сәер дә булыр иде әле. Ләкин тоташ бер вакыт дәвамында шагыйрьне тәмам каралтып, хәкарәт итеп, бетереп ташларга тырышу... Ә бит, чыннан да, хәлләр шуңа таба бара иде...

Әлеге имеш-мимешләрне закон көченә иңдерү максаты белән, әдәбиятыбызның аксакалы С.Хәкимнең колагына килеп пышылдаучылар да булгандыр, күрәсең. Югыйсә ул әлеге кичәдән соң, шагыйрьгә булган ышанычы аклануга куанып, кемнәргәдер каршы төшкәндәй, бәхәсләшкәндәй үзалдына сөйләнмәс иде.

Фәиз Зөлкарнәйнең энесе, шагыйрь Ләис Зөлкарнәйнең Мөдәррис Әгъләмов турындагы фикере дә игътибарга лаек:

«Киләчәк ул килмәячәк,
Киләчәккә кайтырга кирәк», –

ди шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов.

Кайтырга – гомереңне читтә, шәһәрләрдә үткәреп, авырулардан битәр берни дә тапмыйча, санаулы көннәреңне уздырырга, үзең тәпи басып киткән сукмаклардан кабат атларга, телеңне ачкан кошлар сайравын, җилләр шаулавын, сулар гөрелтесен,

арба келтерәвен, шыпылдап алма коелуын ишетеп калырга соңгы тапкыр туган авылыңа кайткан сыман кайтырга...

Кайтырга – исән чакта өлгермәсәң, кәфенгә төренеп булса да кайтырга...»

Кайтырга һәм, ниһаять, аңларга – читтә сугылып йөреп, заяга узган бит гомерләр, син эзләгән, эзләп тә табылмаган бәхетләр сине көтә-көтә туган нигезең белән бергә таркалган, тапталган, тигәнәкләргә күмелгән!..

Киләчәк! Син Мокамайның каен башларыннан күргән коммунизм кырлары түгел икәнсең шул.

Киләчәк! Син ал офык та түгел, офык артыннан офык ачыла.

Киләчәк! Син, туган авыл кебек, бер генә.

Синдә – таулар.

Сиңа кайтып үләләр...

Киләчәк – синдәге бишек...

Киләчәк – төтенсез авыл...

«Киләчәккә хатлар» салдык.

Төтенсез авылга хат йөрмәгәне хәзер генә искә төште шикелле...

Ә шагыйрь киләчәккә кайту хакында сөйли.

Ул үзе миңа, ни өчендер, анда инде кайтып килгәндер кебек тоела. Тукай булып үлгәндер дә Мөдәррис Әгъләмов булып тугандыр сыман.

Фатих Әмирхан, исән булып, элеккеге «Амур» кунакханәсе эргәсеннән башын кырын салып, «Кысла»га таба үтеп баручы Мөдәррисне күреп алса, һичшиксез: «Сәлам, Тукай, ник кермичә узып барасың болай?» – дип үпкәләбрәк, тәрәзәсеннән эндәшер иде.

Кайта-кайта «Тукайдан хатлар»ны укыйм. Тукай, үләр алдыннан, сихәтләнмәмме, дип, авылга кайткан. Юрган, ике мендәр (!) тектереп алган.

Моң белән мүкләнгән кечкенә йорт май кебек – көнгә ике тапкыр ягалар. Сабый чагыннан туңган Тукай җылыга кинәнә.

«Ә син туңып кара!»

«Моңнары Аккош күлендәге такта алачыкта – матчасына бәйләм-бәйләм мәтрүшкә, әнис, бөтнек, каен себеркеләре эленгән, өстәлдә өем-өем кәгазь, ипи, суган, стакан; агачтан корыштырылган караватта иске пәлтә (ястык та, мендәр дә шул) яткан бүлмәдә кышларны чыккан Мөдәррис Әгъләмов та Тукайдан ким туңмагандыр, – дип яза Фәиз Зөлкарнәй. – Хәер, Тукайны Мөдәррис Әгъләмов хәленә куйсаң, егерме җидегә дә тарта алмас иде, мөгаен...» ■

М.Әгъләмов (уртада баскан) каләмдәшләре Рәдиф Гаташ, Мансур Вәлиев һәм Марсель Галиев белән

Безнең мирас №6 июнь 2022

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

Торараш хакыйкать

Рабит Батулла

Альфред Лепа, Шәриф Камал, Барый Абдуллин, Гомәр Байчурин, Кәрим Тинчурин. 1936 ел

Бу фотосурәт Коммунистлар партиясенең ТАССР өлкә комитеты бинасында төшерелгән. Арттагы диварда Ленинның томанлы портреты шәйләнә.

Беренче рәттә сулда утырган кеше – Альфред Карпович Лепа (1896-1938), ТАССР өлкә комитетының беренче секретаре (1933-1938), чыгышы белән Латвиядән. Ул 1938 елда Советлар зинданында атып үтерелә. Сылтау – Советларга каршы корткычлык эшләре, террорчылык, Советка каршы баш күтәрүдә катнашу дигән ялган әләкләр.

Беренче рәттә уртада утырган кеше – язучы Шәриф Камал (1884-1942). НКВД ни өчендер аңа кагылмый, ул үз үлеме белән вафат була.

Беренче рәттә уңда утырган кеше – Барый Абдулла улы Абдуллин (1889-1937), язучы Мария Елизарованың ире, ТАССР өлкә комитетының идеология секретаре.

Икенче рәттә сулда басып торучы кеше – Үзәк башкарма комитеты секретаре Гомәр Гыйльметдин улы Байчурин (1896-1938). Репрессиягә сылтау – троцкийчы,

контрреволюцион-террорчылык оешма башлыгы. «Махсус өчлек» аны атарга хөкем итә. Карар шул көнне үк гамәлгә ашырыла.

Икенче рәттә уңда басып төшкән кеше – драматург Кәрим Тинчурин (1887-1938). Ул совет зинданында атып үтерелә. Сылтау – халык дошманы.

Өлкә комитеты бюросы утырышында идеология секретаре Барый Абдуллин болай дип әйтә:

– Иптәшләр! Минем бик җитди тәкъдимем бар! Вак буржуа вәкиле шагыйрь Габдулла Тукайның китапларын алга таба бастырып чыгаруны катгый тыярга кирәк, дим!

Беренче секретарь Альфред Лепа сабыр, ләкин таләпчән тавыш белән Абдуллинга каршы төшә:

– Бари Абдуллович! Прошу Вас, не надо дразнить национальные чувства татар! Бу – татар җәмгыятенең кайбер катлаулары арасында провокацияләргә китереп чыгарырга бик мөмкин! Һәм бу гамәлнең шушы вакытта бик дәһшәтле хәлләргә алып чыгуы бар! – ди.

Утырышта Барый Абдуллинның тәкъдиме кабул ителми.

Озакламый аларны кулга алалар. Атарга алып барганда Альфред Лепа болай дип кычкыра (татарча тәрҗемәдә бирелә – *Р.Б.*):

– Иптәшләр! Сталин килер, дөреслек ачылыр һәм сез, җәлладлар, бу эшегез өчен җавапка тартылачаксыз! – ди.

Рәсемгә игътибар итик. Ихтимал, Өлкә комитеты секретарьләре ике атаклы язучыны үзләренә чакыртып алгандыр. Күрәсең, тар даирәдәге утырышта К.Тинчуринның 25 еллык хезмәтенә багышланган тантана турында сөйләшкәннәрдер. Кичә 1936 елның 28 маенда уза, төп нотыкны Байчурин сөйли. Күп тә үтми, боларның Ш.Камалдан башкаларын алып китеп аталар.

***

Үткәннән янә ике фото...

Ш.Камал гаиләсе белән. 1930 нчы еллар

Ш.Камал хатыны Хәят, кызы Зәйнәп һәм улы Йосыф белән ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

Колынчаковлар утарында

Ренат Абянов, Марат Сәфәров

Колынчаковларның нәсел дәвамчысы Александр Куприн үзенең эш бүлмәсендә. Гатчина, 1912-1913 нче еллар

Темников төбәге татар халкының тарихи хәтерендә аристократия, морзалар нәселләре, феодаль җир биләүчелек белән бәйләнгән. Хәзер дә Мордовиянең көнбатышында нәсел җепләре турыдан-туры затлы фамилияләргә тоташкан бихисап гаиләләр яши: Еникеевләр, Мамлеевлар, Урусовлар, Дашкиннар, Тегуловлар, Хуҗиннар, Акчуриннар, Дивеевлар... «Темников: мәмләкәтләр кирмәне» китабын әзерләгәндә без, билгеле, таралып яткан хроникаларны һәм мөселманнарның дворянлык статусын кире кайтаруны сорап язган иксез-чиксез гозерләрен генә өйрәнеп калмадык. Аннан тыш, замандашларыбыз белән

дә күрешеп сөйләштек. Очрашу урыны – үткән белән киләчәкне матур гына тоташтыра алган күркәм, җанга якын авыллар, Темниковның кунакчыл йортлары булды...

Ә менә бер нәселнең эзләрен эзләп хәтта рус дворяннары яшәгән Стрельниково утарына да барып җиттек. Анда хәзер торган йорт 1905-1910 нчы елларда корылган, искесе – агачы инкыйлаб вакытында крестьяннар тарафыннан яндырылган. Әлеге утарның хуҗасы – Алексей Николаевич, ул – статский советник Николай Алексеевич Колынчаковның улы. Бу йорт немец архитектура проекты буенча биш елга якын төзелгән. Аның ике подъезды, ике балконы һәм пыяла верандасы булган; утар үзе, җиләк-җимеш бакчасын, Наполеонны җиңүгә 100 ел тулу хөрмәтенә 1912 елда утыртылган аллеяны, елына 79 мең чиләк спирт җитештерүче заводны һәм сәүдә биналарын берләштереп, шактый мәйдан биләп торган. Биредә иген игүче, бәрәңге үстерүче, терлек һәм бал кортлары үрчетүче крестьяннарга кредитлар бирә торган банк та эшләгән. Ат абзарында армия өчен юртаклар тәрбияләнгән. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, 1914 елда, биналарның берсендә яралылар өчен хастаханә ачылган. XIX гасыр ахырында ук Колынчаковлар пар машинасы ярдәмендә электр энергиясе эшләп чыгарган. Башка крестьяннар керосинка яисә чыра яндырганда Колынчаковлар утарындагы халык электр яктысыннан кинәнгән. Чит илдән кайтарылып, подвалга урнаштырылган казаннар бөтен өйгә җылылык тараткан.

Әмма, ни кызганыч, әлеге бинага озак еллар төп нигез булып торырга язмый. Колынчаковлар Стрельниковода 1919 елга кадәр яши. Аннан соң, совет хакимияте карары буенча, башка алпавытлар кебек үк, алар да Темников шәһәренә күчерелә, соңрак бөтенләй чит-ят шәһәрләргә һәм губерналарга таратыла, малмөлкәтләре дәүләт тарафыннан тартып алына.

Хикмәт шунда: атаклы урыс язучысы Александр Купринның нәсел җебе шушы Колынчаковларга барып тоташа. Әдипнең әнисе Любовь Алексеевна (1838-1910) кыз чагында Колынчакова фамилиясен йөртә. Купринның «Юнкерлар» автобиографик романыннан алынган юллар безнең сәфәрнең лейтмотивы булды: *«Ул (төп герой Алексей Александров. – Авт.) бу мизгелдә үзенең тамырларында әнисе ягыннан татар морзалары булган тыелгысыз һәм дуамал бабаларының котырынкы каны кайнавын белми иде әле».* «Соңгы рыцарьлар» хикәясендә дә татар генеалогиясенә һәм хәтта ислам диненә дә ишарә бар: *«Шуннан соң генерал папирос кабызды, Тулубеевка да тартырга тәкъдим итте һәм:*

– Сезнең тамырларыгызда татар каны бармы? – дип сорады.

– Нәкъ шулай, галиҗәнап әфәнде. Без – борынгы Касыйм кенәзләре нәселеннән. Беренче булып безнең бабабыз исламнан нәсара диненә күчкән һәм урыс хатынына өйләнгән.

Л. башын селкеде:

– Татарлар – бик яхшы халык; алар барысы да намуслы, сүзгә тугры, пөхтә, кыю, матур; искиткеч оста җайдак һәм менә дигән сугышчы үзләре. Ә ислам дине шулкадәр гади. Ул шундый җайлы, авырлык китерми һәм кешене никадәр югары күтәрә».

Колынчаков фамилиясенең «колын, колынчык» сүзеннән барлыкка килүен Куприн, әлбәттә, белгән. Әнисенә юллаган соңгы хатларының берсендә ул болай дип яза: *«Минем балконда яшел болында утлаган колын рәсеме төшерелгән байрак җилферди».* Иван Бунинга адреслаган хатында да ул мондый аңлатма бирә: *«Яшел болын җирлегендә төшкән алтын колын – морза кызы Колынчакова*

рухының байрагы, бу – герб». Яисә тагын «Юнкерлар»га мөрәҗәгать итик, анда Алексей Александровның әнисе: *«Синең абыең, минем борадәрем булган Аркадий Алексеевич Пенза һәм Тамбов губерналарында иң дуамал татар кешесе иде, ат җене кагылган иде аңа. Йа Хода,ниләр генә майтармады ул гомерендә... Үзенә тиң кардәшләре белән бергә һаман кәеф-сафа кора торгач, ахыр чиктә, ата-бабаларыбыздан калган гаҗәеп ат заводын да харап итте»,* – дип сөйли.

Монысы инде Парижда сыену тапкан, әмма, күп эмигрант дусларыннан аермалы рәвештә, соңгы сулышын алыр алдыннан булса да туган иленә кайта алган чал Купринның сүзләре: *«Минем атларга булган мәхәббәтем – канымда, ул миңа борынгы татар бабаларымнан күчкән. Әнием Колынчаковлар нәселеннән. Ә татар телендә бу сүз «колын» дигәнне аңлата. Мин балачактан ук атларга атланып дала буйлап җилдерергә яраттым!»* (Мәскәүнең Кудрино мәйданында яшәгән Саша, гадәттә, җәй айларын Пенза губернасында уздырган.)

Иван Бунин истәлекләрендә күренгәнчә, Куприн *«чын ханнар кебек җәелеп утырырга һәм андый чакта күзләрен аерата кысып төбәлергә»* яраткан. Бер-ара ул хәтта шәрык халатына төренеп, башына түбәтәй киеп йөргән. Язучының Гатчинадагы эш кабинетында төшкән фотосурәте бар, анда ул нәкъ шундый киемнән. Әлбәттә, биредә үзенә күрә образга керү, уйнау өлеше дә булгандыр (замандашы Феликс Йосыповның җәмәгать алдында әледән-әле шәркый тамырлары белән мактануын, Анна Ахматованың әдәби мифологиясен искә төшерик; җөмләдән, соңрак ул мифологияне улы Лев Гумилев та үзенә «күчереп ала»).

Александр Купринның әнисе Любовь Колынчакова

Бик күп дворяннар тамырланган Шәркый Россия, чикле рәвештә булса да, Петербургтагы иҗтимагыйсәнгати дөньяның бер өлешенә әверелә. Ләкин Куприн очрагында мондый калку хисләр табигый һәм нигезле кебек тоела. Колынчаковлар шәҗәрәсе XX гасыр башында урыс һәм татар зыялыларын бергә үрә.

Тымызык Стрельниковога без яз көне килдек, җир әле ташулардан соң җилләмәгән иде. Безне каеннар үзләренең ямь-яшел «кием»нәре белән каршы алды. Хәзерге Мордовиядә фин-угыр, славян һәм төрки халыклар яши, ә Стрельниково исә урыс җире буларак карала. Хәер, соңгы елларда күрше-тирәдән, шул исәптән, *Пичеполонга* авылыннан да (бу сүз

Колынчаковлар утарындагы йорт. Стрельниково авылы (Мордовия)

мукшычадан «нарат койрыгы» дип тәрҗемә ителә) күп кенә мукшылар бирегә күченә башлаган.

Пичеполонга авылы Атюрьево районында урнашкан, аннан ерак түгел, Пенза өлкәсе чигендәге Зубова Поляна районында шуңа охшаш исемле *Пичпанда* («наратлы тау») авылы бар икән. Угыр телен бу дәрәҗәдә «өйрәнеп җитү» өчен безгә Стрельниково мәктәбенең милли сыйныфында очраган язулар ярдәм итте. Мәктәп озак еллар буе алпавыт утарында урнашкан булган. Хәзер анда укыту бармый инде, сыйныф эчендәге элмә такталарда калган мордва язучыларының шигырьләре генә узган чорларның истәлеген саклый. Безгә аларны тәрҗемәдә укып бирделәр. Бинаның кечкенә генә бер өлешендә урнашкан этнографик музей борынгы мәгърур йорттагы утны мәңгелеккә сүндерергә ирек куймый. Көнкүреш әйберләре аша да мукшы теленнән бик күп сүзләр әйләнешкә кергән монда: иләкнең төрле формалары – *локстем* яки *парга*, бияләй – *варягат*, кашык – *куцю*. Һәм, әлбәттә, бар нәрсәгә баш булып торган икмәк! Мордовиядә ул аеруча тәмле, аны кши дип атыйлар. Алпавыт утарында мордва теле татар теленең мишәр диалектына караган темников сөйләше белән үрелеп бара. Стрельниководан кул сузымында гына Югары һәм Түбән Пешли исемле борынгы татар авыллары урнашкан. Шулай итеп, нәсара диненә күчеп урыслашкан морзалар биредә исламга тугры калган «туганнары» белән бергә гомер кичергән. Олы юлдан читтә урнашкан авылларда бу турыда еш ишетергә мөмкин.

Авыл җирлеге башлыгы Сәет Заһидулла улы Кильдеев якын киләчәктә Темников белән Дивеево авылын тоташтырып торачак туристлык маршрутына зур өметләр баглый. Колынчаковларның нәсел йорты – Стрельниково – бу маршрутта лаеклы урын алыр дип ышана ул. Сәет Кильдеев, аның командасы һәм ваемлы авыл халкы ярдәмендә утар хәзергәчә сакланып тора әле. Бүген дә баскычлардан узарга, элеккеге хуҗаларның кул җылысын хәтерләгән гүзәл ишекләргә орынырга мөмкин. Инкыйлабка кадәрге чорның кыйммәтле артефактлары, этнографик табылдыклар, гөрләп торган авыллар турында сөйләшү, ниһаять, 1970-1980 нче елларга, колхозлар чорына тоташа. Провинциядә Хәтер – мөһим категория. Үткәнгә караш ташлау еш кына тотрыксыз киләчәк өчен таяну ноктасы булып тора.

Бүген Стрельниковоның агачлары, ярым кыргыйланган халәттә, хуҗаларыннан башка ятимләнеп калган бакчаларда шаулый. Колынчаковлар заманында крестьяннар өчен мондагы дүле (груша), алма, слива, чия, карлыган, кура җиләге, крыжовник, җир җиләге кебек нигъмәтләр могҗизага тиң тоелган. Бакчада һәр куак мул уңыш китергән. Хәер, Җирдә һәрнәрсә вакытлыча шул.

Утар артында – татар дөньясының табигый тереклеге: урман һәм далалар. Бу җирләрдә Еники Тенишевның улы, Темников кенәзе (1571-1577 нче елларда) Колынчак Еникеевның нәселе тармакланган, шул рәвешле Колынчаковлар нәселе барлыкка килгән. Монда алар мордва халкыннан «чиреге белән 11 сум» күләмендә ясак җыйганнар, шул рәвешле татар феодалларының куәтле бердәмлегенә кушылганнар. Бер гасырдан соң Колынчак кенәзнең кайбер оныклары чукынган: әйтик, 1689 елгы чыганакларда Федор Котлымәмәтович исемле стольник очрый. Калганнар (Болганчык еллар заманында Темников һәм Арзамаста дөнья куган Ибраһим, аның абыйсы Рәҗәп) нәсаралыкка күчмәгән, шуңа күрә алар 1713 елда һәммә җир-биләмәләреннән мәхрүм ителгән.

Мөселман исемнәре тарих чоңгылында онытыла барса да, морзалар каны үз гайрәтен җуймый, ахрысы: Александр Купринның тышкы кыяфәтендә татар бабаларының чалымнары күренеп тора.

Стрельниковода беренче булып Николай Алексеевич Колынчаков (башта – урман сагы һәм хәрби ведомство вәкиле, соңрак – Казан губерна урманчысы, Темников өязе дворяннары башлыгы, статский советник) агачтан утар салдыра. Крепостнойлык хокукы гамәлдән чыгарылганчы Казан губернасының Лаеш районында аның кул астында 65 крестьяны һәм 361 дисәтинә җире була. Әмма карт кенәз, 1895 елда вафат булганчы, хатыны Софья белән бергә Стрельниковода яши. Монда исә реформага кадәр Колынчаковларның 1300 крепостной крестьяны була, алар, ирек алганнан соң да, шушы хуҗалыкта эшләргә калалар.

Аңа туган туры килгән Любовь Алексеевна Колынчакова-Куприна үзенең балачак елларын Пенза губернасына караган Наровчат өязенең Зубово авылында уздыра. Александр Куприн Наровчат өязе турында болай дип яза: *«Алпавытлар турында сүз кузгатсаң, аларның барысы да диярлек, татар кенәзләреннән иде».* Биредә Любовь Алексеевна Наровчат өязенең җәмәгать судьясы сәркатибе Иван Иванович Куприн белән таныша, соңыннан аңа кияүгә чыга. Әмма көтеп алынган уллары Саша туып күп тә үтми, 1870 елның августында, Иван Иванович ваба чиреннән үлеп китә. «Көчле холыклы һәм миһербанлы» Любовь Алексеевна, утарны сатып, балалары белән Мәскәүгә күченергә карар кыла. Ул, вәкарьлеген һәм кытыршы холкын тыеп, бар көч-куәтен, тырышлыгын балаларына төпле белем бирү өчен сарыф итә.

Александр Иванович Куприн әнисенең образын, аның яраткан сүзләрен, гаилә тарихын, Наровчат өязе һәм татар бабалары турында хикәятләрне гомер буе хәтерендә саклый һәм әсәрләренә кертә. Одесса шәһәреннән авыру әнисенә юллаган соңгы хатында Куприн: *«Мин сине (син дә минем кебек) һәрвакыт янәшәмдә хис итәм, чөнки безнең бер-беребездән якынрак кешебез юк»,* – дип яза.

Язучы үзенә зур йогынты ясаган әнисен «татар ханбикәсе» дип атый. Александр Ивановичның кызы Ксения Куприна (1908-1981) әтисен мондый сүзләр белән искә ала: *«Әти-әнисе ягыннан татар чыгышлы булуы белән гел горурлана иде... XVII гасырның икенче яртысында Александр Ивановичның ерак бабасына Наровчат өязендә (Пенза губернасы) җирләр бирелә. Колынчаковлар нәселенең соңгы вәкиле булып Купринның әнисе – Любовь Алексеевна санала».*

Наровчат авылында, Купринар гаиләсенең элеккеге йорты урынында, хәзер 40 ел буе инде А.И.Купринның әдәби музее эшли. Мукшы һәм Шалдавыч елгалары кушылган җирдән ике чакрым ераклыкта урнашкан бу авыл соңгы елларда Купринның туган җире һәм Алтын Урда мәркәзләренең берсе буларак һаман да ешрак телгә алына. Шушы төбәктә Үзбәк хан ислам динен Евразиянең гаять зур киңлекләрендә дәүләт дине итеп таный.

Темниковка багышланган китабыбызга Наровчат турындагы мәкалә ни хронология, ни этнография җәһәтеннән кирәргә тиеш түгел иде. Без, Шалдавыч, Аккүл-Тараклы, Лакау, Чудовка, Щербаковка кебек татар авылларының кызыклы исемнәреннән сихерләнсәк тә, Пенза өлкәсе белән Мордовия чигендә экспедициябезгә нокта куярга мәҗбүр булдык.

Стрельниковога яңадан кайтып килергә кирәк әле. Купринның данлыклы исеменә сыенып, утар янә торгызылыр һәм Колынчаковлар нәселе хакындагы истәлекләр бик озак еллар буе киләчәк буыннарга тапшырыла барыр дип ышанасы килә.

Мәскәү-Мордовия-Мәскәү

(Язма «Татар дөньясы/Татарский мир» газетасыннан алынды.) ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

ФӘХРЕДДИН РИЗАЭДДИН (1859-1936)

Татар тарихчысы. Энциклопедист. Ризаэддин Фәхреддин (Ризаэддин Фәхреддин улы Фәхреддинов) 1859 елның 16 гыйнварында Самара губернасына караган Бөгелмә өязендәге (хәзерге Әлмәт районындагы) Кичүчат авылында мулла гаиләсендә туган.

1910 елда жандармнар аның өенә бәреп кереп, тентү ясыйлар, татар тарихына кагылышлы бөтен кыйммәтле документларны олауга төяп алып чыгап китәләр дә яндыралар. Идарәгә коммунистлар килгәч тә, аңа көн күрсәтмиләр. Ул бу талауларны кичерә алмый – 1936 елның 12 апрелендә Уфада вафат була.

ФИДАИ ШАМУН (1902-1920)

Татар шагыйре. Шамун Фидаи (Касыйм Мөхәммәтҗан улы Шакирҗанов) Оренбургта көр тормышлы гаиләдә туып-үсә. Атасы Мөхәммәтҗан (кайбер чыганакларда – Хәсән) – хәзерге Әтнә районына кергән Олы Бәрәзә авылы тумасы.

Ш.Фидаи белән дусты, егерме яшьлек Бари Башмаковны комсомол эше белән авылларга юллыйлар. 1920 елның июнь урталарында Иске Камышлы авылы (хәзерге Кушнаренко районына керә) тирәсендә алар совет тәртипләренә каршы баш күтәргән гыйсъянчы крестьяннар кулыннан һәлак булалар.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ХУҖАХМӘТ ӘДҺӘМ

Татар артисты. Әдһәм Хуҗахмәтов, Күчмә театр шартларында арбадан чанага күчеп, яңгыр-бураннарда авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә йөреп, спектакльләрдә уйнады. Ул, тырышып-тырмашып, үз акчасына йорт салып керде, гаиләсен түбәле итте.

Кемнең ни үче булгандыр, төнлә йортына бәреп кереп, аны үтереп чыктылар. Бик куәтле һәм гайрәтле кеше иде, каты каршылык күрсәткән, әмма дошманнар күп булган.

ХӘМИТОВ МАЛИК (1930-1983)

Татар язучысы, мөхәррир, 1966 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. Малик Хәмитов (Габделмалик Әхмәдулла улы Хәмитов) 1930 елның 22 августында Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районына караган Күгәй авылында игенче гаиләсендә туган.

1983 елның 17 июлендә Казанда кичке якта эштән кайтып килгәндә аны исерек җанкыючылар кыйнап үтерәләр.



ХӘСӘНОВ ГАРӘФИ (1921-1992)

Татар язучысы. Гарәфи Хәсәнов (Гарәфетдин Хәким улы Хәсәнов) 1921 елның 13 июнендә Казан шәһәрендә һөнәрче гаиләсендә туган.

1942 елның 27 маенда ул, «милләтчел оешма әгъзасы» буларак, НКВД махсус киңәшмәсе тарафыннан 58-2, 58-10 б.2, 58-11 маддәләре буенча хөкем ителеп, хезмәт белән 8 ел төзәтү лагерына озатыла. Красноярск краенда тоткынлыкта булганда, Гарәфи Хәсәнов 1948 елда яңадан сөргенгә хөкем ителә һәм Красноярск краеның Зур Улуй районындагы Симоново авылындагы балалар йортында һәм интернат-мәктәптә эшче, тәрбияче хезмәтендә була. 1955 елда аның җәза срогы 5 елга калдырыла, аннары ул амнистия буенча иреккә чыга. Гарәфи Хәсәнов 1990 елда тулысынча акланды һәм 1992 елның 15 апрелендә вафат булды.

Текстны басмага
***Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Өзелгән җыр

Шәүкәт Галиев (сулда) һәм Самат Шакир мәктәп музеенда

Казанда Яңа Савин районының Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йортында Балалар әдәбияты музее бар. Бу музей үзенчәлекле экспонатларга бик бай. Биредә шагыйрь Шамил Гәрәйнең фотолары, документлары, рәсем альбомы, китаплары, газета төпләмәсе һәм шәхси әйберләре дә урын алган.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле еллары ераклаша бара. Быел халкыбыз фашист илбасарларын җиңүнең 77 еллыгын билгеләп үтте.

Илебез халкы 1941 елда явызларча басып кергән фашист илбасарларына каршы изге көрәшкә күтәрелә. Бу көрәштән әдәбият һәм сәнгать әһелләре – әдипләр, рәссамнар, композиторлар һәм артистлар да читтә калмый. Аларның коралы – повесть һәм драма әсәрләре, хикәяләр, публицистика, очерк, рәсемнәр, җырлар – бер яктан, сугышчыларда патриотик хисләр, Җиңүгә өмет уятса, икенче яктан, дошманга нәфрәт тәрбияли. Шулай итеп, алар үз Ватаннарының азатлыгы өчен мылтык белән генә түгел, ә каләмнәре белән дә көрәшә.

Сугышның беренче көннәрендә 53 әгъзадан торган Татарстан язучылар берлегеннән 25 кеше фронтка китә: М.Җәлил, Ф.Кәрим, С.Хәким, Ә.Исхак, Г.Кутуй, Ә.Фәйзи, Т.Хуҗиев, С.Баттал, Н.Дәүли, Г.Әпсәләмов һ.б.

Сугыштан кайтмый калган язучылар арасында минем әниемнең абыйсы Шамил Гәрәй дә бар.

Ә кем соң ул Шамил Гәрәй?

Шамил Гәрәй – Казан тумасы. Ул биредә 1916 елның 31 декабрендә хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә.

Дәү әнинең сөйләве буенча, аларның гаиләсе башта Татарстан (Евангелистская) урамындагы 66 нчы йортта яшәгән. Аннары К.Маркс урамындагы 8 нче йортка күченгәннәр.

Әтисе Мөхәммәтгали – Вахитов исемендәге сабын заводында, ә әнисе Рабига тегү фабрикасында эшләгән. Гаиләдә, Шамилдән кала, ике кыз бала булган: Рәйсә һәм Ләлә. Ләлә театр техникумын тәмамлый, соңыннан ул завод эшчесе була. Рәйсә исә хезмәт юлын хисапчы һөнәре белән бәйли.

Шамил Гәрәй Тукай урамында урнашкан Гаспринский мәктәбендә укый. Бу мәктәп үз чоры өчен көчле мәктәпләрдән санала. Шамил анда укыган чагында ук яшьтәшләреннән тырыш һәм сәләтле булуы белән аерылып тора. Ул күп укый, музыка белән кызыксына, гармунда һәм пианинода уйный, рәсемнәр ясый.

Шамилнең архивында рәсем альбомнары сакланган. Аның иң зур кызыксынуы, әлбәттә, – шигърият. Ул үзенең беренче шигырен 10 яшендә иҗат итә.

Фронтовик-рәссам Мансур Рәхимов үзенең балачак хатирәләрендә болай дип искә ала: *Әкияттәге кебек өч дус үстек без. Аның берсе – балалар язучысы, фронтовик шагыйрь – Шамил Гәрәй. Икенчесе – Балтыйк диңгезендә хезмәт иткән фронтовик Әнвәр Сабирҗанов. Уку еллары, егетлек чоры мәңге хәтердә... Һәрберебез тормышта үз юлын, үз кыйбласын табарга тырышты.*

Шамил Гәрәй шигырьләр язарга ярата иде. Мәктәп елларында ук аның шигырьләре «Яшь ленинчы» газетасында (хәзерге «Сабантуй» журналы. – Ф.С.) даими басылып килде. Эшкә дә шушы газета редакциясенә урнашты...»

Шамил Гәрәй күп укый, шәһәр китапханәсендә еш була. Аңа бигрәк тә Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Һ.Такташ әсәрләре ошый. Бу язучыларның иҗатын өйрәнү Шамилнең шагыйрь булып формалашуына зур йогынты ясый.

1932 елны аның әтисе вафат була. Шамил җиденче сыйныфны тәмамлый. Аларның гаиләсе бик авыр тормышта яши, аның хәтта язу өстәле дә булмый. Кыз туганнары әйткәнчә, Шамил төннәрен аш өстәле астына кереп, шигырьләрен керосин лампасы яктысында иҗат итә...

Язучы, журналист Ләбиб Лерон «Яшь ленинчы» газетасында (1985) язганча: *«Шамил Гәрәй исеме матбугат битләрендә 30 нчы елларда күренә башлый. 15 яше тулгач, ягъни 1931 елда ул, шигырьләрен күтәреп, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә килә. «Шигырьләрең миңа ошады», – ди кара тутлы, чәчен бер якка шома итеп тараган иптәш. Бу балалар язучысы Абдулла Алиш була. «Октябрятлар җыры» дигән беренче шигыре газета битләрендә басылып та чыга. Мәшһүр әдип фатихасы белән, Шамил Гәрәй шушы газетаның балалар хәбәрчесе булып китә. Әнә шул көннәрдә аның әдәбиятка юлы ачыла... Бер ел узуга, яшь шагыйрьнең «Сигналчы җыры» исемле беренче китабы дөнья күрә. Берничә елдан «Яшь ленинчы»*

газетасының әдәби бүлеген җитәкли. «Пионер каләме», «Техника» журналлары һәм башка вакытлы матбугат битләрендә дә шигырьләре, хикәяләре, хәбәр язмалары даими рәвештә басыла башлый...»

«Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы редакциясендә эшләгән журналист Мәрьям Дибаева «Элита Татарстана» журналында шагыйрьне болай дип искә алган: *«Шамил Гәрәй дигәч, минем күз алдыма урта буйлы, базык гәүдәле, түгәрәк йөзле егет килеп баса. Күпмедер вакыт ул «Яшь ленинчы» газетасы, «Пионер каләме» журналы редакцияләрендә эшләп алды. Аннары китап нәшриятындамы, башка газета-журналлар редакцияләрендәме, анысын анык белмим, эшләп йөрде. Әмма безнең редакциягә Шамил бик еш килә иде. Яңа язган шигырьләрен укып, бастырып чыгарырга калдыра, хәбәрчеләребездән килгән шигырьләргә күз йөртеп ала, кайчагында аларга үзенең киңәшләрен әйтеп хатлар да яза. Мин аны Абдулла Алиш янында еш очрата идем. Бик күп еллар – ярты гасырдан артык вакыт үткән бит инде. Күп нәрсәләр онытылган. Шулай да Шамил минем хәтеремдә ничектер бик аз сүзле, артык дәрәҗәдә тыйнак бер шәхес булып калган. Әгәр ул, әсирлек һәм тоткынлык газапларын күрмичә, сугыштан исән-имин кайтса, Сибгат Хәкимнәр дәрәҗәсендәге күренекле шагыйрь булыр иде. Без аны бик яшьләй югалттык шул...»*

Шамил Гәрәйнең китаплары

Шамил Гәрәйнең һәр шигырен, һәр хикәясен, һәр мәкаләсен балалар көтеп ала. Чөнки шагыйрь алар белән үз күреп, дус итеп сөйләшә. Ул чын иҗат ялкыны белән яна. Абдулла Алиш кебек асыл осталар янында каләме чарланганнан-чарлана бара. Шагыйрь шигъри осталык биеклекләрен яулый. Бер-бер артлы яңа җырлары, яңа китаплары дөнья күрә.

Язучы, галим Җәвад Тәрҗеманов үзенең «Очрашулар, сәяхәтнамәләр, истәлекләр, эзләнүләр һәм әдәби портретлар» дигән китабында мондый юлларны яза: *«1934 нче елда мин, ниһаять, «Пионер каләме» журналына һәм «Яшь ленинчы» газетасына языулдым һәм, үзем дә сизмәстән, әдәби иҗат мәктәбенә килеп кердем. Газета битләрендә Муса Җәлилнең бер-бер артлы басыла барган җырлары, Фатих Кәримнең «Аучы» поэмасы, Г.Мөхәммәтшин һәм Ш.Гәрәй шигырьләре минем өчен шатлыклы яңалык булды.*

1935 елның сентябрь азакларында Казан Үзәк балалар китапханәсендә «Яшь каләмнәр» берләшмәсе оештырылды. Берләшмәнең җитәкчесе итеп Татарстан Язучылар берлегеннән шагыйрь Галимҗан Мөхәммәтшин билгеләнде. Безнең утырышларга ул бервакытта да үзе генә килми, язучылардан кемне дә булса алып килә. Анда безгә Сафа Гыйльфан, Сибгат Хәким, Шамил Гәрәй, Абдулла Алиш, Фатих Хөсни, Идрис Туктаров үзләренең әдәбияттагы беренче адымнары турында сөйлиләр, яңа әсәрләрен укыйлар иде.

Казан Үзәк балалар китапханәсе каршында оештырылган «Яшь каләмнәр» берләшмәсе түгәрәгенең эш дәфтәреннән:

«1935 ел, 24 ноябрь

Тугызынчы утырыш.

Бүген түгәрәккә Шамил абый һәм Сибгат абый Хәким килде.
Көн тәртибе:
1. Шамил абый Гәрәй белән танышу.
2. Төрлеләр.

Шамил абый Гәрәй үзенең яшь чагында ничек яза башлавын һәм язган әйберләрен редакциягә ничек илтүен сөйли. Язучы һәм шагыйрь булу өчен үзең алган өлкәне сөя белергә кирәклеген әйтә. Үз китапханәсе булуын һәм рус классикларын күп укуы турында сөйли. Аннан лирик шигырьләргә күчеп, аларның нинди мәгънә белдерүен аңлата. Галиуллин: «Кече яшьтә нинди әсәрләр укыдыгыз? – дип сорый. Ш.Гәрәй: «Кечкенә чагымда Такташ шигырьләрен күп укыдым. Башка жанрларга караганда поэзияне яратам», – ди һәм үзенең шигырьләрен укый...»

1933 елда Шамил Гәрәйнең – «Флюра», 1934 елда – «Звено җыры», 1937 елда – «Тормыш иртәсе», 1941 елда «Тормыш чәчәкләре» дигән китаплары басылып чыга. Язучы Самат Шакир: *«Шамил Гәрәй шигырь техникасын Г.Тукайдан өйрәнә. Аның шигырьләре сәнгатьчә оста эшләнеше, рифмаларының яңа булуы, ритмнарының төзеклеге белән аерылып тора»,* – дип яза.

Ш.Гәрәйнең әсәрләре күренекле язучылар тарафыннан да хуплана. Шагыйрьнең архивында аларның автографлары язылган китаплар да күп. Ул язучылар белән бергә Урал якларына һәм Харьковка бара. Татарстан Республикасының Үзәк дәүләт архивында бу турыда материаллар саклана.

Ш.Гәрәй үзен тәрҗемә эшендә дә сынап карый. Ул А.Барто шигырьләрен, Л.Квитко, М.Лермонтов, А.Чехов әсәрләрен тәрҗемә итә.

Язучының архивында А.Алиш китаплары да бар. А.Алишның «Минем абыем» китабына автор кулы белән мондый сүзләр язылган: *«Шамил дустыма! Истәлек өчен. А.Алиш. 20.12.40.».*

А.Алишның туганы Илсөяр Сөнкишева истәлегеннән (20.12.1969): *«Язучы Абдулла Алишның Шамил Гәрәй исемле бер яшь дусты булганын беләбез. Яшь аермалары 9 ел чамасы. Шулай булса да, аларны якын дуслар, хезмәттәшләр дияргә мөмкиндер. Бу иҗади дуслык берничә ел дәвам иткән.*

1933-1936 нчы елларда, Абдулла Алиш татар телендә чыгып килгән «Техника» журналында җаваплы секретарь булып эшләгәндә, яшь иҗат көчләрен, хәтта балаларны-үсмерләрне дә техник темаларга язмалар белән катнаштыра килгән. Менә шушы журналда Шамил Гәрәй дигән авторның да мәкаләләре еш басылган. Шуларның кайберләре:

1. «Серле җәдвәл» – «Техника», №8, 1933 ел;

2. «Яшь техниклар күргәзмәсендә» – «Техника», №9, 1933 ел;

3. «Колхозлардагы техник ударниклар» – «Техника», №10, 1933 ел һ.б.

Белгәнебезчә, бу журналның соңгы битләрендә «Балалар бүлеге», «Яшь техниклар почмагы» оештырылып, балалар өчен материаллар бирелеп килгән. Хәзер зур галим, техник фәннәр докторы, Халыклар дуслыгы университеты профессоры Габделхак Галиуллинның да (ул чакта 13 нче мәктәпнең 6 нчы сыйныф укучысы) беренче мәкаләсе шушы журнал битләрендә басылган. Бу мәкалә «Мин ничек телескоп ясадым?» дип атала («Техника», №1, 1934 ел).

«Пионерлар һәм мәктәп балалары! Техниканы үзләштерү өчен көрәшкә!», «Яшь техниклар һәм уйлап табучылар күбрәк җитешсеннәр!» дигән лозунг (чакырулар) куелып, шуны тормышка ашыруда журнал үзеннән зур өлеш керткән.

Ул елларда Казанда ВОИЗ һәм БРИЗ дигән оешмалар булган (Всероссийское общество изобретателей, Бюро рационализаторов и изобретателей). Ш.Гәрәй мәкаләләренең ахырына еш кына «ВОИЗ комитетыннан» дигән сүзләр язылган. А.Алиш үзе дә БРИЗ члены булган.

Аларның бу өлкәдәге эшчәнлекләрен дә өйрәнеп, тиешле бәя бирәсе иде.

1933 елның 5-6 июль көннәрендә Шамил Гәрәй слетта катнашкан.

Ә 1936 елда Абдулла Алиш белән Харьковка иҗат командировкасына баралар. СССРда беренче булып ачылган Пионерлар сараеның эш тәҗрибәсен өйрәнәләр. Кайткач, берләшмәдә отчет бирәләр. Бу отчет беркетмәләре архивта саклана».

Шамил А.Алишның улларына багышланган «Алмаз белән Айваз» дигән шигырен язган. Бер әдәби кичәдә укучылар ул шигырьне Алмаз Абдулла улына сөйләде.

Ш.Гәрәйнең берничә шигыре язучы Самат Шакирның. «Алар сафта» дигән китабына да кертелгән. Ул китап фронтовик язучылар – М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Нур Баян, Ш.Хәйри, Ш.Гәрәйгә багышланган.

Самат Шакир истәлегеннән бер өзек: *«Минем шагыйрь булып китүемә Шамил Гәрәйнең шигырьләре зур тәэсир ясады. Без мәктәптә укып йөргәндә Шамил Гәрәйнең «Урман буенда» җырын күмәкләп җырлый торган идек. Отрядта бу җырны бик зурлап җырлап йөргәнебезне хәтерлим:*

Җәйге урман.
Нарат агачлары
Гаскәр кебек тезелеп киткәннәр.
Җиләк урыны –
Яшел куаклыклар
Урман буен бизәп киткәннәр.
Салмак кына
Йомшак искән җилләр
Яфракларны селкеп шаулата,
Җырчы кошлар
Агач арасыннан
Сузып җырлап урман яңгырата.

Бу җырның көен композитор Җәүдәт Фәйзи язган.

Шагыйрь балаларга туган илебез табигатенең матурлыгы турында сөйли. Аның бу елларда язылган әсәрләрен бәхетле балачак шигырьләре дип атарга мөмкин.

Еллар үтте. Мин, Шамил Гәрәйнең шигырьләрен җыеп, «Алар сафта» дигән китап чыгардым. Бу китапка аның биш шигыре керде. Шул шигырьләрне җыеп йөргәндә, Шамил Гәрәйнең әнисе Рабига апа өендә булдым. Ул, елый-елый, улының һәлак булуы турында сөйләде. Мин шуннан соң, Ш.Гәрәйнең барлык шигырьләрен җыеп, «Совет әдәбияты» журналында да бастырып чыгардым...»

Әнә шундый талантлы каләм иясенең иҗаты чәчәк аткан вакытта илебезгә немец-фашист илбасарлары бәреп керә. Сугышның беренче көннәреннән үк шагыйрь фронтка китә. Аны А.Алиш һәм туганнары озатып кала. Шамил Гәрәй

алгы сызыкта дошманны мылтык һәм каләм белән «кыйный». Каты сугышлардан соң, ял вакытларында ул шигырьләр яза. Мәскәү янындагы сугышларда «Дошман җиңелер!» дигән шигырен язып, «Фронт» газетасында бастыра.

Кече командир Шамил Гәрәй ифрат кыен хәлләргә, күп михнәтләргә тарый. Мәскәү янындагы рәхимсез сугышларның берсендә чолганышта кала, контузия ала, фашистлар кулына әсирлеккә төшә. Ул тимер чыбык киртә эчендә дә үзенең башлаган җырын дәвам итә, фашистларга каршы сатирик шигырьләр яза. Ш.Гәрәйнең туган илен сагынып язган шигырьләре дә булган, ләкин алар югалганнар. Биш елга сузылган тоткынлык чоры эзсез узмый – аның сәламәтлеген какшата. Әсирлектән котылгач, ул Польшаның Гливице шәһәрендәге госпитальдә дәвалана.

Мәкалә авторы Фәридә Сәлимова туганы – шагыйрь Шамил Гәрәйнең кабере янында

Шагыйрьнең туганнары бөтен сугыш дәвамында Шамилдән хат-хәбәр көтә. Фәкать Җиңү көннәреннән соң гына аннан хәбәр килә. Бу аның 1946 елның мартында Польшадан язган соңгы хаты була: *«Кадерле әни, туганнарым Рәйсә һәм Ләлә! Мин, әле сугыш беткәндә, үземне исән-сау кеше итеп сизә идем. Ләкин сугыш елларында күрергә туры килгән газаплар, җәфалар, кичерешләр, нәләт төшкән фашизм Германиясендәге коточкыч авыр шартлар минем организмга да үзләренең төзәлмәслек печатьләрен салганнар. Авыруымның шулай каты икәнен белгән булсам, беренче хатымны сезгә язмаган булыр идем. Нәләт төшкән Германия җирендә торасы килми, туган илгә кайтасы килә...»*

Шагыйрь Шамил Гәрәй 1946 елның 22 мартында дөнья куя.

Аның җәсәден хәрбиләр зиратына җирлиләр.

2012 елда миңа Польшага бару һәм Гливице шәһәрендәге госпитальне күрү насыйп булды, зиратта да булдым.

Шагыйрь Шамил Гәрәй тормышның шиңмәс чәчәкләре булган балаларга дан җырлады. Безнең хәтер булып яши ул җырлар!

Фәридә Сәлимова,
Яңа Савин районының Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йорты каршындагы Балалар әдәбияты музее җитәкчесе ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

Истә, һаман да истә!

Дәүләт эшлеклесе Кыям Абрамовның тууына 125 ел

Дәүләт эшлеклесе, 1930-1937 нче елларда ТАССР Халык Комиссарлары Советы рәисе (1930-1937) Кыям Әлимбәк улы Абрамов 1897 елның 7 июнендә Сембер губернасының Буа өязендәге (хәзерге Буа районы) Иске Тинчәле авылында туган. 1911-1916 нчы елларда Екатеринослав губернасында француз күмер компаниясенең 1 нче ташкүмер чыгару шахтасында забойчы ярдәмчесе, аннары забойчы булып эшли. Шахтада җимерелү булып, гарип кала: сул кулын кисәләр. Кыям, бабасы Ибраһимның исемен үзгәртеп (Абрамов), үзенә фамилия итеп ала.

К.Абрамов хөкүмәт рәисе булганда, ТАССР аграр-сәнәгать республикасына әверелә, җөмһүрият зур төзелеш мәйданын хәтерләтә: Казанда синтетик каучук, авиация, моторлар төзү, СК-4 һәм кинотасма заводлары, ТЭЦ-1, ТЭЦ-2, районнарда электр станцияләре төзелә. ТАССРда нефть табу эше дә К.Абрамов җитәкчелегендә башлана, Казан химия-технология институты, Казан авиация институты ачыла.

1937 елның 31 июлендә Кыям Абрамов кулга алына. СССР Югары судының хәрби коллегиясе тарафыннан ул, «Инкыйлабка каршы троцкийчы-милли террор оешмасы оештыру»да гаепләнеп, үлемгә хөкем ителә һәм 1938 елның 9 маенда Казанда атып үтерелә. 1956 елның декабрендә аклана.

Шагыйрь Әмир Мәхмүдовның тууына 75 ел

Шагыйрь, әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1999), җәмәгать эшлеклесе Әмир Гобәй улы Мәхмүдов 1947 елның 28 июнендә БАССРның Әлшәй районындагы Гәбдерәшит авылында туган.

Туган авылында – сигезьеллык, район үзәге Раевкада урта мәктәпне тәмамлагач, ул 1965-1969 нчы елларда Башкортстанның Бөре шәһәрендәге педагогия институтының рус филологиясе бүлегендә белем ала.

1974-1981 нче елларда – СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1981-1992 нче елларда – Казан педагогия институтында, 1998-2002 нче елларда ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли.

1990-1995 нче елларда ул Казанда «Суверенитет» исемле газета чыгара.

«Матурлык тантанасы» (1983), «Мәңгелек моң» (1987) һәм «Әмир иле» (2008) дигән шигырь китаплары авторы.

Әмир Мәхмүдов 2018 елның 15 маенда Казанда вафат булды һәм туган авылы зиратында җирләнде.

Сәхифәне *Ләбиб Лерон* әзерләде. ■

Әмир Мәхмүдов (1947-2018) шигырьләре

Кол Гали

(Өзек)

Болгарда сугышлар бара,
Шагыйрь кыйссасын яза.
Хөсетле абыйларын да
Онытмый – бирә җәза.
Төшләрне дә юрый
белгән
Даһи шагыйрь Кол Гали.
Хатын-кыз гүзәллеген дә
Күрә белгән ул – Гали!
Яманлыкны сөймәгән ул,
Иң начары – хыянәт!
Аның өчен бар мәкерлек
Әйтерсең лә, Кыямәт!

***

Бүген заманасы башка,
Йөрмик әле зарланып.
Мең ел инде Казанга да,
Бүген яшик данланып.
Бәхет дөньясының да без
Күрәбез бит таңнарын.
Кол Гали, Җәлилләр белән
Яши татар сайланып.
Кыйссасы да кыска түгел,
Йөзек кашы татарның.
Кол Галинең мирасы да
Нигез ташы татарның. ■

ШАМУН ФИДАИНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Шамун Фидаи (1902-1920) шигырьләре

«Мөкатдәс...»

Мөкатдәс хәнҗәрем төшмәс кулымнан,
Бөтен сәдне[1] кисәрмен мин юлымнан.
Әмәл йолдызлары мәңге янарлар,
Бөтен мазлум[2] халык безне танырлар.
Очабыз, без шулай мәңге очарбыз...
Килер бер көн – сәгадәтләр кочарбыз.
Бәхет бакчасына барып керербез,
Сәгадәт чәчкәсен өзеп йөрербез.

[1] Сәд – тоткарлык, киртә, койма.
[2] Мазлум – изелгән.

Кызыл маяк

Җилләр исә. Диңгез, чеп-чеп итеп,
Киң ярларга бәрелә-кагыла...
Чайкалышып дулкын бер-бер артлы
Берсен куа... берсе тагыла...
Әнә еракларда «Кызыл маяк»,
Нәкъ йолдыздай яна... ялтырый...
Диңгездәге юлчы аңа карап,
Алга бара... изге юл сорый...
Курыкма син, юлчы! Әйдә, алга!
Әнә маяк, көрәш юлы ул...
Әнә маяк, ул бит яңа хәят,
Алда кызыл – шуның нуры ул...

Җырла әле

Сандугачкай, җырла әле,
Нурлы җырлар чәчкәләп,
Шат җырың, ямьле моңың
Берлә күңелне ачкалап...
Бар күңелләрдән агым
Моң ташкынын таштыр әле!
Уй белән, моңнар белән
Аштыр әле, шаштыр әле!

Ялкынлы теләк

Күкрәсен күк, куркынып
Китсен яшеннән ялтырап!
Бар мөнафыйклар[1] егылсын,
Җиргә төшсен калтырап!
Тетрәсен җир, йөзтүбән
Килсен сәнамнәр[2] чылтырап!
Әйдә, ташсын көчле силләр[3],
Ут кабынсын елтырап!

[1] Мөнафыйк – икейөзле.
[2] Сәнамнәр – мәҗүсиләрнең табына торган сыннары.
[3] Силләр – көчле ташулар мәгънәсендә.

Без

Ак кан диңгезе...
Без шунда шаулап,
Шаулап та даулап,
Йөзәбез көлеп,
Аптырый җир йөзе.
Йөрәктә ташкын,
Күкрәктә ярсу...
Кайгы-хәсрәт, ян...
Дулкыннар суга...
Көймә айкала.
Күңел чайкала...
Йөгреп һәм уйнап
Дулкыннар куа...
Тик кайгырмыйбыз...
Без – кызыл чәчәк,
Шәфкатьле мәләк,
Кызыл күбәләк,
Ләгънәт ормыйбыз...
Дулкын, көчләп кил!
Әйдәгез, котыр-шаш!
Гайрәтлән дә бас!
Селкенмибез дә, –
Дулкын, шуны бел. ■

Мәгърифәтче хормейстер

Илдар Кыямов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Хор дирижеры Ирнис Әхмәдулла улы Рәхимуллинны зыялы, ипле, мөхтәрәм зат, талантлы педагог буларак беләләр. Үз гомерендә ул ничәмә-ничә кешегә күмәк җырлау серләрен өйрәтте, аларның җанында татар моңына мәхәббәт уятты.

Хор Ригада чыгыш ясый. 1970 нче еллар азагы

Җырлы тормыш

Тамырлары Арча ягына тоташкан Казан егете Ирнис – сугыш чоры буыны вәкиле. Ул 1942 елның 3 февралендә дөньяга килә. Исемен еш кына немесчәдәге Эрнест белән бутап язалар, ә дөресе – Ирнис, нәфис, матур, хуш исле чәчәк атамасыннан. Әтисе Әхмәдулла абзыйдан яшьли ятим калган ул. Нәгыймә апа бердәнбер улын ялгызы гына тәрбияләп аякка бастыра. Сәләтле малай Пионерлар сараендагы балалар хорына йөри. Еш кына башлап җырлый, шуның өчен аңа төрле бүләкләр дә бирәләр. Көмеш тавышлы, матур кыяфәтле бу баланы бервакыт Татар дәүләт опера һәм балет академия театрына чакыралар һәм аннан Дж.Пуччининың «Богема» спектаклендә Малай ролендә «Мама, я хочу лошадку» дигән бер гыйбарә җырлаталар. 6 нчы сыйныфта укыганда Ирнис Артекка бара.

Анда да яшьтәшләрен җыеп җырлата, аларга җыр өйрәтә, мәш китерә ул. Яхшы җырлаучыларны аерым бастыра, колагына аю басканнарына марш атлап йөрергә куша. Нәни чактан ук сәхнәгә менгән егет киләчәктә җырчы булырга карар кыла, ләкин язмыш аңа икенчерәк һөнәр әзерләгән икән...

Урта мәктәптән соң Ирнис, тырыша-тырмаша, Казан музыка училищесында хор дирижеры белгечлеге буенча белем ала. Аннан – консерватория. Үзе кебек үк күмәк җырлауны яратучы яшьләр арасында дөнья музыкасы җәүһәрләрен үзләштерү, белемнәрне тирәнәйтү, полифоник материалдан сәнгать әсәре ясарга өйрәнү чоры.

Әле музыка училищесында укыган вакытта ук сәләтле егеткә Казан хор мәктәбенең «атасы» Семен Казачков игътибар итә. Ирнис ара-тирә аннан дирижер осталыгы буенча дәресләр ала, консерваториядә дә С.Казачков студенты була. Профессор, кайда перәннек, кайда камчы, дигәндәй, ярдәмчел булуы белән бергә, таләпчәнлек мәсьәләсендә дә кимен куймый. Укучыларына һаман төп ике нәрсәне тукый ул: «Музыка, аерым алганда, хор яки ансамбль сәнгате, ул – иң элек кеше хисләренең гәүдәләнеше. Монысы бер булса, икенчесе шул: әлеге хисләрне төгәл һәм үтемле музыкаль чаралар белән чагылдырырга теләсәң, «пахать надо»! «Иң мөкатдәс нәрсә – эш» дигәнне хөрмәтле маэстро әнә шулай үзенчә аңлатып биргән.

Тәбәнәгрәк буйлы музыкант егетне 2 нче курстан армиягә алып, кулына гранатомет тоттыралар. 1 ел да 2 ай хезмәт иткәч, ул, Казанга кайтып, укуын дәвам итә. 1970 елда консерваторияне уңышлы гына тәмамлап, шунда ук остазы белән бергә укытырга алына. Ирнис Рәхимуллин гомеренең һәр көнен, һәр мизгелен хезмәттә уздыра. Ул әле училищеда укыганда ук, 1960 елда, Ленин исемендәге мәдәният йортында хор капелласын җитәкләргә керешә, 132 нче мәктәптә балалар хорын да алып бара. Шулай итеп, унсигез яшьтән үк үз белгечлеге буенча эшли башлый. Ирнис Рәхимуллин 1975 елда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында хормейстер вазыйфасын башкара. Берара баш хормейстер да булып тора. Театрда 40тан артык музыкаль спектакль, опера һәм опереттолар куюда катнаша ул. Шул өлкәдәге эшчәнлеге өчен, аңа 1987 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирел-

1992 елгы юбилей фотосы. Солистлар – Ландыш Шәяхмәтова һәм Илдар Кыямов

Хор Әстерханга килеп төшкәч. 1990 ел

де. Ирнис абыйның Г.Камал исемендәге академия театрында «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Моңлы бер җыр» спектакльләренең хор бизәлешен башкаруы исә Мәскәү тәнкыйтьчеләренең югары бәясенә лаек булды. Саналган кадәре дә бер кешегә җитеп торадыр кебек. Тик тынгысыз маэстро тагын бер иҗат күмәгенә нигез сала.

Халык хоры

Мөгаллим – бик бәхетле кешедер. Адәм баласына дөньяны танырга өйрәтү, аларның уңышын күреп сөенү, чыннан да, сәгадәт бит! Музыка педагогларын мин икеләтә бәхетле дип беләм, чөнки алар, ата-ана үз баласын тәпи йөрергә өйрәткән сыман, укучыларына музыка сәнгатенең «әлиф»ен, элгәрләрен төшендерә, баланы илаһи моң дөньясына алып керә. Кешедә зәвык тәрбияләү, аны гүзәллеккә өндәү – гаять игелекле, мәртәбәле хезмәт. Әле хезмәтнең дә ниндие!

1967 елда була бу. Ирнис Рәхимуллин Казан дәүләт университетының филология факультетында журналистика, татар теле һәм әдәбияты бүлекләреннән студентлар туплап, хор оештыра. Дүрт тавышлы, киң яңгырашлы, чын татар хоры. Тиз арада бу коллектив халык хоры исемен яулый, классик әсәрләр башкарыр дәрәҗәдә шомара-камилләшә, ил буйлап чыгышлар ясый башлый. Татар халык хорының җырларын Санкт-Петербург, Алма-Ата, Вильнюс, Уфа, Рига, Һельсинки, Әстерхан, Йошкар-Ола һәм Самара тамашачылары да ишетә. Әлеге хор Бөтенсоюз һәм республика бәйгеләрендә җиңүләр яулады. 2001 елгы Казан хорлары ассамблеясендә дәрәҗәле урынга иреште. ТАССРның 100 еллыгына багышланган фестиваль-конкурста ул 1 нче урынны яулады. Күпсанлы конкурс һәм хор бәйгеләрендә исә дистәдән артык дипломнар, призлар алды. Күбесе беренче һәм

икенче дәрәҗә дипломнар! Санап үтелгән шәһәрләрдә дә, Казанда да хорның шактый гына әсәрләре радио һәм телевидениегә яздырылган. (Аларны бүген ешрак тапшырасы иде…) Хор әсәрләренең күбесенә бизәлеш һәм эшкәртүләрне И.Рәхимуллин үзе ясый.

Үзешчән коллективның бер үзенчәлекле ягы шул: анда җырлаучылар гел алышынып тора. Авыл баласы Казанга килә, 5 елын укый да… кайтып китә. Менә шулай биш ел дәвамында Ирнис абыйсы хорында музыкаль сабак алган яшьләр, күңелләренә ничаклы матурлык төяп, туган якларына таралыша. Күпме яхшы нәрсәләргә өйрәнә бит алар: җырлау күнекмәләре дисеңме, музыканы ишетүаңлау сәләтен әйтәсеңме, матурлык-гармонияне тоемлауны аласыңмы!.. Димәк, болар эшләгән җирендә алыштыргысыз белгеч булачак, чөнки үз фәннәреннән тыш, җыр дәресләрен дә алып бара алалар. Әле бит җырларга өйрәнүдән кала, Ирнис абый сәнгать һәм тормыш, әйләнә-тирә дөнья турында да күпме кызыклы мәгълүмат бирә! Бергәләп спектакльләр карау, классик музыка, опералар, орган концертлары тыңлау, шулар турында фикер алышу, күңелле бәйрәм кичәләре, сәфәр-сәяхәт вакытындагы «экспромт» концертлар, бәйгеләр, яз көннәрендә табигатькә чыгып, сандугачлар сайравын тыңлау студентларга эстетик тәрбия бирүдә алыштыргысыз чаралар булып тора. Шунысы мөһим: хорга телчеләр белән журналистлар гына түгел, булачак юристлар, физиклар, химиклар, биологлар, географлар да йөри.

Лирик чигенеш

1988 ел. Мин – университетның беренче курс студенты. Ара-тирә җырлап куйгаласам да, кешеләр барында җырладым юк – оялам, җиргә сеңәм, тавыш калтырый башлый, аннан бөтенләй туктыйм… Курсташ егетләр хорга барырга кыстый:

– Без синең җырлавың турында Ирнис абыйга әйттек, әйдә, ул сине чакырып калды.

Бер ай ялындыргач, киттем. Студентлар Ирнис абыйның килүен көтә. Менә КФУның төп бинасындагы 2 нче физика аудиториясен тутырып, озын кама бүрек, затлы пәлтә кигән бер әфәнде килеп керде. Исәнләшкәч, сәмруг кошларыдай тезелешеп утырган «шәкертләр»ен күз карашы белән сөзеп чыкты. (Соңрак белдем: кемнәр бар, кемнәр юк икәнне шулай чамалавы икән.) Анда-санда җырлаштыргалап йөргәнемне әйткәч, Ирнис абый сорап куйды:

– Ялгыз гына җырларга теләр идеңме?

– Шәп булыр иде дә соң, оялам шул, Ирнис абый.

– Анысы куркыныч түгел, оялмаска өйрәтәм мин сине.

Әкренләп ул мине «оялмаска өйрәтә» башлады. Репетиция тәмамлангач, мине хорчылар каршына рояль янына чыгарып бастыра да аккомпанемент уйнарга керешә, әле башта тональлекне сорый. Мин, ул өйрәткәнчә, «ре мажор», «до диез минор» дип әйтеп куям. Бу вакытта күңелне горурлык били – әйтерсең лә, мин бик күпне беләм, гүя, мин инде әллә кем… Шулай кыландыра торгач, бу мине тәмам сәхнәгә чыгарлык итте бит. Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы факультетына кереп укып, аны тәмамларлык ышаныч та тудырган икән әле ул миндә…

Ирнис Әхмәдулла улы – рухи яктан иң бай кеше. Татарстанның бөтен мәгарифмәдәният өлкәсендә, җир җимертеп дигәндәй, аның шәкертләре эшләп ята. Алар арасында дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, халык шагыйре Роберт Миңнуллин,

2017 елгы юбилей концерты

2017 елгы күмәк фото

хосусый нәшрият җитәкчесе Дамир Шакиров, Татарстан китап нәшрияты директоры урынбасары Айдар Гыймадиев, Милли китапханә директоры урынбасары Ирек Һадиев, Кама Тамагы районында хакимият башлыгы урынбасары булып эшләгән Рөстәм Гыйльметдинов; Татарстанның Санкт-Петербургтагы һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Ринат Вәлиуллин, Мөнир Нигъмәтуллов, Фәрит

Бәширов кебек фән кандидатлары һәм докторлары, галимә һәм сәнгать эшлеклесе Фәнзилә Җәүһәрова, Хәлил Сәлимов кебек профессорлар; Исмәгыйль Шәрәфиев, Флюра Низамова, Җәүдәт Дәрзаманов, Гөлшат Салихҗанова, Илгизәр Хәйруллин, Алмаз Гыймадиев, Данил Гыйниятов, Гөлүсә Сафиуллина кебек әдипләр һәм журналистлар; Резидә Кадыйрова, Ләйсән Сөләйманова, Айҗан кебек җырчылар бар. Саный китсәң, аларның исәбенә-чутына чыгарлык түгел. Кайберләре Ирнис абыйга хат язгалап тора. Үзләренең шәхес булып формалашуында Ирнис абыйның зур урын тотуын, төрле кызыклы сәфәрләрне, күңелле вакыйгаларны искә алалар. Яшь аралаш елмаеп укылган шушы эчкерсез юллар остазга бүгенге читен заманда яшәргә көч өсти, җан җылысы бирә. Сәнгатьтә күп җитәкчеләр, түземлеге җитмичә, профессиональ коллективлар белән эшләүгә күчә. Ә безнең Ирнис абый, үзешчән хорның бөтен читенлеген җилкәсенә салган хәлдә, сабыр гына үз эшен алып бара. Моннан бер-ике дистә ел элек Казан вузларында нибары өч үзешчән хор эшләп килде. Ә татар хорлары икәү генә иде. Аларның икесен дә Ирнис абый җитәкләде. Кич җитте исә, репетициягә килми изаландырган, дөрес җырламый аптыраткан, ләкин үзе өзелеп яраткан студентлары янына ашыга ул. Болар да, еллар узгач, каяндыр ерак җирдән Ирнис абыйларына хат язар әле... Һәм ул хатларда йөрәк түреннән чыккан рәхмәт сүзе булыр. Әлегә репетиция бара. Җитәкче әсәрне шомарту буенча көндәлек эш белән мәшгуль:

– Бу – җыр түгел, сөтле су! Бичарайский, мәгънәсез аваз белән җырламагыз, зинһар! Сүнгән аккошлар тавышы кирәк түгел.

Еллар узгач, Ирнис абыйның шушы яратып шелтәләүләрен дә сагынып искә алачак әле бу студентлар.

«Сәнәк тотам» түгел!

Хор 55 ел яшәү чорында «тәгәрмәч өстендәге филармония»не хәтерләтә. Анда, хордан тыш, «Былбыл» вокаль ансамбле, солистлар, биючеләр, нәфис сүз сөйләүчеләр дә бар. Кайда гына, кем алдында гына җырласалар да, җитәкче һәрчак интонация сафлыгы, образлы яңгыраш өчен көрәшә. Аның өчен вак нәрсә юк, барысы да беренчел дәрәҗәдә мөһим: киемең дә, чәчең дә, сулышың, хәтта нәрсә уйлавың да! Икенчерәк нәрсә турында уйга бирелеп киткән кешене ул шундук сизеп ала. Бервакыт А.Ключаревның Г.Зәйнашева шигыренә җырлана торган «Туган җирем – Татарстан» җырын өйрәнәбез. Ирнис абый гадәтенә, һәрвакыттагыча, тугры:

– «Матур булып ата бездә таң». Күз алдына китерегез: таң ата, яшел яфраклар арасыннан кояшның беренче нурлары сузыла, кошлар сайрый. Бу хакта битараф тавыш белән җырларга ярамый! Җырлаганда һәрвакыт ни турында сүз барганын уйларга кирәк.

Хор җырлаган чакта сүз-авазлар әйтелешенә маэстро аеруча игътибарлы. Татар теленең бөтен авазларын ачык һәм дөрес әйтүне таләп итә. Үзе Казанда үскән, татарчаны әби-бабасы янына Арчага кайткан арада гына ишеткән кешегә ана телен шулай камил дәрәҗәдә аңларга, минемчә, төпле белеменнән тыш, тырышлыгы да ярдәм иткәндер.

– Балалар бакчасыннан алып консерваториягә чаклы гел урысча сөйләштек. Урысчаны мин теләсә кайсы урыстан яхшырак беләм, дип әйтә алам. Французча да аңлашыр-гәпләшерлек рәтем бар. Безнең буын урыс мохитендә тәрбияләнде бит, – ди ул үзе.

Шуңа да карамастан, татарчаны үзлегеннән өйрәнгән. Улы Рөстәмне үстергәндә, аның белән төшкә кадәр татарча, төштән соң урысча сөйләшкәннәрен дә әйткәне булды. Хор репетицияләрендә, никадәр генә читен булмасын, тырыша-тырыша үзебезчә сөйли ул. Грамматик хаталар да җибәргәли инде, ләкин барыбер ана телебездә аралаша. Урысча сүзләр кыстырган шәкертләрен төзәткәләп тә куя әле хәтта.

Тагын бер хатирә: күбебез авыл баласы булсак та, ни хикмәт, иренләшкән «а» авазы урынына урысча ачык «а»ны әйтеп җырлыйбыз икән. Ирнис абый дәрес саен сабыр гына төзәтә тора. Халыкара студентлар гимны «Гаудеамус»та исә, «сэнэк тутем» дигән латинча гыйбарәне әйтүебезне ошатмый. Кисәтеп-кисәтеп тә төзәтмәгәч, тавышын күтәребрәк:

– «Сәнәк тотам» түгел, «сэнэк тутем!» – дияргә мәҗбүр була.

Тагын бер чигенеш

1997 елның 25 апреле. Университетның актлар залында Татар халык хорына 30 ел тулуга багышланган бәйрәм концерты бара. Хор берничә әсәр башкаргач, Ирнис абый халыкка мөрәҗәгать итте:

– Җәмәгать, бу залда, бүгенге бәйрәм кичәсендә минем әнием утыра. (Зал көчле алкышларга күмелде.) Бәхетле угыл әнисе турында тагын нидер әйтергә теләсә дә, сүзен дәвам итә алмады – тамагына төер, күзенә яшь тыгылды... Ул ялт итеп хорга таба борылды да «игътибар» дигән ишарә ясады. Без Луиза Батыр-Болгариның (Марсель Галиев шигыре) «Су буеннан әнкәй кайтып килә» дигән җырын башлап җибәрдек. Остазыбызның бу чактагы халәтендә, ихлас күз яшендә яшәеш фәлсәфәсе дә, инде бүген үзе әти булган бердәнбере – улы Рөстәм хакындагы уйлары да, кешеләргә сәнгать шатлыгы бирә алуына горурлануы да, Нәгыймә апага рәхмәт хисе дә чагыла иде. Анысын сүзсез дә аңладык...

Ирнис Рәхимуллин – үз гомерендә тау кадәр эш башкарган кеше. Мәшһүр профессор С.А.Казачков, үз укучысының казанышларына сөенеп, аңа мондый бәя бирә: *«Ирнис Рәхимуллин – гаҗәеп төрле юнәлешләрдә эшли алырдай, бай иҗади тәҗрибәгә ия талантлы музыкант һәм хор дирижеры. Барлык иҗади казанышларын исәпкә алсак, Ирнис Әхмәдулла улының Татарстандагы иң күренекле мәгърифәтче музыкант икәнен күрербез».* Гомеренең 62 елын күмәк җырлау сәнгатенә багышлаган зат нигез салган хорда җырлый башлаганнарның балалары да, студентлык чорын төгәлләп, ил-көнгә хезмәт итә. Инде өченче буын – «оныклар»ны хорда җырлатыр чак. Ә Ирнис абый, сигез дистәне түгәрәкләп куйса да, сөбеханАллаһ, диик, һаман яшь, һаман көчле, һаман җыр-моңлы. Аның үзе оештырган җыр күмәгенә карата кредосы да сокландыргыч: «Безнең максат – укытучы булачак яшьләрнең чын эстетик, сәнгать тәрбиясе алуы, – ди ул. – Бер көнлек җырлар башкармыйбыз, ә чишмәдәй пакь әсәрләргә алынабыз. Андый җырлар тыңлаучының да, хор җырчыларының да җанын сафландыра. Хор күп тавышлы орган кебек яңгырый. Шуңа күрә дә ул күмәк сәнгать, фикердәшләр, дуслар иҗаты!»

Шулай дәвам гына итсен иде. Ирнис абыйның бик күркәм хыялы бар: КФУның татар халык хорын Италиядәге халыкара хорлар фестивалендә катнаштыру. Үзара сөйләшүләрнең берсендә: «Италиягә барып җырламыйча үләргә ярамый әле миңа!» – дип куйган иде. Мең кәррә амин, йа Раббым! Яңгыратыйк әле татар моңнарын Европа уртасында! Яшьләр янында яшәгән кеше вакыт сынауларына бирешми, диләр бит.

Һәрчак шулай яшь булып кал, остазыбыз! ■

Төсләрдә милли хисләр

Дания Гайнетдинова

Татарстан Республикасының халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗев

Казан Ратушасының сәнгать залында Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗевның «Төсләрдә милли хисләр» дип аталган күргәзмәсе ачылды. Рәссам билгеләп үткәнчә, ул иҗатының 50 еллыгы уңаеннан оештырылган. Кылкаләм остасының тормыш һәм иҗат юлын барлый башласак, Татарстанның Шәмәрдән эшчеләр бистәсендә дөньяга аваз салган Мөдәррис Минһаҗев, мәктәпне тәмамлаганнан соң, Ижау каласына юл тота. 1976 елда ул Ижау дәүләт университетының сәнгать-графика факультетын тәмамлый һәм армия хезмәтенә алына. Армия хезмәтеннән кайткач, Арчада сәнгать остаханәсен оештырып җибәрә. Соңрак, 1978 елда Мөдәррис Минһаҗев Түбән Кама каласына күченеп килә һәм анда сәнгать студиясе ача. Һәрдаим камиллеккә омтылучы рәссам Түбән Камада шәһәр диварларын, урам мәйданнарын һәм башка билгеле биналарны бизи, Кызыл Чишмәдә мәчет бизәүгә алына һәм даими рәвештә күргәзмәләрдә катнаша башлый. Иҗатчының күңеле һәрдаим эзләнүдә, яңа образлар тудыруда. Ул, әле моңарчы кеше күзе күрмәгән тын табигатьне, сабый чагында әби-бабасы сөйләгән шанлы үткәнебезне, чишмә моңнарын, буй җитмәслек кыя-тауларны эзләп, кабат юлга кузгала. Бу юлы аны Лениногорск каласы үзенә сыендыра. Мөдәррис Мөхетдин улы 1998 елдан әлеге калада яшәп иҗат итә. Шул еллар дәвамында кылкаләмен шактый чарлый һәм чын рәссам булып җитлегә. Аның әледән-әле оештырылып килә торган күргәзмәләре, Зәй, Яшел Үзән, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама һәм Ижау калаларын узып, башкалабыз Казанны яулап ала. Башкортстан, Казакъстан кебек тугандаш республикаларда яшәүче халыклар да кылкаләм остасының гүзәл иҗат әсәрләре белән хозурлана алды. Бүгенге көндә ул башкалабыз Казанда яшәп иҗат итә.

Мөдәррис Минһаҗевның иҗат эшчәнлегенә дә 50 ел вакыт узган икән. Ул соңгы елларда милли бизәкләргә аеруча игътибар бирә башлады. Бу – аның күңел халәте. Әлеге күргәзмәнең «Төсләрдә милли хисләр» дип аталуы да шуңа бер дәлил.

Тынгысыз, эзләнүчән һәм максатчан иҗат остасы Мөдәррис Минһаҗев – гүзәл табигатькә, андагы һәр тереклек иясенә, гасырлар хәтерен саклаучы тау-ташларга һәм, әлбәттә, бала чагыннан ук авыл өйләрендә күреп үскән милли төсләргә, әни-әбиләребезнең чигешләрендәге бизәкләргә гашыйк рәссам. Вакыт дигән тылсымлы дәрьяны чорлар аша бүгенгесе белән тоташтыра ул. «Төсләрдә

Күргәзмәгә дуслар килгән.

милли хисләр» күргәзмәсендә дә автор бизәкләр аша үткән тарихыбызга алып кайта, уйланырга чакыра. Аларның җылысын, кайтаваз аһәңен гасырлар аша безгә килеп ирешкән әлеге бизәкләрдә тоемлап була.

Юл йөргәндә дә этюднигын үзеннән калдырмаска тырыша Мөдәррис Мөхетдин улы. Дөньяның матурлыгы киндергә күчми калыр да, башка бик күпләр бу матурлыкны күрми калыр сыман. Шуңадыр да ул, кылкаләмен табигатьнең кабатланмас төсләренә манып, шул сихри гүзәллекне ак киндергә иңдерә бара. Олы иҗаты белән тамашачыларын матурлык дөньясына алып керә рәссам. Чыннан да, дөньяны матурлык коткарыр, дип юкка гына әйтмиләрдер.

Рәссам Мөдәррис Минһаҗев бер үк вакытта тарихи жанрда да иҗатын туктатмый. Аны еш кына изге Болгар җирендә дә күрергә була. «Иҗатымны татар халкының тарихын яктыртуга багышлавым юктан гына түгел, изге Болгар җирләре минем дөньяга карашымны, иҗатымны яңабаштан барлап чыгарга этәрде», – дияргә ярата ул.

Чыннан да, син, рәссам миссиясен үтәр өчен дөньяга килгәнсең икән, гомерең буе Сәнгать дигән бөек могҗизага хезмәт итәргә мәҗбүрсең. Мөдәррис Минһаҗев та, табигатьнең күңел күзе генә күрә алган яшерен серләрен, тын гүзәллеген, әйләнә-тирәдәгеләрнең эчке кичерешләрен тоемлап, аларны берәм-берәм киндергә иңдерә бара. Ул олы иҗаты белән заманның бертуктаусыз үзгәреп торган вакыйгаларының асылына төшенергә, үткән белән киләчәкне тоташтыручы җеп очын ялгарга омтыла. Шунсыз биеклеккә омтылу мөмкин дә түгелдер, мөгаен.

Рәссамның иҗатында дөньяны үзенчә күзаллавын, фәлсәфи фикер йөртүен тоемлыйбыз. Үткән тарихыбызны барлау, милли хис-тойгылар, рух бөеклеге, татар милләтенә генә хас нур, моң киндергә үзенчә җете төсләргә төрелеп иңдерелә. Аның һәр әсәрендә останың гармоник сиземләвен тоясың. Күргәзмәгә куелган милли бизәкләр бер карашка гадәти тоелса да, аларда ха-

лык язмышы, истәлек-хатирәләр, авыл халкы өчен кадерле булган чигешләр янәшәсендә үзеңне җылы бөркеп торган авыл өендә итеп хис итәсең. Автор иҗатында милли бизәкләр, шамаилләр элегрәк тә зур урын алып тора иде. Ул Мөдәррис Мөхетдин улының авыл өендә, әби-бабай нигезендә сабый чагында күңеленә, рухына сеңеп калган хатирәләреннән киләдер. Мөдәррис Минһаҗев гарәби язу алымын үзенең гади генә тоелган «Натюрморт»ларына да бизәк итеп кертеп җибәрә.

Иҗатчының һәр картинасы киләчәккә якты өмет, күтәренке хис, яшәү шатлыгы белән сугарылган. Автор шушы гүзәл табигать кочагында иҗатына тугры калып, халкым рухын саклап, киләчәккә якты өмет-хыяллар белән яши. Гомеренең 50 елын олы иҗат дөньясына багышлаган Мөдәррис Минһаҗев – чын мәгънәсендә Халык рәссамы.

М.Минһаҗев «Иске патефон». Киндер, майлы буяу. 2000 ел

Төрле жанрда, төрле техника белән иҗат ителгән пейзажларда туган як табигате яктыртылса, төрле чор кешеләренең уйчан да, мөлаем да йөзләренә күреп туймаслык гамь, моң яшеренгән.

Мөдәррис Минһаҗевның әсәрләре татар мәдәниятенә саллы өлеш кертә һәм алар дөньякүләм заман сәнгатенең хәзинәсе булып саналырлык гүзәл. Рәссамның Җирдә кешенең иҗади хезмәтен, туган як табигатенең матурлыгын данлаучы эшләре шигъри аһәң һәм мәхәббәт белән сугарылган. Аларны үз күзләрең белән күреп, сокланып, хозурланып калу кирәктер.

Чишмәләр, җир-суларыбыз да аңа рәхмәтледер, югыйсә картиналарда аларның агышын, җыр-моңнарын тоемлап булмас иде. Су буеннан кайтып килгән казлар да бер-берләренә аваз салгандай каңгылдашалар сыман. Әйтерсең лә, бу гүзәл картиналар сине табигатьнең үзенә сәяхәткә алып чыга!..

Гомер уза, еллар үтә. Тарих тәгәрмәче алга тәгәри. Кешелек, ашыга-ашыга, киләчәккә атлый. Тик бер генә мизгелгә артка борылып карыйсы, халкыбыз үткән дәвер һәм чорлар аша еракта калган хатирәләрне барлыйсы килә. Рәссам Мөдәррис Минһаҗев картиналары да безне хәтер яңартырга өнди сыман. Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗевның Казан Ратушасында ачылган күргәзмәсе чын мәгънәсендә үткән белән бүгенгене тоташтыручы күпер һәм иманга кайту кебек тә кабул ителә. Төсләрдәге милли хисләр тамашачы күңеленә дә якты нурлар сибә кебек. Иҗатың һәрчак төсләргә мул булсын дигән теләктә калыйк. ■

Җуелмас хәзинә

«Сагынуга дәва юк икән» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Сагынуга дәва юк икән

(Зөлфәт сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин көе)

Гел уемда, һаман уемда,
Атлар уйный урман буенда,
Әйтерсең лә, Сабан туенда –
Сагынуга дәва юк икән.

Кушымта:
Бүләр болыннары,
Сәет урманнары!
Гөлләр моңы һәрбер таңында –
Хәтер кебек уйнап,
Якты дөнья буйлап
Атлар чаба туган ягымда.

Олы юлда калдың озатып,
Биек йолдызларга күз атып.
Бер каравың җанны сызлатты –
Өзелермен инде, сөйгән яр!

Кушымта:
Бүләр болыннары,
Сәет урманнары!
Һәр чишмәгә таллар иелгән,
Синдә якты язым,
Янар яшьлек назым, –
Язлар назы калыр күңелдә.

Гел уемда һаман ул яклар,
Ял таратып чапкан шул атлар
Хыялымда һаман уйнаклар...
Сагынуга дәва юк икән.

Кушымта:
Бүләр болыннары,
Сәет урманнары!
Моңнар килә ерак киңлектән –
Тупыр-тупыр тояк,
Сөю юлы ерак –
Сагынуга дәва юк икән.

Тәртип радиосы

Күренекле шагыйрь, ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Республикабызның М.Җәлил исемендәге премиясе иясе, Мөслим районының Иске Сәет авылы тумасы Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов, 1947-2007)

Заманында (1990-1995 нче елларда булса кирәк), композитор Зиннур Гыйбадуллин «Салават күпере» журналы редакциясенә килгәч, «Сагынуга дәва юк икән» җырының ничек язылуын искә төшереп, шагыйрь Ләбиб Леронга болай дип сөйләгән иде: *«Без бу җырны Зөлфәт дус белән көне буе яздык. Бәхәсләшеп беттек. Миңа теге яисә бу сүз яки тулаем шигырь юлы ошамый. Зөлфәт исә, шигырьне яклап, аның һәр юлы, һәр сүзе өчен тартыша... Ничек итсәк иттек, тәки җырны язып бетердек!»*

Бу җыр Рөстәм Закиров һәм Ильвир Әхмәтов репертуарында бар.

Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзгә» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде. ■

Нарат

Дөньяда наратның 130 төре бар. Биеклеге 40 метрга кадәр җитә ала.

Тел галимнәре нарат сүзен монгол телендәге *нара* тамырлы сүздән алынган дип исәпли. Аны Әстерхан татарларында һәм Себер татарларының бер өлешендә *карагай* дип тә атыйлар. Себернең сазлыклы җирләрендә утырган татарларда *кызыл агач* дигән атамасы да бар.

Безнең халык наратка зур хөрмәт белән карый. Шулай да Казан татарлары арасында наратны өй тирәсенә бик утыртмыйлар. Төрле сырхаулардан нарат энәләре һәм күркәләреннән төнәтмәләр ясап эчәләр, ванналар ясап керәләр.

Наратка игътибарның бик зур булуын аның образы халык иҗатының барлык жанрларында да очравы дәлилли. Мәсәлән, дәвалау имнәрендә баш авыртуын: *«Алтын тауда алтын нарат! Шул наратның башын ясалмаган ук белән атып ничек шаулатсалар, шул чагында бу кешенең дә башы шауласын!»* – дигән имләү сүзләре белән дәвалаганнар.

Казан артындагы кайбер татар авылларында нарат әле Кирәмәт агачы буларак та исәпләнә. Ул нарат төбенә көмеш акчалар күмеп, баласызлар – бала, сырхаулылар шифа сорый. Зур юлга чыкканда юл садакалары калдыралар. Армиягә китүчеләр дә, исән-имин кайтып җитү теләкләрен әйтә-әйтә, әлеге изге исәпләнүче нарат төбенә акчалар күмеп калдыра.

Табышмакларда, җырларда, уен такмакларында яшь егетне наратка тиңләү бик популяр. Мәсәлән, наратка бәйле ошбу табышмак бик үзенчәлекле: *Җәй дә егет, кыш та егет, картайган юк, гел егет.*

Ә менә бу такмакны әле дә булса әйтәләр:

Нараттай төздер буйлары,
Кемдә икән уйлары?

*Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Фәнзилә Җәүһәрова**) белән берлектә әзерләнде.* ■

Нарат дәвалый

Мәшһүребез Каюм Насыйриның «Хәвасе нәбатат» («Шифалы үләннәр») китабына игътибарыбызны юнәлтик әле:

«**Нарат** (сосна обыкновенная), гарәпчә *санаубәр* диләр – күренекле агач. Нарат агачы һәм нарат урманы – сихәтлек өчен бик файдалы нәрсә. Нараттан яхшы майлар ясыйлар. Зәңгелә зәхмәте өчен ясала торган даруларның һәркайсына нарат чәчәге керә. Нараттан тагы *тәрмәнти* исемле яхшы май алына, аны *ак скипидар* дип атыйлар.

Нарат мае (живица), гарәпчә – *дуһи санаубәр*. Коры сызлауларга, тамырлар һәм сеңерләр авыруы, гарконнәса (арт сан, утракса нервлары ялкынсыну) өчен бик файдалы май. Ул агач маеннан куерак бертөрле май. Аның белән мунчада яки ягылган мич алдында уынырга кирәк. Соңыннан бик җылы әйбер ябынып ятарга кирәк. Бу май бәлзәм мае белән бердер».

Нарат маеның тән-тире авыруларына да (мәсәлән, гөмбәчек барлыкка килгәндә, үлек булганда), шулай ук сулыш алу юлларына да файдасы бар. Әлеге май ярдәмендә пародонтоз, туберкулез һәм яман шеш авыруларын дәвалыйлар.

Янә К.Насыйри китабын укыйбыз:

«**Нарат әкәләсе** (сосновая шишка), (*нарат күркәсе* дә диләр), гарәпчә *хәбел-санаубәр-ел-кәбар* (җилгузә) дип атала. Мәнинең көчсезлегенә һәм җенси якынлыкка куәт бирә. Нарат сагызын бер кисәк бүзгә сеңдереп, аннан кояшта киптереп, яндырып төтенен борын белән иснәсәң, томау төшкәнгә файдалы. Тагы дүрт көнгә бер кил торган бизгәк өчен бик файдалы. Бизгәк тотканда яндырып иснилә, күп дәвага ия».

4-5 сантиметр зурлыктагы нарат күркәсен май-июнь айларында җыялар. Төнәтмәне болай әзерлиләр: бер литр суга 6 нарат күркәсе салалар, кайнатып чыгаралар, 15 минут тондырып торалар да сөзәләр. Тәүлеккә өч мәртәбә икешәр калак – балаларга, дүрт мәртәбә ике кашык өлкәннәргә эчәргә рөхсәт ителә. Салкын тигәннән, арыганлыктан һәм йокысызлыктан бик файдалы.

Нарат әкәләсе

Нарат мае гәрәбә төсендә була

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2022

Көлке куа килә...

Гамил Афзал (1921-2003)

Гадел эшкә сәбәп

Хатын китте. Аерылыштык. Үч алырга
Уйламыйм да, гадел бит мин. Шушы көндә
Приказ бирәм МТСтан чыгарырга
Атасын да, абыйсын да, сеңлесен дә.

Пычак телле тәнкыйтьчеләр – начар халык,
Бездә, имеш, яши туган-тумачалык.
Житәр инде, төзәлергә вакыт житте,
Гадел эшкә сәбәп булып хатын китте...

1955

Гамил Афзал.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Хәзерге заман гүзәле

Марҗа дисәң, кысык күзле,
Татар дисәң, «саламбаш».
Бер карасаң, киенгән күк,
Бер карасаң, ялангач.

Кәҗә дисәң, җилене юк,
Балык дисәң – саңагы.
Күлмәк дисәң, итәге юк,
Ыштан дисәң – балагы.

Гәрәй Рәхим (1941-2021)

Булмый

Чәнечкеле булу белән –
Кычыткан роза булмый.
Дурактан дурак туса да,
Даhидан даhи тумый.

Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

Кулыма алтын богаулар,
Кил әле, кидер, иркәм...
Рәшит Әхмәтҗанов

Алтын богау ялтыраса
Ялт-йолт минем кулларда,
Исләремә син төшәсең
Командировкаларда.

Ял итсен әле кулларым,
Иртәгә Зәйгә китәм.
Бүгенгә богауларымны
Салдырып торчы, иркәм!..

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Тулы хуҗа

(Саба мәзәге)

Нургаян Мөхәммәтшин чираттагы ялга җыена. Үз урынына каласы кеше белән прием-сдача ясый.

– Менә шулай, туган, мин иртәгәдән отпускка китәм. Син тулы хуҗа буласың. Шулай итеп колхозның бөтен байлыгы синең кулга күчә. Миндә фәкать өч кенә ачкыч кала: фураж, ит һәм балныкы...

Рабит Батулла (1938)

Урыннан сүз ыргыту

(Әхәт Гаффар сөйләгән нотыктан бер өзек)

Гаффар. Әсәрнең ретроспективный перспективасының ракурсы әйбәт. Ул сикәлтәле юлдан йомшак-амортизацион рессорларга салып алып чыккан хиснең үсеш процессын катгыян тәгаенләми сыман кебек тоела, миңа калса... Һәрхәлдә, бу логика призмасыннан ерак тора. Гәрчә, бу турыда миннән алдагы иптәшләр әйтеп узган булсалар да, әйтер идем, бәлки, алга таба без бу мәсьәләне Әлмәт җирлегенә күчереп, яңадан тәфсилләп тикшереп карасак, экспансив линзалар аша өйрәнсәк тә, начар булмас сыман тоела, миңа калса... Хәлбуки, бу турыдан-туры минем иҗатыма кагылышлы түгел. Биниһая, тагын шуны әйтер идем мин, чабата ул татарның аяк киеме түгел. Никадәр генә фәкыйрь булса да, татар җегетләре итек кияргә тырышкан.

Туфан Миңнуллин *(урыннан кычкыра).* Мин унынчы класска чабата киеп йөрдем! Нәрсә? Мин татар түгелмени, ә?!

Гаффар. Мантыйкый фикер йөрткәндә, син, Туфан абый, мотлакан татар булырга тиеш, әмма ләкин, Туфан абый, син Хафиз белән Хафизә чорында яшәмәгән. Алар революциягә кадәр яшәгән. Идентик әсәрләрне алып рекогносцировка ясап алсак, әлгаязы билләһи, «Казан утлары»ның минем исем чыккан саннары аеруча әйбәт тоела, миңа калса...

31 март, 1984 ел

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2022



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Әхмәт Фәйзи (1903-1958)

Чәй эчәбез бал белән

Чәй эчәбез бал белән,
Бала-чагалар белән.
Бала-чага алты җан:
Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан,
Зәйнәп белән Галия,
Иң соңгысы Асия...

«Бал» дисәң, ул бер кими,
Кашык тыксаң, өч кими,
Алты кашык тыгылса,
Иртә тия, кич тими,
Кайвакытта һич тими.

Гәрәбәдәй сары бал
Тора табын балкытып.
Табыныбыз уртасында
Кунагыбыз – бал корты.

Мидхәт Миншин (1936-2009)

Серле күл

Бәбкәләр күк тезелешеп,
Барабыз күлгә –
Уйнап-көлеп су керәбез
Кояшлы көндә.
Күлгә иелгән таллар, камышлар,
Тарта күңелне серле тавышлар.

Судан чыккач, безгә апа
Әкият сөйли...
Нигә инде су анасы
Үзе дә килми?..
Әй, бик матурдыр алтын тарагы,
Күрсәң иде бер чәчен таравын.

Альберт Хәсәнов (1937-2020)

Бал корты һәм яңгыр

Кичә кичке якта яңгыр яуган иде. Нәҗия балалар бакчасыннан кайтышлый ярыйсы гына чыланды...

Шуңа күрә, бүген иртән тору белән үк, ул тәрәзәгә бакты. Көн бүген дә болытлы күренә. Юк инде, Нәҗия бүген алдатмас: үзе белән кечкенә кулчатырын да алачак. Әнисе исә бакчадагы умарта ояларына ишарәләде:

– Бүген яңгыр булмас, кызым, кулчатырыңны алып торма, – диде. – Көндез яңгыр явасы булса, кортлар ояларыннан борыннарын да күрсәтмиләр. Ә бүген исә, әнә, күр, алар ничек иртә кутәрелгәннәр, ничек дәртләнеп очалар.

Чын икән, ул көнне Нәҗиягә кулчатырның кирәге булмады, бер тамчы да яңгыр яумады. «Кара син аны, үзләре нәп-нәни кортлар, ә көннең нинди буласын әллә каян беләләр!» – дип гаҗәпләнде Нәҗия.

Әнәс Кари (1920-1954)

Үрдәк

Үрдәк йөри
Күл буенда,
Бәбкәләре
Бар янында,
«Би-бип-бип-бип,
Ни ашыйк?» – дип
Йөдәтәләр һәр адымда.

Алпан-тилпән
Бара атлап
Ана үрдәк –
Комны мактап:
«Монда азык,
Ашыйк казып,
Килегез, кил,
Бак-бак-бак-бак!»

Йөзеп күлгә
Кереп китә
Киң борынын
Төпкә төртә,
Бәбкәләргә
Дәшә кат-кат:
«Таптым азык,
Бак-бак-бак-бак!»

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

МАЙ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 2 майда татар зыялылары дин һәм мәдәният-сәнгать әһелләре (Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Разил Вәлиев, Фоат Рәфыйков, Искәндәр Гыйләҗев, Ләбиб Лерон, Ринат Закиров, Данил Салихов, Харис Камалиев һ.б.), Яңа татар бистәсе зиратында җирләнгән күренекле шәхесләрне искә алып, мәрхүмнәребез рухына дога кылды.

● 4 майда Түбән Кама муниципаль район хакимияте башлыгы Рамил Муллин «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Леронны ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясен алуы белән котлады.

● 4 майда Мөслим районы үзәгендәге Тукай скверында Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенең быелгы лауреты, шагыйрь Ләбиб Леронга элмә такта кую чарасы булып узды.

● 5-6 майда Сарманда дин белгече, тарихчы, мәгърифәтче, Иске Әлмәт авылы тумасы Морат Рәмзигә (1854-1934) нисбәтле фәнни-гамәли конференция үтте. Чарада Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Сарман һәм Мөслим район хакимиятләре башлыклары Ф.Хөснуллин һәм А.Хуҗин, галимнәр Ф.Уразаев (әлеге чараны оештыручы), Х.Миңнегулов, А.Борһанов, И.Гыйләҗев, Йосыф хәзрәт Дәүләтшин, «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Л.Лерон белән Л.Гобәйдуллин, төбәк тарихын өйрәнүчеләр (Д.Гарифуллин, Н.Мәхмүтов, Д.Кәшипова һ.б.), М.Рәмзинең нәсел дәвамчылары, якын-тирә авыллардан килгән дин әһелләре катнашты.

● 13 майда Казан федераль университетының мәрмәр залында «Журналистлар династиясе» дигән фотокүргәзмә ачылды. Декан Л.Толчинский алып барган әлеге чарада «Татмедиа» АҖ генераль директоры Ш.Садыйков, «Безнең мирас»

журналы»ның баш мөхәррире Л.Лерон, «Татарстан» телерадиокомпаниясенең милли тапшырулар хезмәте башлыгы М.Сәфәров чыгыш ясады.

● 17 майда Питрәчтәге 2 нче мәктәптә балалар язучысы Ләбиб Лерон укытучылар һәм укучылар белән очрашты.

● 17-18 майда «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Л.Лерон һәм Л.Гобәйдуллин Мордовиядәге Аксюн авылында эшлекле сәфәрдә булып, эшмәкәр Рәфыйк Фәтхуллов, шулай ук, авыл белән танышкан вакытта, яңа төзелеп беткән мәчеткә һәм мәктәпкә кереп, укытучылар һәм укучылар, шул исәптән төбәк тарихын өйрәнүче, шушы авыл тумасы Ирек Биккинин белән очрашты.

● 18 майда «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Л.Лерон һәм Л.Гобәйдуллин Мордовиядәге Рузаевка районының Татар Пешләсе авылында (әдип Ш.Камал биредә туган), аерым алганда, авыл китапханәсендә, мәктәптә һәм мәчеттә булды.

● 19 майда Кол Шәриф мәчетендә «Тәртип» радиосы, «Рухи моң» иҗат берләшмәсе һәм Татарстан Диния нәзарәте белән берлектә оештырылган «Татар азаны-2022» III бөтентатар бәйгесенең йомгаклау чарасы узды. «Татар мәзине» исеменә Динар Шәймәрданов лаек булды. Икенче урында – Илфат Гыйбадуллин һәм өченче урын иясе – Рузил Ихсанов. Аларның өчесенә дә «Тәртип» радиосында азан әйтү хокукы бирелде.

● 20 майда, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында, Казанның элек «Кырлай» паркы буларак танылган урынында Җәмигъ мәчете төзелешенә нигез ташы салу тантанасы булып үтте.

● 24 майда Казанда күренекле шагыйрь, ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов, 1947-2007) яшәгән йортка истәлек тактасы куелды. Шул көнне кичен Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында әдипнең туууына 75 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды. ■

МИРАСВОРД

Композитор Азат Хөсәенов туган авыл

... Булгакова

... кисеп җиң ялгау

Балык аулау коралы

Тузган, таушалган

Әмирхан ...

Рус халык әкиятендәге персонаж

Язучы Ибраһим ...

Аңа үлем юк

Даян ... (Бөек Ватан сугышы ветераны, Чехословакия герое)

Урта гасыр фарсы-таҗик шагыйре

... Гыйззәт

Кече Азиядәге борынгы дәүләт

Фатих Кәрим поэмасы

Рөхсәт, фатиха (иск.)

Әхсән Баян поэмасы

Элмәк кидерү өчен аркылы агач

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Артышның Урта Азия төре

... Алигьери (итальян шагыйре)

«Башсыз җайдак» романы авторы

Ярдәмче фигыль

Фәкать, бары тик (иск.)

Сынчы ... Нигъмәтуллина

Габдулла Тукай яшәгән шәһәр

Мәҗүсиләр табына торган сын, балбал

...-том

... Сакаева

Идел буе Болгар дәүләте идарәчесе

Нәкый Исәнбәт сүзләренә җырлана торган татар халык көе

Татар халык җыры

Мөселманнарда өлкән рухани

Казахстан каласы

«Шүрәле», «Раушан»

Актаныш районындагы авыл

... Гамбәр

Отеллоның милләте

... Мирзаянов

Рус телендә чыга торган газета

Ояда калдырылган йомырка

Үзбәк ансамбле

Язучының иҗат җимеше

Калашников автоматы

Сербия каласы

Кан кардәшлеге булган берничә буын, нәсел

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: әл, буаз, салма, иру, абаз, чин, Госман, такан, Нәби, Таиров, Бәян, Фива, хан, Фаил, Утыз, Ак, Иргали, дрейф, ату, фарс, Фәрит, Роза, Фадлан.

Өстән аска: Сибгатуллин, лар, әлү, скиф, ага, Рифкать, Тарханова, Лу, Нәваи, фәрд, Лоран, ти, уд, Риза, биана, бау, стан, Бикчәнтәев, алача, Нәзифә.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас» елъязмасы / июнь

Нәби Дәүлинең Базарлы Матак гимназиясе каршында куелган бюсты.
Фото alki-rt.ru сайтыннан алынды.

645 ел элек (1377)

Мамай мирзаның уң як Идел ярындагы идарәчесе – гаскәр башлыгы Гарәпшаһ Мәскәү кенәзлеге гаскәрләренә Пьяна елгасы буенда һөҗүм итә һәм хәлиткеч җиңүгә ирешә.

640 ел элек (1382)

Татарларның алгы күзәтү (разведка) гаскәре җәй башында Мәскәүгә килеп җитә, бераздан алар каланы камап алалар, шул рәвешле Мәскәүне яулап алу күрәше башлана.

185 ел элек (1837)

Сәүдәгәр, милләтпәрвәр җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче Әхмәт Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1837-1906) дөньяга килә.

105 ел элек (1917)

Ташкент шәһәрендә татар вә үзбәк телләрендә «Киңәш» исеме белән атналык газета чыга башлый. Тора-бара аның исеме дә үзгәрә, «Нәҗат» вә «Шураи ислам» буларак, икегә аерыла. Нашире – «Төркестан мөселман мәркәз шурасы», мөхәррирләре – Зәки Вәлиди вә Мөнәвәр карый Габдерәшит.

100 ел элек (1922)

Уфада «Таң» исемендә китап кибете ачыла. Исмәгыйль Рәми вә Давыт Юлтый оештырган ошбу кибет милләттәшләребезгә татар телендәге китапларны тәкъдим итә.

65 ел элек (1957)

«Совет әдәбияты» журналының июнь ае санында Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» исемле повесте басыла башлый.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Июнь 2022

И останется в мире слово моё…: Шариф Камал.

Историческое наследие: «Татарский остров в Мордовии: лямбирские и тюменские татары, эрзя». И.Биккинин; «Оказала помощь мужу». Н.Исхаков; «Марийские термины в речи малмыжских татар». И.Газизуллин; «Татарский мир 100 лет назад: Сабантуй». Р.Шарафиева, Л.Губайдуллин; «Стамбульские письма». Ф.Карими.

Татарский мир: «Мы кто или Размышления об одной книге». И.Тагиров; «Рафик Фатхуллов: «Мы проводим Сабантуй так, чтоб о татарах знали».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Ислам. Религиозный словарь»; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «Автобиография» («Тәрҗемәи хәлем»). Х.Хамидулла; «Большое счастье композитора». Э.Шарифуллина.

В глубинах памяти: «В усадьбе Кулунчаковых». Р.Абянов, М.Сафаров; «Прерванная песня». Ф.Салимова; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Природное наследие: «Сосна».

Алхәбәр:

Рәсемдә (сулдан уңга): утырганнар – Котдус Сәйфуллин, Муса Җәлил һәм аның баҗасы Сергей Тарасов; икенче рәттә басканнар – Әминә ханымның әнисе Рабига апа, Әминә Җәлилова, исемнәре ачыкланмаган туташлар, Әминәнең бертуган апасы Роза. 1937 ел ***(Фото матбугатта беренче тапкыр басыла.)***
(«Кадерле минутлар, бәхетле сәгатьләр». Назирә Фәттахова, Ләйсән Харрасова)

Мордовиянең Сыркыды авылы тумасы Һади Такташ һәм аның гаиләсе — фотоларда

Һади Такташ беренче хатыны Гөлчәһрә Хәмзина һәм уллары Рафаил белән. 1927 ел

Һади Такташның апасы Фатыйма ире Каюм, уллары (сулдан) Рәшит, Әхәт һәм кызлары Сәйдә белән

Һади Такташның әнисе Шәмсениса

Һади Такташның әтисе Хәйрулла

Һади Такташның сеңлесе Хәнифә. 1930 ел

Фотолар Лена Гайнанова архивыннан алынды.

«ИДЕЛ КИЧМИ ИЛ БУЛМЫЙ»



Фотолар хаҗи Абдулла Дубин коллекциясеннән алынды.

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.